# ФИРДӘҮСИ

# ШАҺНАМӘ



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2003

УДК 821.512.1
ББК 84 (2 Рос = Тат)9
Ф57

Хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемә итүче
*МӘСГУД ГАЙНЕТДИН*

**Фирдәүси Әбелкасыйм**

Ф 57 Шаһнамә.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2003.— 231 б.

«Шаһнамә» — дөнья әдәбиятының иң мәшһүр иҗат үрнәкләреннән. Иранның бөек шагыйре Әбелкасыйм Фирдәүси (930—1020) әсәре. Бүгенге укучының әдәби мираска ихтыяҗын күздә тотып, «Шаһнамә»дән «Кәй-Кәвыс» һәм «Сиявуш» бүлекләрен хәзер-ге әдәби телдә тәкъдим итәбез.

ISBN 5-298-01265-5
© Татарстан китап нәшрияты, 2003

# КӘЙ-КӘВЫС



## *Мазандиран явы*

Чыгып утырды Кәй-Кәвыс тәхеткә:
«Ирештем,— ди,— шөһрәт, хөрмәт, бәхеткә!»

Боерды ул: «Барлансын бар хәзинә!»
Җыйды, кайда булса, байлык үзенә.

Аның барысын күздән бер кичерде,
Алтын-көмеш муллыгыннан исерде.

Күңеленә тулды шатлык, горурлык,
Бирде дәфтәргә теркәргә боерык.

Шулай беркөн бер бакчада шаһ Кәвыс,
Бәкләр белән шәрабтән итеп авыз,

Күңел ачып утыралар гөрләшеп,
Табынына гөлләр карый көнләшеп.

Ничә бәкләр утырган каршыракта,
Ничә тора аягүрә еракта.

Назлы сазлар талгын моң-көй сирпиләр,
Шәраб коеп тора гүзәл сәкыйләр.

Гизеп тора бокаллар бер-бер артлы,
Гайрәт тулы йөрәкләр, күңел якты.

Сәрхуш булды Кәй-Кәвыс, эчә-эчә,
Мактанырга тотынды гадәтенчә.

Диде: «Бер шаһ тиң булырмы үземә?
Кемдә булган бу кадәр мал, хәзинә?

Кемдә бар бу кадәр авыл-шәһәрләр,
Кем була тиң җирдә миңа бәрабәр?

Кем бар җирдә хөкмемнән баш тартала?
Буйсынсын бар авыл миңа, бар кала!

Телим — миңа тик буйсынсын бар Галәм!»
Диләр бәкләр: «Бирсен Ходай Тәгаләм!

Кем ки синең әмереңнән тартар баш —
Явачак ич ул башка уклар тоташ».

Бер хезмәтче килде шулчак шаһка да,
Диде: «Җырчы рөхсәт сорый капкада.

Гыйльме, нәрсә сорасаң да, бар, имеш,
Үзе уйнап, үзе үк җырлар, имеш.

Бик оста, ди, килгән Мазандираннан.
Көтә рөхсәт капкада күп заманнан».

Боерды шаһ, бакчага керде җырчы.
Кул күтәреп, шаһка күп дога кылды.

Шаһ ишарәт итте, уйна, дип, сазың,
Саз сыздырды бераз сихри авазын.

Ага моң-көй — назлый, җанга дәрт сала,
Күңелләрдә шат тойгылар кузгала.

Бераз уйнап кузгатты да хисләрне,
Ул җыр белән хәйран итте кешеләрне:

Кулы оста, нәфис авазы, теле,
Ишеткәннең сихерләнә күңеле.

Газәл җырлый, мактап Мазандиранны,
Гашыйк итеп сихри илгә бар җанны,

Мактый шаһын, мактый суын, һавасын,
Болын, чәчәк, җимешләре дәвасын.

«Даим яз,— ди,— аның гөлбагларында,
Былбыл, тургай аның куакларында.

Болыннарда гүзәл боланнар гизә,
Суларында алтын чабаклар йөзә;

Җире — ганбәр, суы саф, хуш һавасы, —
Шунда инде бар дәртләрнең дәвасы.

Кышын-язын авында юк кимчелек —
Теләсә кем җәнлек ауласын йөк-йөк.

Суын эчсәң, эчтә җаннар тазара,
Әбелхәят кушкан дирсең аңарга;

Куаклардан китми һич тә яшеллек,
Яз башлана анда кышның башындук.

Иле төзек, халкы сау чиктән чиккә,
Диячәксең, туфрак-су шулай итә.

Еланнар карнында үсә җәүһәр таш,
Шуңар бу таш кырларда ауный тоташ.

Хәзинәдән ашкан алтыны, ташкан,
Алтын арзан ул якта кара таштан.

Ишәкләр дә анда алтын иярле,
Юксыллары, һәммәсе алтын зәрле.

Бәхетлеләр булса җирдә, тик — анда,
Башка андый бер урын юк җиһанда.

Мазандиран җирдә — җәннәт бакчасы.
Матур гомер сөргән шунда барчасы».

Гашыйк булды Кәвыс Мазандиранга,
Бу иллардән зәвык калмады җанга.

Шундук торып әйтте ул бәкләренә:
«Бу илдә юк дәрман йөрәкләремә.

Миңа тиң шаһ булганмы җирдә, бармы?
Кулымда мин тотам бөтен дөньяны.

Минем алда кем генә Җәмшит, Заххәк?
Миңа нисбәт, алар ич — бер уч туфрак,

Ник канәгать итим алар милкенә?
Күңел Мазандиранга дип җилкенә.

Ул оҗмахны ник мин калдырыйм читкә,
Ашкынам мин тик аңа — шул җәннәткә.

Ни өчен ди мин бармыйм анда ауга?
Сәер итәм кырында, чыгам тауга».

Бу сүзләрдән шом тулды күңелләргә,
Тик берсе дә аны алмый телләргә.

Диештеләр: «Син — шаһ, синдә ихтыяр,
Карышырга сиңа кемнең ирке бар?»

Ул сүзләрдән мәҗлестә Тус һәм Гишвад,
Гөргин, Харрад, Гударз булмады шат.

Таралдылар, калмады мәҗлестә ямь,
Уфтанышып, юк, дип, янда Заль, Рөстәм.

Җыелышты олылар бер тирәгә:
«Күрдегезме,— диләр,— шаһ ни сөйләнә?

Мазандиран ул бит — җеннәр оясы,
Дию, пәри, сихер — шунда барысы.

Һәвәс итсә Мазандиранга Кәвыс,
Ай-һай, кыйммәткә төшәчәк бу тавыш.

Бу башсызлык чыгар тик диванадан,
Китәр мең баш бу юлда, китәр мең җан.

Китәр дәүләт, китәр тәхет Кәвыстан, —
Шул нәтиҗә чыгар тик бу тавыштан.

Безне дию, паридән кем коткарыр?
Башларыбыз китәчәк, оят калыр.

Һәлакәткә, күрә торып, бир ди баш!
Безнең канга батачак ич туфрак, таш.

Тагын Иран дошманнардан җиңелә,
Тагын фетнә килә Иран җиренә.

Дию булсын, яки җен, яки пәри —
Болар Җәмшид хөкмендә иде бары,

Сихри йөзек бирелгән иде аңа,
Йөзек көче җитә бөтен дөньяңа.

Шул Җәмшид тә, бер кат, Мазандиранга
Кул сузмады, ул дәһшәтле еланга.

Ә Фәридун? — Яу башы! Тиңсез батыр!
Аның каршында бар шаһлар — бер факыр.

Мондый эшкә җөрьәт итмәде ул да,
Белә иде ни хәтәрләр бар юлда.

Һәм, ниһаять, Мәнүчәһер җиһангир,
Бар галәмне гаскәренә җыйган ир,

Ул да аны алмады хәтта телгә,
Кем кул сузар, белә торып, әҗәлгә?

Йөрәкләргә салмастан борын яра,
Бу бәлагә без табыйк бирәр чара».

Тус сүз башлый: «Чара — бер һәм бик асан.
Хәбәр салыйк: тиз килеп җитсен Дастан,

Хәлне итеп хикәят языйк хат та,
Юллыйк аны яшендәй җилгер атта.

Сабын сөртенгәнме? Юып тормасын,
Уртламасын күтәргән пыяласын».

«Юлын тапсаң, килеп җит,— диеп,— очып,
Саклап кал,— дип,— илнең-көннең тынычын».

Хат салдылар. Нимрузга җитте хәбәр,
Бу дәһшәтле хәбәрдән ачынды Заль:

«Бу Кәвыс та юньсез чыкты, пешмәгән,
Әле дәүләт эшенә керешмәгән,

Татымаган тормыш ачы-төчесен,
Тукмы-ачмы белми илнең кешесен,

Ил тормышын тотып атмакчы утка!
Миңа нәрсә эшләргә бу минутта?

Хакмы риза мондый эшкә йә халык?
Башлы кеше бу эшне күрмәс лаек.

Хакыйкатьне, кадамыйча бәгырьгә,
Ил алдында шаһ йөзенә бәрергә!

Калачакмын мәңгегә үкенечкә.
Белә торып, риза булсам бу эшкә,

Бу дуамал эшкә карышмас булсам,
Бар дус-ишне итәм үземә дошман.

Үз файдасы, колак салса сүземә,
Тыңламаса, үпкәләсен үзенә», —

Дип, төн буе уйланып ятты Дастан,
Очка чыга, уйлана яңабаштан.

Көн яктырды, кояш калкытты башын,
Нурга күмеп җир йөзен, тавы-ташын.

Ал таң белән Заль гаскәргә җар салды.
Атка менде. Иран якка юл алды.

Тирә-якта ат җилдерә олылар,
Төнне көнгә ялгап очып баралар.

Хәбәр килде: якынлашты Заль-Дастан,
Бу хәбәрдән шатлыкка тулды Иран.

Пәһлеваннар йөреде Зальгә каршы:
Тус, Гөстәһәм, Харрад, Гөргиннар — барсы.

Зальне күреп, афәрин укый халык,
Диләр: «Бу эш, менә, бәкләргә лаек.

Безнең тынычлык өчен рәнҗү чиктең:
Читкә атып рәхәтең, юлга чыктың.

Синең исмеңә эчә ант бөтен ил,
Сиңа зыян тидермәсен явыз җил.

Күләгәңдә яшибез шат һәм тыныч,
Дәвереңдә безгә юк бер куркыныч».

Бу сүзләргә рәхмәтләр укый Дастан:
«Юлыгызга корбан булсын баш һәм җан!»

Ә бәкләргә: «Без,— диде,— шаһка барыйк,
Каршысында тез чүгеп бер ялварыйк.

Ул бит безнең шаһыбыз һәм бәгебез,
Сүзебезне тотсын — шул теләгебез».

Кузгалдылар. Алдан бара Заль-Дастан,
Ә артыннан ияргән бар пәһлеван.

Заль җир үпте килеп Кәвыс алдына,
Теләк теләп, мактау сөйли атына:

«Җирдә бар шаһ сиңа коллыкка мохтаҗ!
Бик тә яраша үзеңә тәхет-таҗ!

Җирдә бәхет — гаделлегең җимеше,
Бу Галәмгә бәхет өләш, һәмишә».

Шаһ та олы хөрмәт күрсәтте Зальгә:
«Синең гомер — бәхет бөтен Иранга.

Хуш киләсең! Шәүләң дә безгә — калкан,
Килүеңне зарыгып көтә халкың.

Армадыңмы бу юл зәхмәтләреннән?
Хак сакласын сине афәтләреннән.

Күрешкән юк инде ничә заманнар,
Ни хәл Рөстәм? Ни хәлдә пәһлеваннар?»

Диде: «Бар да исән, шаһ хезмәтендә;
Дога укыйлар шаһымның хөрмәтенә,—

Болай диеп дәвам итте Заль шуннан: —
Бик күп хәлләр кичте минем башымнан:

Хезмәт иттем Мәнүчәһергә башлап,
Килде Нәүдәр, аннан Зув, аннан Гиршасб;

Кәй-Кобадка тәхет күчте аңардан,
Гаделлекне арттырды башкалардан,

Иран милке гүя кабат terelде.
Үткәнгә күз бер йөретеп күр инде.

Кайсы ничек көн кичергән, беләбез,
Хөрмәт белән искә алабыз менә без.

Алар хуҗа булып торды заманга,
Комагайлык итми Мазандиранга.

Мазандиран — тоташ дию сафы ла,
Галәмдә җен шуннан ич сихер ала.

Пәри йорты, сихерчеләр торагы —
Кайчан басты анда дошман аягы?

Бер затка да ул үз тылсымын ачмас,
Кошлар хәтта ул якка карап очмас.

Кылыч белән ул илне ачып булмый,
Күккә пәри артыннан очып булмый.

Безгә тиеш түгел һич анда бару,
Бу — бар көчкә ташка йодрык ору.

Анда борылган гаскәр азгынлана,
Табыш күрми, китәчәк мал, хәзинә.

Үтенәбез: гаскәрең сөрмә анда,
Бу башсызлыкка галәм калыр таңга,

Йөрәгеңдәге диюгә юл бирмә,
Нәфсе өчен гаскәр канына кермә».

Болай дип шаһ җавап бирде батырга:
«Сүзең һәрчак туры килә акылга,

Һәр киңәшең, валлаһи, мәслихәттер,
Кирәкми, тик калдырышмыйк без хәтер.

Мазандиран биләгән күңелемне,
Һичбер киңәш аермас аннан мине.

Мазандиран — минем җырым, теләгем,
Башка сүзләргә бикләнде колагым.

Зинһар, әйтмә миңа Җәмшид кыйссасын,
Миңа тартма аның бик тар кысасын.

Минем алда кем әле Фәридун да?
Күпме гаскәр, беләмсең, минем кулда?

Миндә алардан артык тапкырлык бар,
Тапкыр кеше, аңласаң, тауны ярар.

Карыйммы соң Фәридун бармазына?!
Каршы торыр көч кайда бу явыма?

Салачакмын Мазандиранны юлга,
Пәриләрнең канатын йола-йолка!

Изге юлга аларны мин салырмын,
Диюләрнең сихерен кайтарырмын.

Сихер, әфсен җиңәр көч «Шаһ» атымда,
Эттән түбән алар минем катымда.

Тузаннан да минем алда вак алар,
Алармы соң мине сагышка салар?

Каршы торып, мине юлдан аерма,
Киңәш бу, дип, аякка балта орма.

Ярый, барма, үзең утыр өеңдә,
Калса калсын янында Рөстәмең дә.

Утырыгыз күзәтеп монда илне,
Иран өчен тыныч тотыйм күңелне.

Әгәр хөкмем җәйсәм Мазандиранга,
Җиңү яулап кайтармын сезнең янга.

Әгәр бер хәл була калса бу яуга,
Безне ягъни дию салса богауга,

Сорап ярдәм, салырмын сиңа адәм,
Шунда юлга төшәрсең син йә Рөстәм.

Ә хәзергә авыз да ачыр булма,
Карарым бер: хәзер үк чыгам юлга».

Заль, уфтанып, башын түбәнгә салды:
«Сиңа әйттем күңелемдә ни барны.

Колларың без, син — хуҗа безгә, син — шаһ,
Ни боерсаң, «Баш өсте!» — безнең җавап.

Ни теләсәң, ни боерсаң, синең эш...
Ахыры тик... булсын иде... сөенеч.

Килер берчак, мине искә алырсың,
Тотмаганга киңәшем, уфтанырсың.

Әрнеп-сызлап үкенерсең бу эшкә,
Файда булмый соңгарган үкенечтә».

Җир үпте дә сарайдан чыкты Дастан,
Килде аның алдына бер пәһлеван,

Диләр: «Юкка борчыдык үзегезне,
Булмас эшкә көчли шул патша безне.

Уйлый идек: синең сүзне ишетә,
Аңга килә, акыл белән эш итә.

Кеше сүзенә бикләгән колагын,
Уйламый шаһ эшенең төрле ягын.

Ярый, тәкъдир язганын без күрербез,
Син — Иранда, шөкер, имин өебез».

Кәвыс шундук дәште Гударз, Тусны:
«Гаскәрләрне яуга күтәр!» — дип кушты.

Кулларына бирде мул хәзинә, мал —
Мал мул булса, яуда җиңел була хәл.

Гөргин улы Миладны шаһ чакырды,
Аңа барлык ачкычларны тапшырды.

«Булсын,— диде,— синең хөкмеңдә Иран,
Әгәр дошман һөҗүме булса, әй җан,

Ярдәмчедер сиңа Рөстәм белән Заль,
Кеше җибәр, аларны чакыртып ал.

Барлык эшләрне китереп җиренә,
Тәхеттән шаһ күчте ат ияренә.

Иртә таңнан гаскәр шәһәрдән акты,
Купты тузан, күренмәс булды якты.

Артык гаскәр саны сахра комыннан,
Шау-шу, тавыш гүли, быргы, барабан.

Батырлыкта галәмгә чыгарган ат —
Алгы сафта атлый Гударз, Тус, Гишвад.

Ялгап төнне көнгә, баралар алга,
Ирештеләр якын Мазандиранга.

Шаһ чатыр корды Әспируз тавында.
Батырлары җыелдылар табынга.

Сөзеп затлы шәраблар бокалларга,
Корып мәҗлес, бирде шаһ ял аларга.

Иртән Гивны шаһ чатырга чакырды:
«Хәзер үк ал,— ди,— ике мең батырны,

Кылыч, сөңге, гөрзиләр алып янга,
Юл ачыгыз безгә Мазандиранга,

Күргән бер өйне әйләндер учакка,
Уйлап торма: бусы — байлык, бу — бакча!

Калтырансын дәһшәтең күреп илләр,
Илен ташлап, куркып качсын диюләр.

Өркүеннән үте шартласын җеннең,
Пәриләрне шүрләтсен хәтта җилең.

Чыкты батыр чатырдан, кул үпте дә,
Пәһлеваннар сайлап алды күп кенә,

Кузгалдылар. Кереп Мазандиранга,
Бара алар дәһшәт салып һәр җанга:

Кая ирешсә, кылычы түкте кан,
Куркуыннан җен-пәриләр бирде җан.

Илне турап таптады кара җиргә,
Шәһәрләрне әйләндерде күмергә.

Кайда күзгә ташланса бер хәзинә,
Кырып талап алды аны үзенә.

Җәннәттәй бер җиргә килеп чыктылар:
Шарлап ага һәр якка татлы сулар,

Кеше буе печән үскән болынлык,
Шау чәчәктә, күрсәң хәйран булырлык;

Көтү-көтү сыер, сарык, киек, ат
Көтүчесез болында йөри утлап;

Сайрый кошлар күктә, җирдә, үләндә,
Җаннар рәхәт тойды моны күргәндә.

Аяк баскан борылып китә алмас,
Була алмас җәннәт моңарга алмаш.

Менә алда — гүзәл шәһәр. Таң калып
Калды гаскәр, ихтыярсыз тукталып:

Халкы көләч, гүзәлләр, күз таң кала,
Бер караш, бер наз белән йөз җан ала.

Хәбәр язып салды шундук Гив шаһка,
Юлыктык, дип, без җирдәге оҗмахка.

«Кан түгүдән зарыккан,— ди шаһ,— халык,
Ял итик бер, бу «оҗмахка» тукталып».

Күреп, шаһ та хәйран калды бу җиргә,
Укый рәхмәт хәбәрче җырчы иргә.

Бер атналар торды шәһәрдә гаскәр,
Алтын-көмеш җыйды туйганча бәкләр.

Хәбәр җитте Мазандиран шаһына:
«Кәвыс басып керде җир оҗмахына.

Үләт чире кебек кыра халыкны,
Утка яга шәһәр, авыл, байлыкны».

Бу шаһның бар хезмәтендә бер җене.
Чакыртты ул шул явызны — Сәнҗәне.

«Хәзер үк,— ди,— оч Ак дию янына,
Чара күрсен минем бу дошманыма».

Мазандиранда бар иде бер дию, —
Тик яраша аңа Әхриман дию.

Баштанаяк кар кебек ак иде ул,
Бар диюгә шул явыз күрсәтә юл.

Тауны кисәр кылыч үтмәс тәненә.
Хәзер утыз мең дию хезмәтендә.

Бар пәриләр Каф тавыннан һәр таңда,
Сорап хезмәт, килә аңа сәламгә.

Мазандиран шаһына дус иде ул,
Чит затларга кисә ул бу илгә юл...

Ишетеп ул Кәвыс явызлыкларын:
«Укытам,— ди,— боларга сабакларын!

Син, Сәнҗә,— ди,— хәзер кайтып шаһка бар,
Яу бар диеп борчылмасын ул, зинһар.

Тар күрсәтәм Кәвыска киң җиһанны,
Оныттырам аңа Мазандиранны».

Ул җар салды. Тутырды бар һаваны
Дию, пәри, җеннәрнең пәһлеваны.

Алар өрде сихри әфсен һәрьяктан,
Көн төн булды, атмас кебек якты таң.

Берсен-берсе күрмәс булды һәр адәм,
Җәһәннәмгә батты гүя бар галәм.

Шундый салкын бәрде тәнгә һәрьяктан,
Гүя бозга әйләнде тамырда кан.

Ява яңгыр кебек күктән җиргә таш —
Чыгара күз, сындыра кул, яра баш.

Тел озата бәкләр Кәвыска анда:
«Эзләгәнең таптың Мазандиранда».

«Җилгә очты атлар, качыр хәзинә!»
«Сынык икмәк табалмассың үзеңә!»

Атна буе яуды башка таш яңгыр,
Кешеләрдән кайтарды үч шайтан бер.

Шунда дию ярсып әйтте Кәвыска:
«Әй оятсыз, ят вөҗданга, намуска,

Эшнең уңын-сулын уйлый белмисең,
Шаһмы соң син? Башы юк зат, ирме син?

Ни гаебен таптың Мазандиранның,
Тиде илгә сансыз зарар-зыяның.

Сыешмадыңмыни анда Иранга,
Нәфсең суздың безнең Мазандиранга.

Шул баш белән шаһ булмакчы дөньяга?!
Минем атны ишетмәдеңме анда?

Таянычың кая? Җилме? Оятсыз!
Яу күтәреп калдың тәхетсез, атсыз».

Бәйләтте дә дию шаһны, бәкләрне:
«Атыгыз,— ди,— зинданга имгәкләрне!»

Караңгы бер базга илтеп аттылар,
Унике мең куйды дию-сакчылар.

Көнгә тузан кадәр икмәк тамакка,
Калды болар чыдап булмас газапка.

Алып килгән һәм таланган хәзинә,
Ак диюнең кирәкмәгәч үзенә.

Озатылды Мазандиран шаһына:
«Дошман җитте,— диегез,— үз башына.

Кайсын кырдым, кайсысын тоткын иттем,
Иран бәкләрен үзеңә кол иттем,—

Синең барлык үчең алардан алдым,
Барсын бәйләп, кара зинданга салдым.

Тотып алдым, тик кырмадым берочтан,—
Һәркөн саен мең үлсен куркынычтан».

Ә зинданда бәкләре белән Кәвыс,
Калып бичаралыкка, чигә сагыш:

Китте ирек, туклык, юк көн яктысы,
Күңелләрдә сүнгән өмет чаткысы.

Бер чапкыны бар иде шаһ янында,
Туктаталмас бавың да, зинданың да:

«Очасыңмы, китәмсең җир астына,
Һәм ничек тә иреш Забулстанга.

Хәбәр җиткер хәлебездән син Зальгә,
Барын сөйлә, тарыдык нинди хәлгә.

Бүген тик син безгә өмет, таяныч,—
Ди шаһ,— зинһар, тырыш, гайрәттә ян, оч.

Әйт син Зальгә: хәтерлим бар киңәшен,
Үкенәм, тик ни чара — үткән эшем.

Кара бәхетем бәйләде күзне башта,
Бу көннәрне китерде соңра, башка:

Кулдан китте тәхет, гаскәр, хәзинә,
Коллык, зиндан язмыш булды үземә.

Ач тән богаулы, күптән тайган хәлдән,
Телим җаным тизрәк чыкканын тәннән.

Безгә мәңге котылу юк зинданнан,
Ярдәм кулын сузалмасаң син аннан,

Сиңа, Рөстәмгә ялвара барыбыз:
Зинһар, безне бәладән коткарыгыз!»

Кара хәбәр ирештe килеп Зальгә,
Утлы хәнҗәр кадалды гүя җанга.

Ачу белән күлмәген тартып ертты,
Үз башына учлап туфрак ыргытты:

«Бу бәлане ничек китәрик баштан?..»
Үз янына улын чакыртты Дастан.

Диде: «Гамьнән йөрәгем парә-парә,
Бер өметем — син табалмамсың чара?

Калдык Галәм алдында без оятка,
Гарьдән җиңел үзеңне ату утка.

Дию колы булып яшәсә Кәвыс,
Кала аяк астына безнең намус.

Сиңа Алла куәт бирде, батырлык,
Егет чагың, тауны-ташны ватарлык.

Тәңре синдә күрсәткән бер кирамәт:
Сине күрсә, диюдән китә гайрәт.

Монда утырма, эчмә бер йотым су,
Анда, диюканында, бар, кулың ю.

Көчең белән сихерчеләр кулын тот,
Гайрәт белән җеннәрнең җанын куркыт.

Ачу белән кулга алсаң син хәнҗәр,
Дию усак яфрагы кебек тетрәр.

Кем генә соң шаһы Мазандиранның,
Юлын буарга синдәй пәһлеванның?»

Диде Рөстәм: «Баш өсте, бойрык — синнән,
Җан бирәм, тик йөз чөермим сүзеңнән.

Үләрмен, дип, тузанча чикмимен гамь,
Үләр өчен кылә дөньяга адәм.

Йә мин алам җен-пәри башын, җанын,
Йә шул юлда түгәм соң тамчы каным.

Әрҗәң шаһын, дивләрен, Сәнҗәсен
Калдырмыймын, юк итәмен һәммәсен».

Җавабына улының Заль куанды,
Күңелдә бер яңа курку уянды:

«Син җиткәнче, бетсә Кәвысның эше,—
Күпме генә ач яши ала кеше?

Юл әйләнгеч, озын Мазандиранга,
Ә бит үзе күрше генә Иранга,—

Ике атна ком-таш, сусыз далада,
Сәмум ерып, кем генә соң барала?

Үлән үсми. Ә сәмумга ни чара?
Анда нинди батырың да бичара.

Тәвәккәл ит Ходага, шул юлга төш,
Канатың бар — җилдән дә җитез Рәхеш.

Йөре, михнәт чиксәң дә, гамь түгелдер,
Михнәт чикмәгән зат адәм түгелдер.

Ә мин көн-төн күтәрәм кул догага,
«Балам кайтсын!» — дип ялварам Ходага.—

Кочып улын, Заль бәгыренә басты.—
Улым, безнең җанга ялкын тоташты.

Атаңның бу күз яшьләрен онытма,
Безне калдырма җирдә ялгызлыкка.

Синең йөздән ала нур безнең күзләр,
Ай йөзеңнән аерым без — үксезләр».

Хушлашырга Рудабә килеп җитте,
Күзләреннән канлы яшьләрен түкте:

«Кемгә мине ташлап китәсең, балам?
Синсез мин ич сулам, шәм кебек янам».

Аны кочып: «Изге әнкәм,— ди Рөстәм,—
Куеныңнан мин дә мең әрнеп китәм,

Язмыш — бурыч, мине синнән аера,
Теләктә тор, ялварып Ходаеңа».

Килеп, Миһраб кочты-үпте оныгын:
«Мин дә барыйм, күтәрим сөңгең-угың.

Кол итеп ал — кирәк атка көтүче,
Миңа яусын явыз дошманның үче».

«Сезнең изге теләкләр миңа юлдаш,
Мамык булырлар, әгәр юл булса таш»,—

Дип, Тәһмәтән кочты-үпте аларны.
Көбә киде, бәйләде коралларны.

Иеп ата-анага баш, менде атка.
Рәхеш аны алып очты еракка.

Ике көнлек юлны бер көндә ала,
Көн-төн дими, Тәһмәтән алга бара.

Саба җиле җитә алмый артыннан,
Күләгәсе ерак калган атыннан.

Җилә Рәхеш таулар-ташлар эчендә,
Ачыккачтын, беренче көн кичендә

Тауда Рөстәм бер киек алды атып.
Учак якты, атын ялга туктатып.

Пешерде дә тәмләп киек кәбабын,
Ашап, батыр тукландырды тамагын.

Тагын китте, бер камышлыкка җитеп,
Йоклап алмакчы булды ул, ял итеп.

Ага чишмә челтерәп, сайрый кошлар,
Тынлыгыннан рәхәтләр таба һушлар.

Рәхшен куеп җибәрде дә утларга,
Ятты Рөстәм тынычланып йокларга.

Камышлык тын,— кермәгән кеше юлы,—
Эче аның мең төрле җанвар тулы.

Арысланнар — бу тынлыкның сагында,
Якын килми кеше алар барында.

Арада бар бер килбәтсез арыслан,
Күрсә, аждаһа куркудан бирер җан.

Чит-ят исләр бәрде сизгер борынга,
Юлыкты ул, килеп шушы урынга.

Күрә: кеше йоклый, йөри ат утлап,
Ат өстенә атылды, тормый туктап.

Яшендәй тиз чәпчеп, борылып артка,
Ике аяклап типте ерткычка ат та.

Баш ярылып, арыслан ауды җиргә,
Тотынды ат тешләп аны чәяргә.

Шау-шу Рөстәмне уятты, күтәрде.
Китә язып һуштан, күреп бу хәлне,

Диде Рөстәм: «Нинди һөнәр! Ни йөрәк!
Мондый һөнәр, малкай, сиңа ник кирәк?

Аның исме — «арыслан» ич, синең — «ат»,
Тиң буламы бу ике? Миңа кыйбат —

Синең саулык, дустым-атым зыяны
Тар итәчәк миңа бу киң дөньяны.

Син булмасаң, кем күтәрала мине,
Бу тәнемне, көбәмне, бу гөрзине?

Чакыр гына, килеп җитәм мин ыргып,
Күрер идең, торыр идемме куркып.

Көн күрсәтмим синең дошманнарыңа,
Теш тидертмим җирдә синең каныңа.

Синсез калсам, баткандай бу яланга,
Кем илтала мине Мазандиранга?»

Кочып атын, үпте ике күзеннән,
Суда юды канын тәне-йөзеннән.

Атланды да кабат ул төште юлга,
Юлы керде очсыз-кырыйсыз чүлгә.

Һава — ялкын, җир гүя кызган таба,
Ут — киемгә, гүя ут чәчкә каба.

Бар җир янган, күренми — корган үлән:
«Ярабби,— ди Рөстәм,— тагын ни күрәм?»

Бара да ул, бара, чүлнең юк чиге,
Үзе арды, ат авардай йончыды:

«Бу дәрткә соң дәрман табармын кайдан?»
Күрә Рөстәм: инде бичара хайван

Телен салган, сөйрәлә ава-түнә,
Батыр үзе җәяү барырга күнә.

Төште аттан. Сөйри атын башыннан,
Кара бәхетен кичерә карашыннан:

«Нидән соң мин юлыктым бу бәлагә?
Батыр гәүдәм комда аунап кала ла».

Һәр чарадан җаны бичара калды,
Тезләнде ул, күккә ялвара калды.

Диде: «Миңа бер күзең сал, Илаһым,
Түгел яшерен синнән хәлем, зар-аһым:

Үләм ләса, күңел калды куркуга,
Юлыктыр син мине бер йотым суга.

Синең рәхмәтеңдә тик бар өметем,
Ярдәмең бир, мин дә максатка җитим:

Йолып алыйм бәкләрне һәм Кәвысны,
Җәзалыйм бар сихерчене, явызны.

Корылыктан теленде ләса телем,
Тәнем яна, күрәмсең минем хәлем?»

Хәлсезләнеп, ул шунда ауды комга,
Калды хәл тик соң кат күзне йомарга.

Шунда Рөстәм күреп калды: еракта
Киек чабып китеп бара бер якка.

Диде: «Сусыз җирдә ич яшәми бу!
Димәк, шунда, кайдадыр якында су!»

Атын сөйрәп киек артына төште,
Озакламый алар суга ирешге.

Үзе эчте, туймастай эчте аты,
Сизмәгән дә карны ачыкканын каты.

Ауга чыгып атты киек, атты кош,
Ашап-эчеп, моң күңелен итте хуш.

Талып тәне, йокы төште күзенә,
Әйтте атка: «Дошман килсә, үземә

Хәбәр ит син, зинһар, үзең көрәшмә,
Синсез калу миңа ул җиңел эшме?» —

Сөйли-сөйли шуны, ауды йокыга.
Түзә алмый авыр юлда йончуга.

Йөри Рәхеш хәтфә үләндә утлап,
Ята Рөстәм рәхәтләр сизеп йоклап.

Килми каплан, арыслан бу чишмәгә,
Җанвар кача — һәм бу түгел тикмәгә:

Бу чүл-сахра бер аждаһа милке иде,
Җан иясе шул явыздан өркә иде.

Аудан кайтып, ул «кунакка» ярсыды,
Койрык белән чүлгә сипте бар суны.

Уйлый атны сулыш белән йотарга,
Ярдәм эзләп ташланды ат батырга.

Шундук Рөстәм чәчрәп торды аякка,
Ачу белән күзен салды як-якка.

Күрә: артында аждаһа, килбәтсез,
Үзе таудай, тырнак — урак, иләмсез.

Аңа Рөстәм шундый итеп бакырды,
Бу тавыштан җир озак тетрәп торды;

Кылыч алып йөреде аңа каршы,
Гүя алда — тәнсез шәүлә карасы.

Диде Рөстәм: «Бармы синең сүз-атың?
Нигә килдең, ник каныңа сусадың?

Әйт исмеңне, башыңны кисәм аннан,
Бу кылычым бер кансын синең каннан».

«Сиңа нигә,— ди аждаһа,— минем ат,
Кирәксә җан, миңа ялвар, иман сат,

Сиңа атым атарга гарьләнәм мин,
Әйтим инде, белеп тор, мин — Дәҗхим.

Бу утлак һәм сахралар минем милкем,
Аяк монда басып, җан коткарган кем?

Очып чыпчык үтми моннан җәзасыз,
Курка монда салырга йолдыз да күз.

Кая, син дә әйтче миңа үз атың,
Бу тәмугка керүдән ни моратың?

Күрерсең син сугышын аждаһаның,
Түгәчәк яшь синең өчен карт анаң».

Диде Рөстәм: «Озын-озак лаф орма,
Тарыдың син мәшһүр Рөстәм батырга,

Атам — Заль; Сям, Нәриман — миңа баба,
Мин ул башыңа күктән иңгән бәла.

Син аждаһа түгел ул, мин — аждаһа,
Кылыч алдым сездәйләргә җәзага».

Котырынды аждаһа бу сүзләргә,
Күлдәй тулды зәһәрле кан күзләргә.

Алар, ярсып, бер-берсенә ташланды,
Ике арада авыр көрәш башланды.

Кылыч белән иреште бергә аты,
Теше белән йолка еланны каты.

Йолка, ерта, талкый явыз тиресен,
Түгел Рөстәм, көрәшә ат диярсең.

Моны күреп, батырга үсте канат,—
Елан башын кисте кылыч, чапкалап.

Бәреп җиргә койрыгын, ул бирде җан,
Ташу булып, дала йөзен басты кан.

Зәһәрле кан җиткән җирдә яна кыр,
Хәтфә утлак урны кала тап-такыр.

Хәйран калып, Рөстәм тиз китте аннан,
Кылычыннан тамып бара кара кан.

Бите-кулы буялган иде канга,
Дәшә чишмә, рәхәтләр биреп җанга.

Юды кулын, кылычын анда каннан,
Шөкер итә Тәңрегә ихлас җаннан.

Коендырды атын, юды, пакьләде,
Аны үпте, назлады, кочаклады:

«Батыр аты! Үзең дә чын баһадир,
Минем җан да сиңа җитмәс бәһадер.

Булып шулай һәр эшемә ярдәмче,
Яшә заман ахыры җиткәнгәче!»

Оча алга, атлана да атына,
Барып керә сихернең ватанына.

Күреп Рөстәм ул илне, калды хәйран:
Һава — һушбуй, җире — җәннәт, гөлстан.

Килеп чыкты гаҗәп бер гөлбакчага:
Челтер-челтер төрле якка чишмә ага,

Шау чәчәктә балкып үсә агачлар,
Куакларда сайрыйлар сандугачлар;

Чишмә яры — чәчәк күләгәсендә —
Табын, бер җан да юк әйләнәсендә;

Якут бокалларда кыйммәт шәраблар,
Табын тулы төрле сыйлар, кәбаблар.

Бу табынга күзе төшеп, таң калып,
Авыз суын йотты Рөстәм, тукталып.

Аттан төште. Атын җибәрде утка,
Сыйны карый, тукталып бер минутка:

«Шөкер итеп бетәрлек түгел Хакка,—
Диде,— ризык очып тора тамакка.

Кем пешергән? Ә менә кемгә язган!
Бир арттырып килер көндә дә Яздан!

Сихерчеләр эше булса да бу эш,
Мондый ризыкка үтә ул минем теш».

Авыз итә һәммә ризыктан бер-бер,
Тамак туйды. Күрә алдында танбыр.

Алып кулга, чиртә аның кылларын,
Көйли башлый сагыну-сагыш җырларын:

«Яшимен мин дөньяда, көнем кара,
Бәхетсез мин бар сукбайдан, бичара.

Минем урным — яу, дау кыры, кан кыры,
Тау-таш, сахра, ком чүленең такыры.

Юлым кисә дию, шайтан, аждаһа,
Буран кыйный битне, башка таш ява.

Сугыш өчен мине Хода яраткан,
Ярый әле, саклый оят, ярадан.

Бу дөньядан өлешем дәрт йә гамьдер,
Заман бүләге миңа шул бәламдер».

Шәраб эчә дә суза шул җырын ул,
Җырга сала сагыну-сагыш моңын ул.

Сихерчеләр иле иде бу яклар,
Бу якларга аяк басалмый ятлар.

Бозалды тик Рөстәм болар тозагын,
«Каралтты бу безнең данны — йөз агын,—

Диде илгә мәшһүр убыр карчыгы,—
Сихернең ич безнең кулда бар чыны...»

Бу чирканыч карчык мәшһүр бар илгә,
Төс үзгәртеп керә бәлә мең төргә.

Гүзәл бер кыз рәвешенә керә ул,
Батыр янына чыгып күренә ул.

Сораша хәл Тәһмәтәннән, назланып,
Сагышлы җан, назга сабырсызланып.

Бу гүзәлгә соклана, дәрттә яна:
«Ничек шөкер итмисең,— ди,— Аллага.

Табын бирде, танбыр бирде, инде — кыз».
Алла исмен ишетүгә, ул явыз

Кисәү кебек кинәт каралып калды,
Сихер көче изге сүздән югалды.

Рөстәм шундук элмәкле аркан атты,
Бу явызның муйнына аркан такты:

«Буам, явыз, күрен үз төсеңдә, тиз!»
Һәм элмәктә чүгеп Тәһмәтәнгә тез,

Тыпырчынды чирканыч бер хәшәрәт.
Кылыч төшереп башына ничә рәт,

Аны җиргә таптады да Тәһмәтән,
Бу урыннан ярсып җилдертте атын.

Юл йомгагын урап чапты да чапты.
Шулай менә көтмәгәндә берчакны

Караңгылык иленә ул юлыкты —
Күз алдында күрмисең ак яулыкны.

Гүя кояшны япканнар зинданга,
Олаккан ай-йолдызлар да бер янга.

Күзгә төртсәң күренмәс, һәрьяк кара.
«Ул афәттән коткарса, ат коткара»,—

Диде Рөстәм, тезгенне куйды кулдан,
Килә Рәхеш баргандай якты юлдан.

Тәвәккәлләп шулай байтак юл басты,
Күренми, алды димим, аяк асты.

Килеп чыкты, ниһаять, якты кырга,
Тыныч болын, сәбәп юк һич куркырга.

Ага сулар, кош-корт сайрый, саф һава,
Чәчәк исе — күңелгә каймак, дәва.

Суга баткан иде тирләп Тәһмәтән,
Су керде ул, сизеп оҗмах рәхәтен.

Атын юды. Аңа да су эчерде,
Каршы якта шау чәчәк утлак күрде.

Зәвыкланып чәйнәрсең,— шундый печән.
«Ял итсен бер утлап шунда бу кичен»,—

Дип, атын ул җибәрде дә болынга,
Талды йокыга, авып бер урынга.

Каравылчы күреп ят атны кырда,
Килде чабып, күрде: Рөстәм — йокыда;

Ә ат, ярсып, утны урыпмы ура,
Чәчәк болын булып кала кап-кара.

Коты очып, сакчы карап торды да
Төшерде бер камчы Рөстәм сыртына.

Урыныннан ярсып торды Тәһмәтән,
Диде сакчы Рөстәмгә: «Син, әй адәм,

Үзең икмәгән җиргә ник куйдың ат?
Бу җирләрнең хуҗасы — патша Әүляд.

Чәчәк болынын таптаттың патшаның,
Сораячак хакын синнән патша аның...»

Бу янаудан Рөстәм тормады куркып,
Алды аның ике колагын йолкып.

Биреп сакчы колакларын кулына,
«Хәзер,— диде,— ычкын килгән юлыңа!»

Елап, сакчы чапты патша алдына,
Килде әрнеп, сакалын йолка-йолка.

Диде: «Анда берәү, буе манара,
Куркыр дию дә йөзенә карарга.

Хур иттергән чәчәк болынын аттан,
Мине менә мәхрүм итте колактан».

Сугышкак, яшь, батыр ир иде Әүляд,
«Җиңелмәс» дип казанган иде ул ат.

Җыйды шундук барлык батырларын ул,
Чәчәк болын ягына алдылар юл.

Күрә Рөстәм бервакыт: каршы яктан
Тузан болыты калыкты ерактан.

Тотып Рәхшен иярләде, киенде,
Коралланып, яуга дип, атын менде.

Ул арада килеп җитте Әүляд та,
Диде: «Кем син? Тиз бул, исемеңне ата!

Нигә сораусыз чит илгә керәсең?
Тәкъдиреңдә бар икән шул күрәсең.

Ябышасың сакчының колагына,
Сусагансың, күрәсең, үз каныңа».

«Сорама,— ди Рөстәм,— минем исемне,
Исмем ишетсәң, җуярсың исеңне.

Минем исмем — дошманнарга бәладер,
Аны ишеткән тәкатьсез каладыр,

Ишет: мин ул — филтән Рөстәм, Тәһмәтән,
Сиңа кем дип исем кычкыртты атаң?

Кәфен тегеп, еларга тапкан анаң,
Гаскәр белән куркытыргамы чамаң?

Кем икәнемне хәзер белдерәмен,—
Җиһан халкын үзеңнән көлдерәмен».

Болыт кебек яудыручы җиргә кан,
Әбдәр кылыч чыгарды ул кыныннан.

Тауны ярыр икегә, тауга тисә,
Менә инде ул дошманнарны кисә.

Кизәнсә бер, ике кешене яра,
Булды сарык көтүе бу яу аңа.

Өркеп, төркем-төркем алдан качалар,
Коты очып кычкыралар ачы алар.

Атын Рөстәм Әүляд артыннан сала,
Ташлап аркан, иярдән йолкып ала.

Төшеп аттан, хәнҗәр куйды муйнына,
Тыпырчынып, керердәй җир куйнына,

Әүляд ялвара: «Кызган, әй пәһлеван,
Канымнан кич, калсын тәндә кошча җан,

Колың булыйм алдыңда, хезмәтеңдә,
Хуҗа кеше үтерми ич этен дә».

Диде Рөстәм: «Сорауларым сиңа бар,
Турылыгың шулар белән сыналыр:

Ак дию өненә миңа юл күрсәт,
Кайда тоткын ителгән Кәй-Кәвыс, әйт.

Мине шунда илтәлсаң, котылырсың,
Хәтта үзең шул илгә шаһ булырсың».

«Баш өсте,— ди Әүляд,— мин, тере куйсаң,
Колың булам, үтим нәрсә боерсаң.

Минем кулда — бу якның бар хәбәре,
Ни сорасаң, сиңа ирешер бары.

Сиңа күрсәтәм диюнең ятагын,
Кисәсеңме аның башын, аягын.

Илтәм сине Кәвысың зинданына,
Ни боерсаң, әзер торам барына.

Унике мең дию саклый зинданын
Кәвысыңның, шуны онытма, җаным.

Пулат һинди аларның башлыклары,
Биду, Сәнҗә — шул сакта тора бары.

Ул якларга барыр юллар хәтәрле,
Ничә йөз мең батыр ерып үтәрме?

Бу җирләрдән җен иленә йөз фәрсәх[1],
Юлы тау, таш, сусыз. Тик кичеп барсаң,

Юлыгасың ерткычлар тырнагына,
Йөз-мең дәһшәт ява анда җаныңа.

Мазандиран шунда тота фил явын,
Һәрбер филе аударырлык бер тавың.

Ә беләмсең шаһын Мазандиранның?
Галәмдә юк сихерен, көчен аның?

Кулга ала камчы — була аждаһа,
Сулышы — җил, күзе белән ут яга.

Хезмәтендә мең җирдә мең дию бар,
Ә син — ялгыз, бармыйк ул якка, зинһар».

Аның сүзен ишетеп көлде Рөстәм:
«Ялгыз да мин алар башына җитәм.

---

[1] *Фәрсәх* — үлчәү берәмлеге.

Бөтен дөнья булса сихергә тулы,
Белмимен мин һич алардан куркуны.

Курыкмыймын диюдән, Әхриманнан,
Юлдан кайтмыйм, яхшысы — кичәм җаннан.

Алла мине үзе саклый алардан,
Җирдә минем көч өстен башкалардан».

Кузгалдылар. Карамый юл кыенга,
Дими көн-төн, кудылар атны алга.

Менә алда инде Әспәруз тавы,
Шунда тар-мар булды Кәвысның явы.

Кояш батты. Бер далага чыктылар,
Алда — яна сансыз утлар, чаткылар.

Диде Рөстәм: «Бусы тагын ни шаукым?
Бу нинди ут? Бу ят илдә патша кем?»

«Бу — сакчылар. Барсы — дию. Йокысыз
Утлар ягып юл саклыйлар, куркусыз.

Әрҗәң дигән явыз патша аларга,
Яши дәһшәт салып аждаһаларга»,—

Диде Әүляд. «Алай икән,— ди Рөстәм.—
Ятып йоклап алырга вакыт җиткән».

Күңеле тыныч, диюләр юк та кебек.
Үсеп торган бер зур агачка килеп,

Аркан белән Әүлядны бәйләп куя,
Үзе, ятып, шундук тала йокыга.

Кояш белән батыр бергә калыкты.
Килеп, баудан азат итте Әүлядны.

«Син,— ди,— зинһар, ачуланма бу эшкә,
Саклык кирәк, кем зур эшкә керешсә».

Атка менде, кораллар тагып билгә,
Яшен кебек атылды дошман илгә.

Әрҗәң явызны чакырып көрәшкә,
Бер җар салды шунда Рөстәм бар көчкә:

Гүя шартлап өзелде күкләр бавы,
Ишелгәндәй булды Әспәруз тавы,

Гүя ас өскә айкалды океан,
Шартлап гүя җимерелде дөнья, заман.

Калтыранды куркып Әрҗәң йөрәге,
Гүя өзелде үзәге — терәге.

«Бу дәһшәтле аваз,— ди,— кем эше ул?
Кот чыгара шаулап нинди кеше ул?»

Куышыннан чәчрәп тышка чыкты,
Тәһмәтәнне күреп, каршы ашыкты.

Алмый Рөстәм кулына гөрзи-кылыч,
Каршы килә, салып дәһшәт, куркыныч.

Колагына ябыша да ул барып,
Әрҗәң башын ала өзеп-кубарып.

Бәрә башны диюләрнең өстенә,
Коты чыгып, юл бирми бер-берсенә,

Туган таптый туганын, ата — улын,
Дию халкы качарга тапмый юлын.

Котылганы Рөстәмнең гөрзиеннән
Юк булдылар Мазандиран иленнән.

Килеп шундук Рөстәм Әүляд янына:
«Юл күрсәт,— ди,— Кәвысның зинданына».

«Ерак түгел Кәвыс яткан зиндан да,
Шул бүген үк барып җитәрбез анда»,—

Диде Әүляд. Кузгалдылар җилдереп.
Кәвыс исен сизде Рәхеш иң элек.

Алар яткан илгә якын килгәч тә,
Ярсып кешнәп җибәрде ул бар көчкә.

Тавышыннан Кәвыс танып Рәхешне,
Шул минуттук аңлап ала да эшне,

Куанычтан ыргып аякка баса:
«Сөенче! — ди,— Рөстәм килде ләбаса!

Кешнәгән ат — аның Рәхше, мин таныйм,
Котылдык без, инде нигә уфтаныйм!»

Сикерешеп торды барсы аякка,
Өмет белән күз салалар як-якка.

Ул арада килеп җитте Рөстәм дә,
Күреп шаһны, бетте арулар, гамь дә.

Үбә Кәвысның кулын, соңра тезен,
Аның алдында җиргә сөртә йөзен.

Шуннан соң тик Рөстәм тора аякка,
Бере-берен үбеп ала кочакка.

Күрештеләр, куаныштылар алар,
Килеп бер-бер күрешә пәһлеваннар.

Сораша шаһ юл хәлен, ил хәлләрен —
Иран, Нимруз, Забулың һәм Зальләрен:

«Һаваланып, колак салмыйча Зальгә,
Күрәсең,— ди,— тарыдым нинди хәлгә.

Ул гынамы? Бер сихерле ут өреп,
Күз нурымны дию куйды сүндереп:

Бу, ди явыз, безнең ил тутиясы[1],
Юк мәлгуньнең ояты йә хәясы[2].

Бу дәртеңә, диде, бар тик бер дәрман:
Ала алсаң Ак дию бәгъреннән кан.

Булыр булса, бу дәрман синнән булыр,
Күземне ач, минем теләгем шулдыр.

Безне калдыр, шул диюгә чара тап,
Ярдәм бирсен бу юлыңа да Яраб.

Кирәк булыр җиде тауны кичәргә,
Һәр адымың тулы дию, сихергә.

Булыр алдыңда, кичсәң, зур мәгарә,
Юлыгырсың шунда син ул каһәргә.

Башын кис тә китер бәгъренең канын,—
Шунда гына тынычлык табар җаным.

Күзләремә минем Галәм караңгы,
Китермәсәң табып шул тамчы канны.

Ашыга күр, зинһар, әле ул ләгыйнь
Синең җиңү хәбәреңне алмаган.

Әгәр белсә, бар диюгә җар сала,
Исәр җилдәй, зинһар, бик тиз барсана».

Кулын үпте Кәвыс шаһның Тәһмәтән:
«Күрсәм тагын шулай Алла рәхмәтен,

Һәлак булыр кулымнан дию, шайтан,
Бойрык-фәрман гына булсын тик шаһтан.

---

[1] *Тутиясы* — бизәнү әйбере.

[2] *Хәясы* — тәртибе, әдәп-холкы.

Җиһанны,— ди,— җен-сихердән итәм пакь,
Диюләрнең өстенә өям туфрак.

Юл күрсәт!» — дип алды тагын Әүлядны,
Атланды да тауларга борды атны.

Җилә Рәхеш, чайкала җир, тетрәнә,
«Җиде тау»га юлы иреште әнә.

Күрә Рөстәм: пәри, җен — уңда, сулда,
Койма булып басканнар барыр юлда.

Көлтә кебек түшәп юлга аларны,
Мәгарәгә табан Рөстәм юл ярды.

Алда әнә (караудан җан тетрәнә)
Кара тәмуг упкыныдай мәгарә.

Аның эчендә мыжлый дию, җеннәр,—
Гүя тизәккә ябырылган чебеннәр.

Урын күрми басарга анда аяк,
Диде Рөстәм: «Әүляд, син булдың таяк.

Миңа чиксез авыр, дәһшәтле юлда,
Берәр киңәш әйтче, зинһар, бу юл да».

Диде Әүляд: «Хәзергә сабыр ит син,
Кояш, барып, көн уртасына җитсен.

Шунда болар барсы йокыга тала,
Капкаларда сакчылар гына кала».

Төш җиткәчтен, Рөстәм капкага килде,
Кылыч белән сакчылар бәгърен телде.

Дию каны Җәйхуннар булып акты,
Куркып юлыннан диюләр олакты.

Тәвәккәлләп керде ул мәгарәгә,
Дөм караңгы, охшаган җәһәннәмгә.

Караңгыга күзен күндереп торды,
Тора-тора гүя бераз яктырды.

Күрә: алда тау кадәр дию яткан,
Ул чем-кара, ял йоны гына актан.

Баштанаяк ул тимергә киенгән,
Таулар талкан булырлар ул тимердән.

Йоклый явыз. Рөстәм, уятып аны,
Бер җар салды, дер селкетеп дөньяны.

Бу тавышка дию сикереп торды:
«Кем йокымны бүлә? — диеп кычкырды,—

Нәрсә булган минем сакчыларыма?
Ятлар керә йокы бакчаларыма!»

Ул арада дию Рөстәмне күрде,
Зур таш тотып, аңа каршы йөгерде.

«Бу кем соң,— ди,— үз канына сусаган,
Курыкмыйча атлый минем бусагам?

Минем өстән очып үтми бер кош та,
Шәүләм юлыннан кача юлбарыс та.

Суга керсәм, кача аннан крокодил,
Сине монда бәрдеме өермә җил?

Туфырагың монда тарткан күрәсең».
Диде Рөстәм: «Мәлгунь, үзең үләсең!

Йөзең кебек сүзләрең дә чирканыч,
Бармы берәр һөнәрең? Иә, күрсәт көч!

Миннән хәбәр сорама, саклан, мескен,
Кылычымнан котыла алмый һичкем».

Дию, моны ишетеп, утка янды,
Сөременә бөтен Галәм буянды.

Ярсып, җирне тырнагы белән ерта,
Чәчрәтеп ут, тешләрен шыгырдата.

Алып кулга Тәһмәтән дә кылычын,
Дошманына чәчрәде гүя очкын.

Бар көч белән дию биленә чапты,
Бер аягы диюнең өзелеп чыкты.

Явыз үзен Рөстәм өстенә салды,
Тимер кулы биленнән кысып алды.

Бере-берен изә алар кочакта,
Ярсуыннан диюнең көче арта.

Уйлый Рөстәм: «Котылсам бу кочактан,
Юк җиңләсем дөньяда бер көчектән».

Каны агып, көче киткән дию дә
Житте: «Дошман — Газраилем! — диюгә,—

Баштанаяк суйсын иде тиремне,
Тик үтерми коткарсын иде мине,

Эзем булмас кеше яшәгән җирдә,
Бу кочактан фәкать ничек чигәргә?»

Фонтандай кан, яңгыр булып тир ага,
Ләгънәт укый язмышка ул, дөньяга.

Коткара да билен дию кулыннан,
Аны Рөстәм эләктерә ялыннан.

Гайрәтләнеп күтәреп бәрә җиргә,
Дию җанын «эләктерә» хәнҗәргә.

Кисә дию йөрәген хәнҗәр очы,
Күрә дию: хәнҗәр кылычтан ачы.

Дию калды җансыз, таудай өелеп,
Рөстәм аның йөрәген ала телеп.

Аны чыгып йоклатә дә Әүлядка,
Шундук алар кузгала килгән якка.

«Мин,— ди Әүляд,— хәл барынча булыштым,
Хәтәр юллар авырлыгын бүлештем,

Төн буена бәйле тордым тегендә,
Ул бау эзе тәнемдә бар бүген дә.

Мине тоттың, үлемнән азат иттең,
Күңелем шунда, вәгъдә белән шат иттең.

Ирешкәндә максатыңа биредә,
Куандырсаң, үтәп вәгъдәң, мине дә?»

«Ку күңлеңнән юк шикне,— диде Рөстәм,—
Мазандиран сиңа була, дөрестән.

Тазартам да дию, пәридән илне,
Шаһын куып, тәхеткә куям сине».

Кайтып Рөстәм үпте Кәвыснең кулын,
Сөйләп бирде сугышын, җиңү юлын:

«Чабып өздем бер аягын биленнән,
Язгач аяктан, көч китте кулыннан;

Җиргә аттым, хәнҗәр кададым җанга,
Шунда явыз булыгып үлде канга.

Җәһәннәмгә олактырдым да җанын,
Алып кайттым сиңа бәгырен — канын».

Бу хәбәргә Кәвыс куанды хәтсез:
«Синсез дәүләт — коралсыз, шаһ — рәхәтсез.

Рәхмәт һәм дан синең анаң-атаңа,
Тудырганга шундый бала Ватанга.

Мин — бәхетле: юк һич дошманнан гамем,
Рөстәмем бар — тиңсез батыр адәмем.

Инде, зинһар, алып кайткан бәгырьдән
Ике-өч тамчы күзләремә тамыз кан!»

Күз ачылды батыр тамызган каннан.
Шау-гөр килеп мәҗлес кордылар аннан.

Алтын тәхет, алтын таҗ һәм алтын зәр
Бүләк алды бу мәҗлестә Рөстәм Заль.

Җиңү котлап, тотып алтын бокаллар,
Җиде тәүлек бәйрәм иттеләр алар.

«Яуга иртән!» — диде шуннан соң Кәвыс.
Ә иртәсен күтәрелде зур тавыш:

Билдә — кылыч, кулда — гөрзи, сөңгеләр,
Җилгер атларга батырлар менделәр.

Күмеп данга исемнәрен, Иранны,
Кылыч белән тетте Мазандиранны.

Икте алар үлем, дәһшәт бу илгә,
Күрсәтмәде шәфкать хатынга, иргә.

Күренгән бер җанга кылыч чаптылар,
Шәһәрләрне, авылларны яктылар.

Дөрләп коры камышлыктай янды ил,
Кан дәрьясына әйләнде бөтен җир.

Кылыч чабып, батыр беләкләр талды,
Янгыннардан күк корымга буялды.

Диде Кәвыс, яман сулап, ниһаять:
«Җәзаланды сихер-явыз җинаять.

Кан коюны туктатыйк та чак кына,
Илче салыйк бу дәүләтнең шаһына.

Илче булсын акыллы да, батыр да,
Көче җитсен җиңү яулап кайтырга».

Яу эшеннән ял итеп тормый хәтта,
Боерды шаһ шундук язарга хат та.

Алла хөкмен мактадылар иң башта:
«...Җирдә, гүрдә барыбызга ул — патша.

Бойрыгы нык, какшамас таудан, таштан,
Өстен хөкме җирдән, күктән, кояштан.

Берәү баш тарталмый хөкменнән аның,
Ник диюгә сыгынды синең җаның?

Диюгә кем дөньяда баглый өмет,
Җәһәннәмгә кисәү булачак ул эт.

Сихер, дию, җен, пәри — йомышыңа,
Каты кайгы болар синең башыңа.

Ишеткәнсең, җәзасын тапты алар,
Синең башың иртән шул көнгә калыр.

Катмыйм, дисәң, әгәр агу ашыңа,
Калсын, дисәң, исән тәхет, башың да,

Куй дөньясын, тәхет-таҗыңа таш ор,
Бүген минем алдыма килеп баш ор.

Иртән җитмәс филтән явына көчең,
Гафу үтен бездән син бүген кичен.

Әгәр теләр булсаң Мазандиранны,
Башкарасың нәрсә теләсәм аны:

Бу илеңә безне син олы сана —
Хаким итим сине бу улусыма.

Нигә кирәк урынсыз сугыш, лафлар?
Түгел хәтта тиң бер кулда бармаклар.

Уйла: калдың Ак диюдән, Әрҗәңнән,
Алар җанын инде йотты җәһәннәм.

Таянганың шулар иде җиһанда,
Йә, өметең кемдә Мазандиранда?

Кулыңда кем булырлык бар таяныч?
Ашык, баш ор, юкса эшең аяныч.

Батырларың башын өзде батырым,
Үлмим дисәң, тиз тап аның хәтерен.

Пәһлеван юк дөньяда Рөстәмгә тиң,—
Мин кисәттем. Күбәйтмә җирдә ятим».

«Җавап алып кайтасың син бу хатка»,—
Диде Кәвыс шунда торган Фәрһадкә.

Юлга Фәрһад ашыкты, үпте дә җир,
Куа атын, артыннан җиталмый җил.

Үзе охшап давыллы житез җилгә,
Килеп керде Чәрмпай дигән илгә.

Ә кешеләре курыкмас янгыр, кыштан —
Бар халкының аяк-кулы каештан.

Ул аяклар җиргә, гүя — җилемнән,
Ун пәһлеван селкеталмас җиреннән.

Алар кеше җилкәсенә ябышса,
Төшәсе юк, ул зат мәңге ялынса.

Һәвәс барсы сугышка крокодилдай,
Крокодиллар да кача, күрсә, җилдәй.

Афәт булып яши алар җиһанда.
Гаскәр иде алар Мазандиранда.

Килеп, Фәрһад юлыкты явызларга,
Ирек бирми явызлыкка узарга.

Диде: «Киләм илче булып, белегез,
Патшагызга барып хәбәр бирегез!»

Ишетеп, шаһ бойрык бирде аларга,
«Һөнәр» белән илчене каршыларга:

«Күрсәтегез аңа бер-ике «уен»,
Иран безгә иярлек булсын муен.

Кем иң көчле, кысып изсен бер кулын,
Ул шаһына алып кайтсын куркуын».

Иң көчлеләр китте илчегә каршы,
Кәмит карыйк, дип чаба арттан барсы.

Килеп берсе Фәрһаднең кулын кысты,
Бар бармаклар гүя бергә ябышты.

Җитте хәле һушы китеп аварга,
Сулыш каба, аның йөзе агара.

Ул арада кул кыса икенчесе:
«Хуш килдең,— ди,— әй бөек шаһ илчесе!»

Кул кысудан кан сава йөрәгенә,
Шашмый, чыдый йомышка күрә генә.

Сынауларның чыдады ул барсына,
Аны алып бардылар шаһ каршына.

Сораша шаһ аңардан Кәвыс хәлен:
«Ничек килдең? Арытмадымы юлың?»

Кәвыс хатын тоттырды Фәрһад аңа,
Хат укылды. Әрни йөрәге, яна.

«Һәлак булган Ак дию! Әрҗәң корбан!
Аларны бер явыз җан — Рөстәм кырган.

Агудан да ачы аның кылычы,
Кагылыр, аһ, безгә аның бер очы».

Тик Кәвыснең гарьләнде тәкъдименә,
Булды каршы барасы тәкъдиренә.

Ул яздырды шундук җавап Кәвыска:
«Таң калдык без син күтәргән тавышка.

Ике-өч дию үтергән икән Рөстәм,
Мондый югалтудан без чикмибез гамь!

Каннан диңгез ясаса да кылычың,
Бозалмый бу безнең күңел тынычын.

Минем урыным, дәрәҗәм синнән өстен,
Баш ору, баҗ[1] миннән сорыйсың ник син?

Үтең шартлар, гаскәремне санасам,
Дию, җенен җиңү дисеңме асан?

Итәм диңгез, эретеп тимерләрне,
Тыеп торам пәриләрне, җеннәрне.

Кача җеннән адәм һәрбер урында,
Яу күтәрсәм, пыр тузачак Иран да.

Исеңә кил, акылың җый башыңа,
Таянма күп ялгыз бер юлдашыңа.

Яшим дисәң, оныт Мазандиранны,
Курык хәтта төштә күрергә аны».

Җавап хатны алды да Фәрһад чапты,
Котылдым, дип, Кәвыс янына чаклы.

Сөйләп бирде бар ачы күрмешләрен,
Шаһ алдында түгеп әрнү яшьләрен.

Ачуланды булмас сүзләргә Кәвыс:
«Әй егет,— ди,— юк мәллә синдә намус?»

---

*Баҗ* — салым.

Ачуыннан күзләрдә чатнады ут,
Чакырттырды Рөстәмне ул шул минут.

Хатны бирде: «Укы, хәлләрне ишет!
Көчең җитсә, янар уттан тиз эш ит.

Бу хатмы соң? — Хәнҗәр йөрәкне яра,
Ни кылыйм соң? Моңа миндә юк чара».

Диде Рөстәм, көлеп, Кәвыска: «Әй шаһ,
Нигә кирәк бу кадәр газап һәм аһ?

Үзем барыйм, рөхсәт бирсәң, шул якка,
Кулга алыйм кылыч кебек бер хат та».

Куанды шаһ, укый Рөстәмгә рәхмәт:
«Синең белән нык минем тәхет, дәүләт».

Язучысын чакыртты шундук үзе,
Әйтте, булса күпме зәһәрле сүзе.

Әйдә яз: «Әй гаклы зәгыйфь, борны — Каф,
Үз чамаңны белми, миңа орма лаф.

Борчак сипмә, күр котылу чарасын —
Кылычымнан ничек җан коткарасың?

Әгәр миңа ялварып баш иясең,
Сау каласың, башыңа таҗ киясең,

Буйсынмасаң, санап сине бозгынга,
Тәнең телеп, миең бирәм козгынга.

Минем яуны сыйдырмый диңгез яры,
Шул гаскәрдән җибәрәм берсен бары.

Күзеңә тар итәр ул бу Галәмне,
Чагыштыр бер җенең белән адәмне».

Шундый сүзләр күп тутырды хатына.
Хатны алып атланды да атына,

Рөстәм шундук юнәлде авыр юлга,
Кылыч тагып, гөрзисен тотып кулга.

Хәбәр җитте Мазандиран шаһына:
«Тагын Кәвыс илче куйган катыңа.

Аяк басты иленә бүген таңда,
Филдәй көчле гаҗәп чибәр атында.

Буе озын, ачык йөз, ачулы каш,
Гайрәтеннән аждаһа коткармас баш.

Әгәр булса көче, буйга ярыша,
Һичкем бездә алмас аңа карыша».

Боерды шаһ тагын пәһлеваннарга:
«Чыгып, «һөнәр» күрсәтегез аңарга!

Йодрык белән ташны талкан итәрлек
Батыр ирләр безнең илдә җитәрлек!

Кулын кысып, сытыгыз бармакларын,
Җуеп кайтсын шаһына тырнакларын».

Каршы китте батырлар җилгер атта.
Күреп Рөстәм атлыларны еракта,

Искә алды Фәрһад маҗараларын,
Күз йөретеп үлчәде араларын.

Шунда кинәт, үскәндәй әлмисахтан,
Юан, биек агач күрә ерактан:

Кочакласа, җитмәс кеше кочагы,
Бүрәнәдәй юан һәрбер ботагы.

Барып, Рөстәм ике ботагын тотты,
Бар көченә тартты, бу агач купты.

Килүчеләр, бармак кабып авызга,
Гаҗәпләнеп туктап калды беразга.

Атты селтәп агачны, гүя салам,
Килеп болар алдына, бирде сәлам:

Күрешергә болар кулын озатты,
Көтә иде Рөстәм мондый тозакны.

Бирде кулын, кысты берсе сарылып,
Китте кебек бармаклары ярылып.

Түзде Рөстәм, көлү чыгарып йөзгә,
Диде: «Инде нәүбәт җиткәндер безгә».

Үзе кысты дошманы кулын, ярсып,
Ауды җиргә дошманы, һуштан язып.

Ике-өч бармак өзелеп төште җиргә,
Күреп батты батырлар салкын тиргә.

Бар иде бер тиңсез батыр арада,
Үзе филдәй, буе гүя манара.

Ул — Кәлләхур. Кулы гүя тимердән,
Күп дошманның гомер юлын җимергән.

Ул кул бирде: «Хуш килдең,— диеп,— ага»,—
Эләкте кул гүя тимер кысага.

Гүя төште бармаклары өзелеп,
Түзде. Кысты дошман кулын үзе нык.

Шундый кысты, Кәлләхур бармаклары
Канга әйләнде, түгелде тырнаклары.

Әрни явыз. Гүя ташлады җаны,
Куеп мәңге әрнүгә бичараны.

Көлә Рөстәм: «Кичер, уен бу, дустым,
Үзең килеп, минем кулымны кыстың».

Килә Кәлләхур патшасы каршына,
Кулы бәйле, үзе әрни, ярсына.

Канлы кулын чишеп күрсәтте аңа,
Күреп кулны, патша да калды таңга.

Диде шаһка: «Бу кулдан син ал үрнәк,
Алар белән яу башлаудан элегрәк.

Гаҗәп батыр бу сиңа килгән илче,
Аны мөмкин түгел Рөстәм димичә:

Әлиф гәүдә, башкаларны итә «даль»,
Моңа оста дөньяда тик Рөстәм Заль.

Болар белән дуслык күрсәт — тиз яраш,
Ярашмасаң, башыңнан кичәр бар эш.

Кисалмасаң дошман кулын, култыкла,
Тиләләнеп, көчле учка кул тыкма».

Бу арада Рөстәм дә җитте килеп,
Халык аңа хәйран тора текәлеп:

Олысымак сәлам бирде дә шаһка,
Тиң кешедәй утырды каршыракка.

Сораша шаһ теге яктан, бу яктан,
Дөнья хәлен, юл михнәтен кунактан.

Шаһ Кәвысны телгә алды, бәкләрен,
Сораша ул исемен атап барын:

«Бу батырлык, бу куәт һәм бу гәүдә
Булса булыр дөньяда бер Рөстәмдә.

Сорамыйм да, Рөстәм батыр — үзеңдер,
Синең кебек Рөстәм ул — дөньяда бер».

Диде: «Рөстәм — Иранга бер пәһлеван!
Ә мин аңа нисбәтән, бер кол — гавам.

Хат китердем»,— диеп, хат шаһка тотты,
Укыды шаһ: ачу капты, кан йотты.

Күрә: хатта кылычтан ачы сүзләр,
Аны күреп, каннар агызыр күзләр.

Ачуыннан җанга ялкын тоташкан,
Сорый: «Әллә Кәвыс акылдан шашкан?

Булмыйсыңмы иң данлы шаһ Иранда,
Көчеңә тиң килмәсен арыслан да,

Ярыймы, ни килсә телгә, сөйләргә?
Мазандиран колмыни синдиләргә?

Шулай минем намусны таптамаса!
Мин дә аңа тиң бер шаһтыр лабаса?

Ертканмы ул йөздән оят пәрдәсен?
Кеше болай хурламас кол, бәндәсен.

Тиң булмасам, мин соң аңардан кимме?
Аңа малай булыр көнне көтәмме?

Эзләсә дә олылык, белсен юлын,
Сузмасын ул кеше тәхтенә кулын!

Аңа миннән бүген катгый җавап шул:
Кичекмәстән Иранына тотсын юл.

Котылмаса китеп тиз — бетерербез,
Мең кешеңә торыр безнең беребез!

Әгәр яуга гаскәремне кубарсам,
Ираныңны, Тураныңны мин басам».

Илчегә шаһ китертте күп бүләкләр:
Алтын, көмеш, савыт-саба, күлмәкләр.

Шаһ сүзенә ярсып та, үзен тыйды
Рөстәм, шуңа алмады бүләк, сыйны.

Чыгып китте горур. Менеп атына,
Ашыкты ул тагын Кәвыс катына.

Әйтте шаһка, нәрсә ишетсә, аны,
Ул сүзләрдән куркынды Кәвыс җаны.

Моны күреп, ди Кәвыска Тәһмәтән:
«Мазандиран өчен аз да чикмә гамь.

Ора лаф ул, бакма шаһы сүзенә,
Күрмәдем мин бер батыр тиң үземә.

Алар бар да — тузан минем катымда,
Тузан итәм, гөрзим белән талкыйм да».

Тыныч тормыш качты Мазандираннан,
Җыя гаскәр шаһы көн-төн җиһаннан.

Дию, пәри җыелды бар Галәмнән,
Артык көче берсенең мең адәмнән.

Таулар, кырлар — бар Җир гаскәргә тулды,
Саннар җитми, исәп-хисап онытылды.

Гүя сырган саранча җир шарына,
Кош-корт анда тапмас җир басарына.

Бу хәбәрләр Кәвыска җитте килеп,
Чакырта ул Тәһмәтәнне иң элек.

Диде аңа: «Менә бит нинди хәлләр,
Җен явына дучар булды адәмнәр.

Гаскәргә син үзең баш бул бу яуда,
Күрмәсен җен кызгану да, аяу да».

Диде Рөстәм: «Боерык — шаһтан! Баш өсте!
Җенгә каршы күтәрәм барлык көчне».

Батырларны бастырды ул аякка,
Барын башлык итеп куйды як-якка.

Баш уң кулга Тус пәһлеван, Гив — сулга,
Корыч кигән, корал күтәргән кулга.

Гаскәр белән тулды кырлар, сахралар,
Курыкмаска, батырлыкка чакыралар.

Саф алдында җиңелмәс пәһлеваннар:
Гишвад, Харрад, Гударз, Гөстәһәмнәр,

Монда Гөргин, Рахxам, Фәрһад, Шәваран,
Бәһрам, Барзин — барсын кем соң санаган?

Җилә Зәңги, болгап һавада гөрзи,
Гайрәтләнеп чаба ярсып Гәразе.

Һәр тарафка, җәелеп, гаскәр ага,
Аяк басар урын юк кырмыскага.

Көбә, гөрзи, кылыч, ук, корыч калкан —
Гүя тимер җирнең өстенә япкан.

Якынлашты гаскәрләр, каршы басты,
Ачу уты йөрәкләргә тоташты.

Бер пәһлеван чыкты Мазандираннан,
Көче белән үч алырлык җиһаннан.

Фил гәүдәле, юлбарыстан кызу кан,
Кулда — гөрзи, күкрәктә — корыч калкан.

Атка менсә — бәла куба дөньяга,
Кылыч алса — дәрья булып кан ага.

Атын сөрде, гүя сәмум җиле исте,
Тузан, кубып, җирдән күккә иреште.

Җуя иде аты бу пәһлеванның,
Таянычы иде Мазандиранның.

Бераз күрсәтте егетлек мәйданда,
Салып дәһшәт, шау-шу күтәрде анда:

«Кая, бармы берәр җаныннан туйган?
Миңа каршы сынап көч, тотсын мәйдан!»

Авазы да күңелләргә сала шом,
Бар батырлар җиргә текте карашын.

Күңелләрдән гүя юк булды куәт,
Бу дәһшәттән качу — һәммәдә ният.

Каты аваз белән кычкырды Кәвыс:
«Кая, бармы, батырлар, сездә намус?!

Ишетәсез авазын бу явызның,
Ачылганын күрмим сезнең авызның!»

Су капкандай бар батыр өнсез тора,
Җуя ярсый, аның саен котыра.

Бу хәлләрне тамаша кылган Рөстәм:
«Бу явыз,— ди,— таба лаф орудан тәм!

Ә син, шаһым, күңелеңне тот тыныч,
Бу зат аз да түгел миңа куркыныч.

Боерса шаһ, аңа каршы мин керәм,
Аның лафы ни торганын белдерәм».

Диде Кәвыс: «Сиңа мин бирдем аны,
Гайрәт күрсәт, таң калдыр бар дөньяны!»

Менеп атка, яуга Рөстәм атылды,
Һава гүләп, җир йөзе тетрәп торды.

Күрү белән бу тамашаны Җуя,
Бөтен көчен, бөтен гайрәтен җуя.

«Моның килүе охшаш ач бүрегә,
Чигә гайрәт яудан, моны күрүгә»,—

Диеп уйлый, үте туңып, бичара.
«Әй бәлале, каның тарткан, ни чара!

Ни уйлап соң бу мәйданга син чыктың? —
Укы иман, бүген, бел, син тончыктың!

Сине тудырган ана хәле аяныч,
Бәгърен телә синнән җан алган кылыч.

Үз файдаңны-зыяныңны белмисең,
Шаша-пешә әҗәлеңә үрлисең».

Җан керткәндәй булды үртәү Җуяга,
Кабат сүзгә кереште ул: «Чү, ага!

Буең озын булганга, күп лаф орма,
Күләгәдәй буй кирәкми батырга.

Ул буйның мин яртысын кыркып алам,
Чәч йолкысын синең өстеңдә анаң.

Бу агаңны (исмен диярләр Җуя)
Бүре, каплан күрсә, койрыгын җыя.

Арысланнар шәүләмнән шүрләп чаба,
Миңа куян ни, арыслан — бер чама».

Җуя Рөстәм Җуя сүзеннән сабыр:
«Батыр кулын татып кара юкса бер!» —

Дип ала да сөңгесен ул кулына,
Җуя килеп өлгерми акылына.

Тибеп Рәхшен, дошманына ташлана,
Җуя калканын куйса да каршы аңа,

Калкан оча, көбә көлдәй сибелә,
Сөңге очы керә Җуя биленә.

Аны Рөстәм, сөңге очына элеп,
Йолкып ала иярдән капчык кебек.

Баш өстендә бераз күтәреп торды,
Башы аша чөереп җиргә орды.

Йөзе туфрак, авыздан ага каны,
Шул минутта Җуяның чыкты җаны.

Күреп, берәү көя, берәү шатлана,
Матәм кемгә, ә кемгәдер тантана.

Моны күреп Мазандиранның ханы,
Куркуыннан, тамырда корды каны.

Боера ул гаскәренә: «Яу башла!
Кыр, калмасын бер җилкәдә бер баш та!»

Дәрья кебек акты мәйданга адәм.
Тузан каплап, күренмәс булды Галәм.

Гүли сугыш быргысы каршы якта,
Яуга хәзер барлык гаскәр — аякта.

Сөңге очты, кылычлар төште эшкә,
Кан түгелеп ага, охшап инешкә.

Төя гөрзи нараттай ирләр башын,
Һәр як улый ачу, әрнү каргышын.

Җиңдем дигәндә, ук тия йөрәккә,
Муйны кемнеңдер эленә элмәккә.

Ерак кояштан саф, ак, пакь нур иңә,
Офыкта ук аңа кан төсе сеңә.

Кан кагыла бар нәрсәгә, ут яга,
Диңгез булып җәелә ул дөньяга.

Булды хәбәр йөртүче ук арада,
Хәбәр бирми ул да, тик җан ала да.

Бәла иңгән, дөньяга — бәла хаким,
Килеп җитте, диярсең, кыямәт көн,

Ата улны кайгыртмый, ул — атаны,
Һәркем уйлый коткарыр дип ат аны.

Куа, кача, мыж килә, кайный мәйдан,
Җәйхун ага җиһанга кызыл каннан.

Суештылар җиде көн, кичә-көндез,
Таҗын ташлап, Кәвыс җиргә орды йөз.

Башка туфрак сибә, ертты якасын,
Диде: «Ходай, безне утка ягасың.

Син ич — бөтен Галәмнәрнең сакчысы!
Синең кулда бар авырлык ачкычы!

Көчсез калдык. Җаныбыз төште утка,
Дию, сихер безне чыгара юкка.

Җиңү бир син, сихер калсын оятка,
Дию качсын, без ирешик морадка».

Торды, таҗын киде, менде атына,
Чакыртты да Рөстәмне ул катына,

Диде: «Әй күзләремнең нуры Рөстәм,
Безнең җаннар синең кулда, дөрестән:

Юлын табып, үтер явызлар шаһын,
Шуның белән син безне коткарасың.

Патшалары үлгәч, качар гаскәре,
Сиңа ярдәм итсен Гив һәм Тус, яме?

Кирәк дисәң, барсын Гударз, Шәван,
Фәрһадне ал, барсын Бәрзин һәм Бәһрам.

Алар сине саклап торыр һөҗүмнән,
Ә син барып ал үчебезне җеннән».

Рөстәм ярсып ала кулга гөрзине,
Мыжлый алда Мазандиранның җене.

Юл сала ул, аларны түшәп җиргә,
Килеп чыга саф-саф торган күп филгә.

Ул бу сафта яшен-кылыч уйната,
Инде җирдә ничә хартумнар ята.

Пыр туздырып филләр сафын — барчасын,
Күрә алда Мазандиран патшасын.

Ярсу белән ташланды каршы аңа,
Чәнчәм диеп, кулына сөңге ала.

Ачы тешли сөңге очы явызны,
Үлем — янда, ачып торсаң авызны.

Яшендәй тиз таба моңа бер чара,
Имеш, үзен һәлакәттән коткара.

Әфсен укып, ташка әйләнде шундук,
Алмас булды аны кылыч, сөңге, ук.

Моны күреп Тәһмәтән калды таңга:
«Кеше иде алда — әйләнде тауга.

Бу ни сихер: кисәк таш булды, катты,
Белеп булмый, бармы җаны-хәяты?»

Диде Рөстәм: «Бу тауга кул орыгыз,
Авыр микән, бер күтәреп күрегез».

«Мин батыр» дип йөрегәннәр ничәләр
Бергәләшеп күтәралмый көчәнер.

«Яхшысы,— дип, эченнән уйлый Рөстәм,—
Явызны мин, күтәреп, шаһка илтәм».

Бар көч белән җирдән йолкып ул тауны
Күтәрде дә аркасына аударды.

Шуннан Рөстәм, җәяү утеп кыр аша,
Шаһ алдына китереп, ташка баса.

Диде Рөстәм аңа: «Әй бәхете качкан,
Кулдан — тәхете, башыннан таҗы очкан,

Әфсенеңне китәр, чык таш эченнән,
Котылу юк сиңа минем учемнән.

Бу ташыңны хәзер ялкынга бирәм,
Гөрзи белән көл итәм дә көйдерәм».

Ул сихерче ишетеп Рөстәм сүзен,
Чыгып таштан, күрсәтте илгә йөзен.

Бер чирканыч хәшәрәт, йөз — карамай.
Диде Кәвыс: «Бу — шаһлыкка ярамый.

Күпме чикте моның җәбрен халаек,
Яхшысы: без мәлгуньне яндыраек».

Шулай аны җәһәннәмгә аттылар,
Җеннәр шаһсыз як-якка олактылар.

Берсендә дә калмады яуга тәкать.
Кеме качты, кайсы итте итагать.

Тотып-тотып җен-пәри кабахәтен,
Сихерченең иң явыз — эттән-этен,

Җәза белән башын кистеләр бер-бер,
Имин булды алардан бу гүзәл җир.

Хәзинәләр ишеген ачтырды шаһ,
Гаскәренә өләште мал бихисап.

«Шөкер,— диде,— калды исем, намус пакь»,—
Бу җиңүгә бик куанды Кәвыс шаһ.

Атна буе дога кылды Ходага,
Бирде нигъмәт фәкыйрь, мискин, гәдага.

«Бөтен гаскәр итсен,— дип,— мәйдән авыз»,—
Җиңү туен шуннан соң башлый Кәвыс.

Колак салып әрганунның моңына,
Җиде көн-төн гаскәр мәйгә туена.

Җиденче көн Рөстәм, калкып аякка,
Мактау сүзен башта сөйләде шаһка.

Соң сөйли ул Әүлядның вакыйгасын,
Искә ала аңа биргән вәгъдәсен.

«Бүген инде Әүлядны без онытмыйк,
Вәгъдә бозып, аны читкә ыргытмыйк.

Уйлыйм, шаһка лаек дип тик аны,
Әүляд булсын Мазандиранның ханы».

Шаһ чакыртты бу илнең олыларын,
Бүләк биреп, күңлен тапты аларның.

«Бүгеннән,— ди,— Әүляд — бу икълим[1] шаһы,
Сезгә — терәк, ә сез аның — канаты».

Диде бәкләр барсы: «Булсын мөбарәк!
Итсен эшен мөбарәк Хак тәбарәк!»

Кидерә дә шаһ хилгатьләр[2] Әүлядка:
«Гадел хөкем йөрет,— ди,— тирә-якка.

Әгәр кемдер хөкмеңә ими башын,
Андый башны кылычтан уздырасың!»

Аны патша итеп Мазандиранга,
Гаскәр белән үзе китте Иранга.

## Һамавиран сугышы

Җиңү яулап, Кәвыс Иранга кайтты,
Шатлык белән аны каршылый халкы:

Бизәтелгән барлык шәһәр-авыллар,
Гөлчәчәккә күмелгән кырлар, юллар;

[1] *Икълим* — борынгы бүленештә Җирнең экватордан төньяк котыпка кадәр булган җиде бүленешенең берсе.

[2] *Хилгатьләр* — югары дәрәҗәле кешеләр тарафыннан бүләк ителгән өс киеме.

Каршыларга юксыллар чыккан, байлар;
Бөтен якта көй сыздыра курайлар.

Шат һәм көләч шаһ тәхеткә утырды,
Хәзинәчене алдына чакырды.

Ачтырды ул хәзинә ишекләрен,
Бүләкләде бай-юксылны, бәкләрен.

Диде: «Килсен алдыма пәһлеваннар,
Алар яуда аямадылар җаннар».

Тәһмәтәнне башлык итте дә, бәкләр
Килде, шаһка тели-тели теләкләр.

Килеп, Рөстәм утырды шаһка каршы,
Кул күтәреп дога кылдылар барсы.

Кәвыс укый мактау, рәхмәт Рөстәмгә,
Сансыз бүләк тапшыра Тәһмәтәнгә:

Алтын таҗ һәм алтын тәхет, ука тун,
Алтын зәрле йөз кол һәм йөз кол-хатын.

Алтын җиһазлы, мул гәүһәр бизәкле
Бүләк итә йөз качыр һәм йөз атны.

Алтын, көмеш, ефәк йөкле йөз төя,
«Болар бары, батырым, сиңа тия!»

Һәм тапшыра Кабул иле, Нимрузны,
Тәһмәтәнгә бүләк иткән язуны.

Үзе сорый оялгандай кичерем:
«Юк ул миндә лаек бүләк әйберем!

Синең белән тора безнең башта таҗ,
Таҗ иясе һәрвакыт сиңа мохтаҗ!»

Ул яздырды ярлык пәһлеванлыкка:
«Рөстәм — баш,— дип,— бар гаскәргә, халыкка».

Рөхсәт сорап, үбеп тәхет аягын,
Чыгып Рөстәм карый юлы ярагын.

Алҗып яудан, читтә сагынулардан,
Очты Забул иленә ул Иранннан.

Рөстәм китте. Утырып шаһ тәхеткә,
Ил-халыкны туендырды бәхеткә.

Бүләк итә шәһәрләр бәкләренә:
Башлык итте Тусны үз гаскәренә;

Бүләк итте Гишвадка Исфаһанны...—
Бар бәгенә шулай бүлде җиһанны.

Гадел хөкем бәхет бирә Ил-йортка,
Куана ил — шаһ гаделгә, юмартка.

Бар Галәмгә җәелде аның даны:
«Күр, шаһ җиңгән хәтта Мазандиранны!

Кемнең мондый җиңү күрсәткәне бар?
Баш исәндә, җаның аңардан коткар!» —

Диеп уйлап, барлык патшалар, ханнар
Күп бүләкләр Кәвыска юллаганнар.

Һәрбер икълим алган муйнына салым,
Һәр ел түләп торырга хираҗ малын.

Мал арттырган кыюлыгын Кәвысның,
Оныткан ул нәрсәлеген намусның.

Эзләп яңа чараларын баюның,
Күршеләргә инде озайта кулын.

Ишетте шаһ: Бәрбәр — бер олы ханлык,
Иле — төзек, малы — күп һәм халкы нык.

Дөньяда юк, имеш, аңа бәрабәр,
«Нигә минем хөкмемдә түгел Бәрбәр?!

Ул көч алыр, ул булыр миңа дошман,
Яхшысы — мин Иранга аны кушам».

Боерды шаһ — җыелды барлык гаскәр,
Тагын атланды атка батыр бәкләр.

Юл алдылар, туры Бәрбәргә карап.
Хәбәр җитте Бәрбәр шаһына барып.

Ихтыярсыз кул сузды ул коралга.
Корал алды бар халык, дошман барга.

Тимер көбә диңгезе басты чиккә,
Иран явы каршыга килеп җитә.

Бәрбәр гаскәрләрен күрде Гударз,
Алып гөрзи, гүя дошман коралсыз,

Бәрбәр сафы өстенә атты атын,
Бер мең батыр аңа кушылды тагын.

Анда кызу кырылыш булып алды,
Кызыл каннан җирнең йөзе кызарды.

Гаскәр җитте килеп артыннан аның,
Тузан белән каплап йөзен һаваның.

Мондый яуны күргәне юк Бәрбәрнең,
Ышанычы сынды шунда гаскәрнең.

Гаскәрләрдән бере калмады анда,
Котылыр юл эзләп җилә япанда.

Кеме — тауга, кеме сахрага качты,
Олыларның бәгъренә ут тоташты.

Аһ-зар белән алар килделәр шаһка:
«Бу афәтне төшермә безнең башка.

Без — әсирең, коллыгыңа алыгыз,
Сиңа булсын барлык милек-малыбыз.

Сиңа булсын илебез һәм көнебез,
Нинди шартлар боерсаң да, күнәбез».

Гафу итте шаһ илнең башлыкларын,
Бүләк биреп эзли юашлыкларын.

Ә илләрен Иранга кушып алды,
Ил өстенә авыр салымнар салды.

Аннан үтеп гиздe шаһ уңга-сулга,
Күргән бер ил карышмый керде кулга.

Җитте Кафка. Гиздe тау утлакларын,
Искә алып Забулстан якларын:

«Тукта,— диде,— күрим бер ул якларны,
Бер сыйласын Рөстәм без — кунакларны.

Алып хәбәр, Рөстәм каршы ашыкты,
Килеп, шаһның аягына баш тотты.

Шаһ бәкләрне гөлбакчадай болында
Кунак итте җәннәт кебек урында.

Көндез алар күңел ачуда — ауда,
Кичәләре — мәй җамаягы кулда.

Моңлы көйләр сыза һәр якта сазлар,
Биеп тора каршында гүзәл кызлар.

Шаһ утыз көн татый дөнья ямьнәрен.
Язмыш сөйми шатлыгын адәмнәрнең.

Берничә көн күрсәтсә ачык йөзен,
Бөрки кеше бәгъренә гамь диңгезен.

Бар иде бер патша Гарәбстанда,
Олы нәсәп, данлы зат ул заманда.

Кулы астында бер олы кабилә
Гизә сахрада аның хөкеме белән.

Әгәр качса бер юлбасар бер илдән,
Аңа килеп сыена чын күңелдән.

Шул качкыннар җыелды ун мең кеше.
Юлбасарның билгеле инде эше:

Шаһка буйсынудан ул баш тарткан, ди,
Бәрбәр илен үзенә караткан, ди.

«Кәвыс белән тиңләшәм»,— ди икән ул.
«Аның хөкмен бүлешәм»,— ди икән ул.

Ничек бер таҗ ике башка бүленсен?
Юлбасар бар, ничек ил рәхәт күрсен?

Бу хәбәрдән чиксез ярсыды Кәвыс,
Аудан, сыйдан, мәйләрдән янды намус.

«Атларга!» — дип боерды гаскәренә.
«Яу чабыгыз! Хәзер!» — ди бәкләренә.

«Җаным, Рөстәм, бул сакчы халыкка син,
Бу сәфәргә барыйм дип калыкма син.

Түгел бу яу безнең өчен авыр эш,
Бу юл инде сиңа чиктермим тәшвиш».

Диде Рөстәм: «Баш өсте! Тик, онытма,
Кирәк булсам, син чакырсаң, мин — атта!»

Төн-көн дими, гаскәр ыргылды алга,
Тиз арада барып чыктылар Шамга.

Ике юл бар барыр өчен бередән:
Мең фәрсахлар берсе — чүлдән, корыдан.

Анда су юк, анда — тау-таш, анда — баз,
Кеше түгел, дию анда чыдамас.

Икенчесе — диңгез: якын, ансат та.
Боерып, шаһ күп көймәләр ясата.

Гаскәр, атлар — көймәгә кертте барсын,
Диде: «Гаскәр Мисырга якын барсын».

Исте көчле төньяк җиле сызгырып,
Илтә алга көймәләрне очырып.

Сулда калды Мисыр, Бәрбәр — уң кулда,
Кышы гүзәл яздай бер ил бар юлда.

Шаһ боерды — гаскәр төшә шул ярга,
Салып дошманның җанын куркуларга.

Диңгез булып гаскәр Зерехка акты,
Калкан, сөңге каплады тирә-якны.

Җир таң калды шаһ гаскәре көченә,
Бер ел санап чыгасың юк очына.

Һамавиран шаһына җитте хәбәр:
«Яу килә! — дип,— күр чара, тапсаң әгәр.

Гаскәр килә ташып, сыймый җиһанга,
Дәһшәт салып кош-кортка — барча җанга!»

Бу хәбәрдән катты патшаның башы:
«Хәерлегә килми ул безгә каршы.

Шул Кәвыс ич яккан Мазандиранны,
Аяк астына таптаган җиһанны.

Чыдарлыкмы бу дәрт? Юк ич дәвасы,
Каршы торып үлү — ялгыз чарасы.

Яуга чыгарга,— диде,— бар адәмгә!»
Ярдәм сорап илче салды Бәрбәргә.

Очкан укка маңгайны итеп калкан,
Койма итеп дошман юлына халкын,

Гаскәр җыеп, Кәвыска каршы чыкты,
Бер киң кырда ике гаскәр юлыкты.

Били күкне ук бураны, гүя кыш,
Очмас булды һавада куркудан кош.

Гив тузына анда, дулый монда Тус.
Фәрһад, Пулад, Гишвад, Гударз, Кәй-Кәвыс

Гөрзи тоткан — дошман башын тукмыйлар.
Алларында чәчрәп оча тик миләр.

Йөрәксезнең йөзе үздәй агарган,
Җир өстенә яңгыр булып ага кан.

Баһадирлар ләззәтләнеп сугыша,
Гөрзи күкри, яшен булып ук оча.

Өмет өзде Һамавиран башлыгы:
«Илнең халкын юк иттерү яхшымы?

Кушылсак та Бәрбәр белән икебез,
Булалмыйбыз яуда болар тиңе без».

Җиргә атты гөрзи, җәя-укларын:
«Кабул итәм, Кәвыс ни әйтсә, барын.

Аның хөкме әгәр татлы, гәр ачы,
Шул бүгеннән ул — башыбызның таҗы.

Кәй-Кәвыска бүгеннән җаннар фида!
Хәзинәдән ул мул бүләкләр җыйды.

Ләгыль, җәүһәр,— гүзәллектән нәрсә бар,
Кызыл алтын белән тулы касәләр.

Йөкләп көмеш, сансыз корал, көбәләр —
Кәвыс алдына китереп сибәләр.

Кабул итте Кәвыс бу бүләкләрне,
Тынычлатып ярсыган йөрәкләрне.

Яман шелтә ташламады йөзенә,
Илен-көнен багышлады үзенә.

Һамавиран шаһының бар бер кызы,
Гүзәллектә бу дөньяда — ялгызы.

Матурлыгы Галәмне тотар икән,
Аны күргән үзен онытар икән.

Яңаклары гөлнең таҗ яфрагыдай,
Буе — сәрви, күзе — йолдыз, йөзе — ай.

Чәче — сөнбел, ирне шикәр булганга,
Сүзе ганбәр сипкән кебек җиһанга.

Иреннәре — дәртленең дәртенә им,
Дәртең булса, бар да шул иренне им.

Шаһка тиң ул һәм лаек бер яр, диләр,
Хәбәрчеләр Кәвыска сер сөйлиләр.

Бу мактаудан шаһ йөрәге уйнады,
Ул гүзәлгә өйләнергә уйлады.

Чакыртты ул олы бәкләрнең берсен,
Гүзәл йөзле, иң дә татлы теллесен.

«Хәзер үк,— ди,— яучы булып ханга бар,
Сүз урнына агызасың шикәр-бал.

Сүзең белән юмала да атасын,
Миңа кәләш-кыз ярәшеп кайтасың.

Беләсең ич, миңа тиң юк дөньяда,
Миндәй кияү — торган бәхет аңа да».

Яучы килә Һамавиран ханына,
Мактау сөйләп, хушлык бирә җанына.

Соң Кәвыснның йомышларын йомышлый:
«Бәхет килде,— ди,— синең кулга бушлый!»

Кыз атасы әрнеде бу хәбәрдән:
Йөрәгенә каты тиде хәнҗәрдән.

Диде: «Беләм, Кәвыс иң зур падиша,
Аның белән туганлашу яраша.

Тик кыз балам — бердәнберем, күзалмам,
Аны күрми мин бер минут түзалмам.

Илемне алды, малымны алды ич Кәвыс,
Тагын нигә кирәк булды бу тавыш?

Ни хәлем бар? Ул — хуҗа! Тарталмыйм баш,
Кияү итәм, булам аңа карендәш.

Ләкин, тукта, кызны да алып килик,
Ул ни уйлый, аның фикерен белик.

Риза микән ул китәргә еракка,
Безне ташлап, җир читенә — Гыйракка».

Шаһ чакыртты Судабәне — шул кызын,
Сөйләп бирде аңа яучының сүзен:

«Бу яучыдан йөрәккә ут тоташты,
Шаһ та көчләп алмас ич син туташны...»

Кыз шаккатып җавап бирде аңарга:
«Бу — шатлык ич! Нигә аңа янарга?

Мине бер иргә бирергә кирәк ич!
Иран шаһы һәммәдән бөегрәк ич!

Сораш берәр заттан, чыгып ишектән,
Аны күккә чөеп мактар ишеткән...»

Шаһ аңлады кыз теләген, максатын:
«Безнең шатлык — синең бәхет, канатым!»

Төгәл тотып гадәтләрен бу якның,
Бар шартларын үтәп туй һәм никяхның,

Ашап, эчеп, уйнап берничә көннәр,
Хәзерләтеп сансыз йөкләр, төеннәр,

Шаһ күзәтте кыз озату чарасын,
Күз нурына бирде малның барысын:

Бер мең качыр, мең төя һәм бер мең ат,
Җиһазлары алтын, көмештән кыйммәт;

Өсләрендә бил сынарлык йөк тә бар:
Энҗе, җәүһәр, ефәк, атлас — күп товар;

Йөз хезмәтче, йөз кол, йөз кыз-караваш,
Барсы гүзәл — күргән читкә карамас.

Сансыз гаскәр кәрванга юлдаш кылды,
Бер батырын бу гаскәргә баш кылды.

Кыз утырды фил өстендә тәхеткә,
Юл алдылар ирешергә бәхеткә.

Китерделәр хәзерләнгән чатырга,
Коллар шаһны кыз күрергә чакыра.

Аны күреп, шаһ китә язды һуштан:
«Гүзәл!!!» Күрсә, хәйран калыр фәрештәң.

Хәзерләтеп, кызны алды аулакка,
Ике гашыйк ирештеләр максатка.

Кызы киткәч, утка төште атасы,
Кем бар аны бу дәрттән юатасы.

Кояш сүнде, гүя сарай таланды,
Хозур бетте, күз алды дөм караңгы.

Кирәк берәр мәкер, хәйлә табарга,
Кызны биреп җибәрмәскә аларга.

Мин аларны ашка дәшеп китерим,
Кызны алыйм, шаһның эшен бетерим.

Шуның белән китәр җаннан да ачы,
Читкә акмас илнең салым-хиражы.

Ул көндерде Кәвыска берничә би:
«Мин — каенатаң, миңа да башыңны и.

Ил алдында безнең дә йөзне ак ит:
Килеп безгә, күңлебезне кунак ит...»

Тәкъдиме хуш килде Кәвыс күңеленә:
«Күрәм, барам Һамавиран иленә».

Судабәгә бу хакта бирә хәбәр,
Кыз аңлады: монда бар хәйлә, хәтәр.

«Башың белән уйла,— диде Кәвыска,—
Минем әти хәйлә белән ауга оста.

Бер фетнә бу. Ул шундый «кунак» итәр,
Кулдан — ирек, җилкәңнән башың китәр.

Үзең теләп нигә утка керәсең?
Шунда утыр, күрәчәгең күрәрсең».

«Җаным, шулай борчылуың,— ди Кәвыс,—
Миңа шатлык: бу — гыйшкың бирә тавыш.

Ләкин аңла, сүзләрең сүз түгел бит,
Димә, атаң миңа да үз түгел, дип.

Кавыштырды әтиең мине син ярга.
Бу киңәшең алалмыйм игътибарга.

Чәче — озын, акыл — кыска хатында,
Чатак киңәш бирәсең, куркасың да.

Ул чакыра. Ә без посып калыйкмы?»
Ул сәфәргә күтәрде күп халыкны.

Бер шәһәре булган кыз атасының,
Эче — җәннәт, чиге юк бакча, суның.

Исме — Шахә. Улдыр — «Ирәм бакчасы»[1],
Кергән затның аннан килми чыгасы.

[1] *Ирәм бакчасы* — Шәддад дигән патша төзеткән җир җәннәте (миф).

Таштан койма, капкалары тимердән,
Бу кальганың куркасы юк бер ирдән.

Кәвыс килеп урнашты шул шәһәргә,
Бар ил халкы агылды баш иярга:

Җир үбәләр, бүләк сибәләр аңа,
Энҗе, җәүһәр тулып китте дөньяга.

Шаһ боерды — бәкләр утырды сыйга.
Күп эш булды ул көннәр һәр сәкыйгә.

Җиде тәүлек, төн-көндез мәҗлес кызды,
Күңелләрне, шәраб телләрне язды.

Кочышалар, гөрләшәләр үзара,
Саклык сүнә, күзләр, битләр кызара.

Шул шартларда мәкергә җитте чират,
Баштанаяк кораллы йөзләп ир-ат

Урнаштылар бер почмакта — посуда,
Тотарга, дип, Кәвысны бер кысуда.

Сыйлый патша шаһын, Иран бәкләрен,
Тулы җамнар үти үз хезмәтләрен.

Лаякыл баш, йокы баса күзләрен,
Ава алар, белмәс булып үзләрен.

Кәвыс бәкләр ауды, йоклап як-якка,
Инде ачу, мәкер басты аякка.

Поскан ирләр йөгерешеп чыгалар,
Кунакларга авыр богау тагалар:

Аяк, кулы, муйны богауда — Кәвыс,
Богауланган Гившвад, Гударз, Гив, Тус,

Харрад, Фәрһад — барлык Иран бәкләре,
Патша барсын җир астына бикләде.

Бар гаскәре, посып килеп, бу чакта
Сүз бирделәр кырда сөңге, пычакка.

Һөҗүм итеп, шаһ гаскәрен бастылар —
Янчеделәр, чәнечтеләр, астылар.

Башсыз гаскәр көтүдәй качты кырга,
Куып тотып, Бәрбәр аларны кыра.

Бер гаскәргә боерык бирелгән тагын:
«Басарга,— дип,— кырда шаһның утагын!

Сарайга,— дип,— алып кайтырга кызын,—
Мин зар булдым күрергә аның йөзен!»

Юк, бу хәбәр куандырмый туташны,
Гүя ялкын йөрәгенә тоташты.

Әрнү белән тартып ертты якасын,
Каргый сызлап анасын һәм атасын:

«Ир булсаң, син шаһны яуда тот идең,
Батыр түгел, хатыннар — синең тиңең!

Мине тели! Күзем яше кирәкме?
Мине дисәң, дәрттән коткар йөрәкне!

Юк, мин кайтмыйм. Яши алмыйм Кәвыссыз.
Богау киям, тик яшәмим намуссыз.

Мине япмый икән Кәвыс янына,
Агу эчәм, керәм дә ятагыма».

Бу сүзләрдән атасы шартлый язды,
Үтерердәй булды хәясыз кызны.

«Интексен,— ди,— күрми якты җиһанны,
Ташлагыз,— ди,— зинданда чыксын җаны!»

Кызны илтеп шаһ янына аттылар,
Гүя кара гүргә иңде якты нур.

Кыз җылады, шаһны күреп богауда:
«Кисәттем ич, әй шаһ, сине утауда.

Минем сүзне алмадың игътибарга,
Йөрәкләрдә төзәлмәс инде яра».

Диде Кәвыс: «Кем качалган казадан?
Килми калмас тәкъдиреңдә язылган».

Тынычланып, кыз да аны юатты:
«Күңелеңдә гамьнән сүнмәсен якты.

Һәр кайгының соңында килә шатлык,
Зиндан, төннең таңы була — азатлык».

Фида булсын мондый хатынга җан-тән:
Хатын түгел, батыр ул бозык ирдән.

Качып көймәгә кералган батырлар,
Берчак, аһ-ваһлап, Иранга кайттылар.

Кайгы хәбәр таралды бар Иранга:
«Шаһ һәм бәкләр төшкәннәр, ди, зинданга.

Көлтә кебек түшәлгән гаскәр җиргә,
Кайтасы юк инде аларның илгә».

Калган бәкләр шаһ юклыкны сизделәр,
Хезмәттән һәм канунннардан бизделәр.

Кем — юл баса, кеме — өендә ята,
Җыен башсыз илне-көнне болгата.

Олы кечене җәберли; ызгыш-шау,
Кайда бакма, анда — талаш, анда — дау.

Бу хәбәрләр җитте Әфрасиябка:
Кәвыс төшкән котылгысыз тозакка.

Башбаштаклык утында ил өтелә,
Каршы торыр юк инде бер эте дә.

Чәчрәп торды урыныннан Әфрасияб,
Гаскәр җыйды, куйды өзәңгегә аяк.

Гаскәр сөрде туры Иран өстенә:
«Каршы торса, шәфкать итмә берсенә!..»

Җыелды бер җиргә Иран ирләре:
«Ил биргәннән җиңелрәк җан биргәне!

Баш куябыз, илгә дошман куймабыз!
Үләрбез, тик төреккә кол булмабыз!»

Коралланды, кемдә нинди корал бар,
Ул арада килеп җитте тураннар.

Ике арада каты сугыш башланды,
Җилкәләрдән җиргә тоташ баш яуды.

Өч ай көн-төн сугыш бара, кан ага,
Иранлылар түзми: кача, тарала.

Ил һәм халык кол булып калды ханга,
Кача алган качты Забулстанга.

Алар әрнеп сыенды Рөстәм, Зальгә,
Диләр: «Нинди дәһшәтле көннәр алда:

Шаһ һәм бәкләр юкка чыкты, беләсез,
Ил, таҗ, тәхет — барсы калды иясез.

Башбаштаклык хуҗасыз илгә тулды,
Һәм нәтиҗә — төрек илгә баш булды.

Тик сездә бар өмет. Зинһар, тап чара,
Фәридун, Җам тәхетенә бер кара:

Тибеп екты төрек, илен яндырды,
Безнең җанда бетмәс әрнү калдырды».

Бу зарларны сызланып тыңлый Рөстәм,
Күзенә — яшь, күңеленә тулды гамь.

«Кайда булса да,— ди,— табам Кәвысны,
Алып кайтам, бетерсен бу тавышны.

Белмәгәндә — үлеме ул, тереме,
Куя алмыйм тәхеткә башка кемне.

Белсәм икән аның кайдалыкларын!
Бер кешедән ишетсәм саулыкларын!

Барыр идем, коткарыр идем аны,
Пыр туздырам шуннан соң бу Туранны».

Тере, диләр, шаһ. Әмма шундый төштә,
Барып җитмәс анда адәм дә, кош та.

Пәри җитмәс, дию җиталмас анда,
Кальгада ул, тирән базда — зинданда.

«Кем бар булса Кабулда һәм Забулда,
Хәзерләнсен,— ди Рөстәм,— хәзер юлга».

Үзе бер хат язды Һамавиранга:
«Нишләдең син?— Йортың аттың вәйранга.

Кулың белән башың салдың бәлагә,
Уйла, Иран шаһы базда каламы?

Ник белмисең үз файдаң һәм зарарың?
Оныттыңмы җирдә Рөстәм, Заль барын.

Белгәнсең ич Мазандиран хәлләрен,
Ишеткәнсең: мин явызны жәлләмим.

Яхшысы шул: акылыңа киләсең,
Тоткын шаһны безнең кулга бирәсең.

Кичектерми түлисең бар хиражны,
Тик шул саклар синең башыңда таҗны.

Тик шул саклар синең башны җилкәдә,
Уйла бүген, соң булмасын иртәгә...»

Рөстәм хаты патшага җитеп барды.
Укыды. Хат әйтерсең үтен ярды.

Бер каралды, бер күгәрде ул хаттан,
Көчкә һушын-исен җыйды азактан.

Кабат кайтты «мин-минлеге», мәкере,
Диде: «Рөстәм ул хәт Галәмнең кеме?

Патшаларга тел озайта әдәпсез,
Каян тапкан кадерсез бу кадәр сүз?

Тумыштан ук мәхрүм калган намустан,
Җиткерегез: өметен өзсен Кәвыстан.

Бу зинданга килеп капкан кешегә
Насыйп Иранны күрү тик төшендә.

Нигә Рөстәм өреп ята ерактан,—
Бәрбәргә бер килеп күрсен Гыйрактан.

Аңа минем әзер монда бау, зиндан,
Күрик, шуннан ни сүз чыгар авызыннан.

Килгән кеше, алып ачу җавабын,
Шундук күрде илгә кайту ярагын.

Кайтты. Әйтте Тәһмәтәнгә бар сүзен,
Ярсып Рөстәм, белештерми үз-үзен,

Кия көбә, кия башка дубылга,
Гөрзи, аркан, ук-җәя ала кулга;

Уйлап араның корыдан ерагын,
Күрде диңгез аша бару ярагын.

Әзер тора яр буенда көймәләр,
Атлар, гаскәрләр көймәгә керәләр.

Күтәрелгән җилкәннәргә тула җил,
Бик еракта, артта калды туган ил.

Килеп хәбәр иттеләр пәһлеванга:
«Җитәбез,— дип,— инде Һамавиранга!»

Ярга төшкәч әйтте Рөстәм: «Карагыз,
Рәхим-шәфкать юк бу илгә,— талагыз!..»

Һамавиран шаһына җитте гауга:
«Ни ятасың? Тәһмәтән килгән ауга!

Очраган һәр кеше башын туп итә,
Аягы җиткән бар җирне ут итә.

Вата, ега, яга бар нәрсәләрне,
Шакал җирли мәет-үләксәләрне».

Һамавиран шаһы моны ишетте,
Чарасы юк, көч туплап каршы китте.

Күз салуга Тәһмәтәннең көченә,
Дәһшәтле бер курку тулды эченә:

Ага кырга яу, ташкыны бар сыман,
Бүре кебек чая барсы, ярсыган.

Әнә Рөстәм: тәне — филдәй, ат — яшен,
Диюдән дә табалмассың тиңдәшен.

Авыр корыч гөрзи җилкәгә яткан,
Тауны, тисә, итәчәк сөрмә, талкан.

Табалмассың, әйләнеп чык Галәмне,
Мондый бер ат, моның кебек адәмне.

Бу мәһабәт гәүдә, бу батыр килбәт
Яралгандыр куптарырга кыямәт.

Ерактан ук һәммәнең үтен ярды.
Авыз ачып, гаскәрләр катып калды.

Кая йөрәк моңа каршы чыгарга,
Сыйпыйм диеп, кем кул сузар еланга?

Якын иде күршедә Мисыр, Бәрбәр,
Шаһ аларга шундук җибәрде хәбәр.

«Яуга тардык, тиз ярдәмгә ирешегез!
Килде Рөстәм, без бит сезнең күршегез!

Безне җиңсә, сезгә җитәчәк чират,
Тиз ярдәмгә килеп җитсен бар ир-ат.

Бар көчләрне әгәр тупласак бергә,
Гыйрак ни дә, Туран ни тора безгә».

Күршеләр дә хуплап җавап кайтара:
«Кайсыбыз соң ялгыз бер эш майтара?

Корал алсын, бассын ир-зат аякка,
Җыен явыз каныкмасын бу якка».

Мисыр, Бәрбәр гаскәре җитте килеп,
Гаскәр белән капланды таулык-киңлек.

Калмады бер кырмыска басар урын,
Сафка борын төртәлмәс озынборын.

Бу чак Рөстәм чигә тик Кәвыс гамен,
Шымчы итеп аңа юллый адәмен.

Итәк тулы алтын бирә кулына,
Алтын — ачкыч җирдә серләр юлына.

«Әйт,— ди,— шаһка, килеп җиттек исән-сау,
Чебенчә дә куркытмыйдыр безне яу.

Минем җанда иртә, кич тә — бер тәшвиш:
Шаһка, димен, итмәсеннәр бер-бер эш.

Шуннан куркып, әлегә туктап торам,
Юкса боларга кыямәт куптарам!

Син булмасаң, миңа җиңү ник кирәк,
Ни кушасың, җавап җибәр тизрәк».

Җавап бирде Кәвыс: «Әй пәһлеваным,
Бәхетем син, таянычым син, җаным.

Минем хакта аз да борчылма, атам,
Мин бу базда исән-сау яшәп ятам.

Бер Аллага тапшыр да минем эшне,
Сугар дошман каны белән Рәхешне.

Йөрәкләрдә ялман кылычың бута,
Тересен дә, үлесен дә як утка».

Яуга ярсый моны ишеткән филтән:
«Барлык гаскәр сафка бассын,— ди,— иртән,

Беләм, Мисыр, Бәрбәр дә килде яуга,
Сыймый дошман ни киң кырга, ни тауга.

Җыелганнар, бар анда йөз мең адәм.—
Берсе — ун мең булмыймы, миңа ни гамь?

Күрерсез сез мин аларны кырганны,
Сезнең бурыч — яудыру ук бураны».

Гайрәт бирә батыр сүзе халыкка,
Гүя куәт коя һәрбер калебкә.

Тынлык, тынычлыкны куып арадан,
Таңнан гүли ике якта барабан.

Китә кырдан күзәтче, поскан саклар,
Калка бер-бер көбә киенгән сафлар.

Тузан акты тоташтан күк йөзенә,
Туфрак тулды йолдызларның күзенә.

Җирдән күккә шулкадәр тузан акты,
Күк — сигез кат, җир калды алты катлы.

Эшкә төште кылыч, сөңге, гөрзи, ук,
Гәүдә — көлтә, оча башлар гүя туп.

Кылыч кемнән авыз итеп эчсә кан,
Ул зат, авып шундук, әрнеп бирде җан.

Кем башына төшсә гөрзи тукмагы,
Күзен йомып, ул мәңгегә йоклады.

Шулкадәр күп кан түкте ир-егетләр,
Канда агып йөрер иде мәетләр.

Яу кырында Тәһмәтән гүя йөзә,
Бер кизәнә — йөз кеше башын изә.

Сизә дошман Рөстәмнең бер карашын,
Куркуыннан калкыта алмый башын.

Өркеп кача батырлар төркем-төркем,
Тора алмый аңарга каршы беркем.

Киңәш итә Һамавиран башы: «Ил,
Егар димә бу батырны берәр җил.

Аңа каршы тик бер чара табабыз:
Ябырылыйк бар көч белән аңа без.

Чорнап, басып, күмик үзен һәм атын,
Кагынмасын яу кырында канатын».

Риза моңа бәрбәрләр дә, Мисыр да,
Башлый алар Тәһмәтәнне кысарга.

Күрә филтән: бар яу аңа ташлана.
«Менә инде мин көткән көн башлана!» —

Дип, биленнән ала кулга арканын,
Элмәк ташлап, тота да Бәрбәр ханын:

«Саклап торчы,— ди Бәһрамга,— монысын...»
Тагын шулай алтмыш Бәрбәр олысын

Тотып бәйләп тапшыра бәкләренә.
«Чират житте Мисыр имгәкләренә»,—

Дип, монда да ханын элмәккә элә,
Бәйләп ташлый илле бәк аның белән.

Һамавиран ханы, күреп чиратын,
Җиргә ауды, ташлап коралын, атын.

Аяк үбә: «Бездән үтте зур хата,
Бүген колың аяк астында ята.

Кирәк — үтер, кирәк — кичер, азат кыл,
Гафу итеп, илне, халыкны шат кыл;

Кичерә күр минем олы гөнаһны,
Китерим мин алдыңа Кәвыс шаһны.

Йөз өстемә төшеп ялварып килдем,
Мәрхәмәт ит, ачуыңа тарып килдем.

Гөнаһларын филтән аның кичерде,
«Тиз үк безгә Кәвыс шаһны китер»,— ди.

Шатланып хан җанын коткарганына,
Очкан кебек китте Кәвыс янына.

Барып, җылап, аякка куйды башын:
«Мин — гөнаһлы, гафу итә күр, шаһым.

Нәрсәң кими, гафуга юмарт булсаң?
Шаһтан тиеш гафу, мәрхәмәт, ихсан».

Шаһ кичереп гөнаһын һәм хатасын,
Кочты җирдән күтәреп каенатасын.

Богау төште. Ишекләр киң ачыла,
Шаһ һәм бәкләр, шаулап, урамга чыга.

Аны Рөстәм аттан төшеп каршылый,
Шатлыгыннан чыдап торалмый, җылый.

Кәвыс атты аның куйнына үзен,
Коча, сыйпый аркасын, үбә күзен:

«Ничәнче кат миңа иттең игелек,
Синең алда минем бурычлар йөк-йөк.

Ничек, кайчан аны түләп бетерәм?
Сине күрәм,— күңелемнән китә гамь».

Китерделәр таланылган бар малны,
Азат иттеләр әсир тоткыннарны.

Шаһ мәһабәт тәхетенә утырды,
Бәкләренә атап зур мәҗлес корды.

Хәзерләтте боерып бер гүзәл ат,
Үсә гүя аңа менгәнгә канат.

«Миңа терәк булды хурлыклы көндә,
Атлансын,— ди,— килсен монда Судабә».

Бик хөрмәтләп китерделәр аны да,
Утырттылар тәхеткә — шаһ янына.

Күп бүләкләр тапшырды шаһ бәкләргә,
Барлык малын өләштерде гаскәргә,

Кичерелгән бар мәкер, гөнаһлары,
Һамавиран, Мисыр, Бәрбәр шаһлары.

Киләчәктә итмәсен, дип, хыянәт,
Өсләренә күп салым салды гаять.

Ишетте шаһ Әфрасияб хәлләрен,
Яу хәбәре тетерәтте тәннәрен.

Ярсыган шаһ тәхеттән ыргып торды,
Җир тетрәтеп: «Атларга! — дип кычкырды.—

Ничек сыйда утырыйм ди мин монда?!
Анда илем — яу кулында, янгында.

Һамавиран бирсен,— ди,— илле мең ир,
Илле — Бәрбәр, Мисырдан — утыз мең ир!

Яу чабабыз бергә Әфрасиябка,
Үзем читтә, Иран калган оятка».

Шулай туплап олы гаскәр кулына,
Шаһ кузгалды ярсып кайту юлына.

Юлда бер хат язып кәйсарга салды:
«Үзем юкта, Иранны төрек алды.

Әле менә аның өстенә барам,
Хәнҗәр белән аның йөрәген ярам.

Калдырам мин аны шундый көлкегә,
Оят булыр йөз күрсәтү төлкегә.

Рум иленең гаскәрен миңа җибәр,
Күрер алар табыш, дан һәм җиңүләр.

Кирәк була кеше һәрчак кешегә,
Бүген — сездән тиеш ярдәм күршегә.

Әгәр теләсәң тәхетең ныклыгын,
Хәзерлән дә шул хезмәткә чык бүген».

Кәйсар, куркып: «Чыкмасын,— диде,— тавыш,
Гаскәр барсын, монда килмәсен Кәвыс».

Җавап язды: «Үпкә Әфрасиябка
Бездә дә зур, килгән өчен бу якка.

Мин үзем дә җыйдым барча ир-атны,
Син кайтмасаң, яклыйм, диеп, Иранны.

Шөкер Хакка, үзең кайтып ирештең,
Бирәм сиңа гаскәрнең бер өлешен.

Калганнарын җыям да чиккә басам,
Төрекләрне ул яктан куаласаң.

Бу якларга качканнарын мин кырам,
Алар канында юылсын бар Иран».

Шаһ куанды гаскәргә һәм җавапка:
«Кара көн,— ди,— килде Әфрасиябка».

Бер хат, боерды, яздылар үзенә:
«Нигә дөнья җитми туймас күзеңә?

Ни өчен милкеңә итмисең канәгать?
Вәгъдә биреп, антлар бозу — ни гадәт?

Ничә бастың, ничә качтың Ираннан,
Тагын табан ялтырат тиз, и надан.

Беләсең ич, миңа касд итүчеләр
Таҗын түгел, башын да җуя, җуләр.

Инде Галәм минем аяк астымда,
Бәрбәр, Мисыр — басып алдым барсын да.

Синме бүген миңа тиң буласы зат?
Яхшысы — син каплан кочагына ят.

Соң кем баса аждаһа койрыгына?
Баш алып кач, буйсын да боерыгыма».

Хат укыгач, янды ханның бәгыре:
«Кәвыс кем соң, масая бу кадәре?

Бер кыргый бит, үскән тауда, япанда,
Кемне күргән, ни тәрбия бар анда?

Иран таҗын шул тау кыргые алса!
Шаһ Фәридун — минем бабам лабаса!

Яу батыры Әфрасияб — мин, мин ич!
Телгән Туран, Иранны минем кылыч.

Ни акылы бар моның, ни кылычы,
Бушбугаз, лаф белән дәгъва кылучы,

Патша булырга ярыймы һавалы?
Яхшы хуҗа көтүче итми аны.

Кай якларга яу чапмасын, тотылды,
Кем белән керсә уенга, отылды:

Дау кузгатып барды Мазандиранга,
Колга әйләнде, әсир төшеп еланга;

Алам, диде, басып Һамавиранны,
Тапты хакын — богауны да зинданны.

Түбәнлеге дәлиле ич бу эшләр!
Оялуны белмәсә белми кешеләр.

Әле башы котылмаган ул яктан,
Лаф ора, күр, битсез, мәхрүм ояттан.

Патша булганга кирәк ич олылык,
Диңгезең дә тик тезеңнән булырлык.

Утырсын, кылсын Рөстәмгә догалар,—
Бар дәртенә табып тора дәвалар».

Шул уйларның барысын язып хатка,
Әфрасияб шундук җибәрде шаһка.

Хат Кәвыска утлы уктай кадалды,
Төстән төште, йөрәге утта янды.

Һәрбер сүзе — агу, зәһәрдән ачы,
Юкка чыкты шаһның бар куанычы.

Ат кудылар, узып Бәрбәрне, алга,
Өч йөз мең рум кушылдылар аларга.

Гүя бөтен Галәмне гаскәр басты,
Гаскәр тиздән Иран чикләрен ашты.

Хәбәр килеп җитте Әфрасиябка:
«Гаскәр килә, сыймый торган хисапка».

Ул да җыйды кул астына гаскәрен,
Хәзерләде бар сугыш кирәкләрен.

Ди: «Кәвыс та булдымы миңа кайгы?!
Каршы барам, итәм көнен караңгы».

Ике гаскәр ярсыган якынлашты,
Ашардай бер-беренә каршы басты.

Баштанаяк корыч кигән ике саф,
Күк йөзенә ук, сөңге игә сымак.

Күз ачмаслык тузан купканга гүя,
Басылсын, дип, җир йөзенә кан коя.

Кемнең башы гөрзи белән яньчелгән,
Кем тәненә сөңге үтә чәнчелгән.

Ничә гәүдә тыпырчына арканда,
Шук баладай, кылычлар йөзә канда.

Күккә ашса аһ-зарлар кайсы читтә,
Димәк, Рөстәм үзе анда эш итә.

Әфрасияб күзәтә таудан, өстән,
Ни бәлаләр сала халыкка Рөстәм.

Аваз сала, гаскәренә көч биреп:
«Пәһлеваннар, җитте сезнең көн килеп.

Казага җан каршы куялган ирләр,
Тырышыгыз, җиңгәнне — батыр дирләр!

Курку белмәү — ир-егетнең ямедер,
Кем ки гайрәт итә, ул — адәмидер.

Күңелләр бер булганда тик арка нык,
Ир-егетне хур итә курыкканлык.

Дошман белән тулып китмиме Галәм,
Курыкмыйм мин, аңардан чикмимен гамь.

Йөзгә-йөз без дошман белән, башка-баш,
Кулда корал барда, егет какшамас.

Тик бер Рөстәм — чамасыз бәла безгә,
Күк каһәре булды ул өстебезгә.

Язмышны да тотып бәйләр арканга,
Куркуыннан шәфәкъ баткан ал канга.

Әгәр бездә һөнәр чыгып бер ирдән,
Читләштерә алса аны өердән,

Аттан бәрсә йә канын түксә җиргә,
Мин дөньяны бүләк итәм ул иргә.

Бирәм шаһлык: булыр ул Иранга — хан,
Җан теләсә, кызганмыйм — бирәмен җан.

Кияү итәм — бирәм аңа кызымны,
Тик явыздан алсын йолып күземне.

Күзне буган кара дәһшәт булып ул,
Гизгәндә ул, бәхет безгә тапмас юл».

Йодрык белән арыслан башын ватар
Бар иде бер Туранда мәшһүр батыр.

Висе улы, Пилсам иде исеме,
Ул күренсә, дәһшәт ала кешене.

Иранда һәм Туранда бер тиң чыкмас,
Аңардан тик, күрсә, Рөстәм курыкмас.

Баш иеп ул әйтте Әфрасиябка:
«Нидән төштең мондый борчу-газапка?

Боерыгың бир — керим мәйданга үзем,
Нишләтермен аларны — күрер күзең.

Кем ул миңа Гивың, Тусың, Гударз?
Өчесен бер чыбык белән утарбыз!

Әгәр Рөстәм юлыксамы юлымда,
Гөрзи, сөңге, кылыч калмас кулында.

Көн калдырмыйм Кәвысның бәкләренә,
Арыслandай ташланам гаскәренә,

Гәүдәләреннән аерам башларын,
Аналарының түктерәм яшьләрен».

Әфрасияб диде: «Рәхмәт, батырым,
Таянычы — син ул Туран халкының.

Беләм, җаным, яуда арыслан үзең,
Сиңа рөхсәт, дошманга күрсәт йөзең.

Ләкин Рөстәм хәтәр, саклан аңардан,
Үзең сакла, аны югалт арадан».

Кулда — кылыч, билдә — гөрзи, арканы,
Тамырларда ачудан кайный каны.

Ярсып, Пилсам мәйданга атын атты,
Дус-дошманны үз ягына каратты.

Нәгърә орып, җилде мәйдан эчендә:
«Килсен, бармы ир-зат Иран эчендә?!»

Аңа каршы «пелт» итеп әллә кайдан
Гөргин чыгып тотмакчы булды мәйдан.

Чапты дошман атының башын Пилсам:
«Хуҗасын,— ди,— арканга бәйләп алсам...»

Ләкин шунда Гөстәһәм җитте килеп:
«Аңа тимә! Миңа җавап бир элек!»

Моңа Пилсам ачуы бик кабарды,
Сөңге сугып, көбәсен төтеп ярды.

Сөңге сынды. Алалгыйнча кылычын,
Килеп җитте өстенә Фәрһад, очып.

Бар көченә чапты кылыч Пилсамга,
Калкан куеп өлгерде Пилсам аңа:

«Димсең шуны: мин дә кылыч чабалам?
Миннән өйрән кылыч чабуны, балам!» —

Дип, кыныннан тартты һинди кылычын,
Салды кулга бар көчен һәм бар үчен,

Фәрһад каршы калкан куеп өлгерде,
Корыч калкан шартлап ике бүленде.

Ярып кереп баштагы дубылгасын,
Яралады кылыч Фәрһадның башын.

Баштан шуып атның муйнына төште,
Ядрә булып ат башы җиргә очты.

Ат өстеннән Фәрһад тә җиргә ауды.
Бу казалар дәһшәткә салды яуны.

Җир тетрәтеп атының аягыннан,
Гив калыкты иранлылар ягыннан.

Батырлыкта охшый ул крокодилга,
Каршы чыкканны таптый кара җиргә.

Күтәрелде Гөргин, Гөстәһәм, Фәрһад,
Әмма Пилсам аз да калмады куркып.

Каршы басты күкрәк киереп дүртенә,
Кем — сөңгегә, кем гөрзигә төртелә.

Дүрт батырның һөҗүмен алмый санга.
Кардәше бар — Пиран, мәшһүр Туранга,

Бу сугышны шул батыр күреп калды,
Ярдәмгә дип, атын мәйданга салды:

«Әй, йөзләре кара,— диде аларга,—
Ябырыласыз берәүгә дүрт аждаһа!

Йөз чөермәс ул сездәй йөз битсездән,
Көлдерде бит Галәмне йөзегездән.

Бу илләрдә батыр, диләр ич сезне,
Ялгыз Пилсам сөрдеме сөрмәгезне.

Хур булдыгыз, ул батырдан китегез,
Кая, минем белән бер эш итегез!» —

Дип сөйләнеп, һөҗүмгә күчте Пиран,
Ике күзен ачудан каплаган кан.

Ике туган дошманны шар иттеләр,
Киң Галәмне аларга тар иттеләр.

Маҗараны күзәтә Рөстәм читтән:
Батырларның хәле соң чиккә җиткән,

Гайрәт шиңгән, әлсерәгән яралы,
Пиран,Пилсам тукмап-тукмый аларны.

Ярсып, Рөстәм камчы салды Рәхшенә,
Очып чыкты туранлылар каршына.

Кем юлыкса, тузанын какты күккә,
Дошман сафын көлтәдәй җиргә түкте.

Кем башына төшсә аның кылычы,
Баш, туп булып, җилкәдән читкә очты.

Сафлар кача аның юлыннан, өркеп,
Ә ул оча, гүя мәйданда бөркет.

Аны күреп, Пилсам булды тораташ:
«Аждаһа бу! Моңа кеше чыдамас!

Югалтыйм,— дип,— Рөстәм юлыннан эзем»,—
Яу кырыннан читкә каратты йөзен.

Тәһмәтәннең шәүләсен күргән гаскәр
Яу кырыннан читләшә барды бер-бер.

Иран халкы гайрәт алды аңардан,
Кан түгәргә, ярсып, туранлылардан:

Шулкадәрле кырдылар анда яуны,
Үле гәүдә каплады бар Иранны.

Адәм каны акты кырдан, таулардан,
Күк тетрәде әрнүле аһ-зарлардан.

«Бу аһ-зар,— ди Туран ханы, ишетеп,—
Шомлы хәбәр, яндыра ич өшетеп.

Монда торсам, баш һәм җан китәр кулдан,
Тапталмастан, урын алыйм мин юлдан.

Җиңү ич ул — бәладән котылу да!» —
Дип ашыгып ташланды кайтыр юлга.

Кәвыс гаскәр куймый аны куарга.
«Яу бетте!» — дип, ил куанды моңарга.

## Кәй-Кәвысның күккә очуы

Төрекләрнең ташлап качкан малларын
Берәмтекләп җыйдырып алып барын,

Диде: «Бүлеп бирелсен бар гаскәргә —
Иранлыга, румнарга, бәрбәргә».

Малга туйдырып олысын, кечесен,
Озатты ул рум, бәрбәр кешесен.

Бәкләренә күп бүләкләр боерды,
Батырларын үз янына җыйдырды,

Үзе белән михнәт күргән ирләргә
Бирде йортлар, таҗ-тәхетләр, илләр дә.

Кайсын — Мәрвү, кемен Шапурга[1] салды,
Берсе — Хират, берсе Бәлхне алды.

[1] *Шапур* — Нишапур шәһәре.

«Кем табылыр Иранда аның ише?
Һәммәгездән артык,— ди,— Рөстәм эше».

Бирде аңа хисапсыз күп хәзинә,
Иң якын зат итте аны үзенә.

Шулай аулап һәр куанган көннелне,
Батырларын чит-чикләргә күндерде.

Яши Кәвыс, хөкем йөртә иркенләп:
Эшкә аша, башта туса ни теләк;

Учта була, кулын озатса нигә,
Үтә хөкме җен, диюгә, пәригә.

Һәркөн саен арта көче, дәүләте,
Кемнең хәзер аңа җитәр куәте?

Пәри, җенне салмакчы бу бер эшкә,
«Җыелсын,— ди,— һәммәсе Элбурска.

Зур сарайлар төзелсен тау эчендә,
Шаһ өчен дә һәм атлары өчен дә.

Казысыннар, киссеннәр тауны алар,
Калдырып тик мәһабәт баганалар.

Ак мәрмәр таш ябылсын диварларга,
Төрле рәсем төшерелсен аларга.

Күргән бер зат шаккатып ава язсын,
Анда кергән бар дәртле дәва тапсын.

Ул сарайлар булсын — хан ат абзары,
Кайнасын бар дошманнарның каннары.

Ике башта төзелсен ике кирмән,
Булсын һушын җуярлык аны күргән:

Бер кирпече — алтын, берсе — көмештән,
Ялыкмас, дим, дию дә мондый эштән;

Стенада — гәүһәр, якут бизәкләр,
Бүлмә санына җитмәсен исәпләр;

Тирәсендә булсын гүзәл бакчалар,
Җанвар гизә, гүзәл кошлар очалар.

Сарай салды җеннәр, сузмыйча күпкә,
Аны күреп, шаһ башы тиде күккә.

Гүя ганбәр — бакчасының үләне,
Хуш һавасы — терелтерлек үлгәнне.

Чәчәкле яз — аның җәй, көз, кышы да,
Һәрчак бакча чәчәкләр балкышында.

Каты куллы булды җенгә Кәвыс шаһ,
Пәри, дию җәбереннән итә аһ.

Туктаусыз эш, тукмак өлеш аларга,
Вакыт калмый хәтта сулыш алырга.

Авыр эштән була язып дивана,
Көч-хәл белән эшли җен, яна-яна.

Беркөн шулай Иблис әйтте җеннәргә:
«Бичаралар, охшагансыз кемнәргә?

Көн-төн дими чиләнәсез гел эштә,
Сезгә рәхәт күренми хәтта төштә.

Юкмыни соң арагызда башлы зат,
Хәйлә табып, итәрлек сезне азат?

Күрсәт дуслык, чыгып Кәвыс юлына,
Изге сүзләр сибеп сулы-уңына,

Аздыр күңлен, чыгар Алла юлыннан,
Төшәр ләгънәт, китәр дәүләт кулыннан,

Түгел сезне, үзен истән чыгарыр,
Сезне тик шул бу газаптан коткарыр.

Әгәр Хакның берлеген итсә инкарь,
Алла белән бозыла аның базар».

Шаһтан куркып чыдыйлар иде эшкә,
Инде колак салдылар Иблискә.

Бар иде бер явыз җен бу өердә,
Тиңләшалмас аңа һичкем мәкердә.

«Син сөйләгән эш ул — минем эшем,— ди,—
Миңа колак салмас кайсы кешең?» — ди.

Беркөн Кәвыс сахрага ауга чыкты,
Гүзәл сурәтле бер иргә юлыкты.

Күз күрмәгән гөлчәчәкләр бәйләмен
Биреп, егет: «Шаһым, гомер бәйрәмең

Дәвам итсә иде,— диде,— мәңгегә,
Синең гомер ул Галәмгә ямь бирә.

Бөтен дөнья — синең аяк астында,
Барлык шаһлар — сиңа кол ич, асылда.

Дию, пәри, шайтан, җен — хезмәтеңдә,
Синнән өркеп таш кисә хәтта төндә.

Бер кимчелек (аңлашылмый ил-көнгә),
Күк Галәмен алмыйсың үз иркеңә.

Оч күккә — ай, кояшны ит тамаша;
Ни сәбәптән төн белән көн алмаша?

Күккә аш син, ул киңлектә сәйран ит,
Гыйльмен алып, бар Галәмне хәйран ит.

Күктә, диләр, Алла безне яраткан,
Без — кол, син ник аңа гашыйк еравктан?..»

Башсыз шаһка бу сүзләр салды коткы,
Дөнья — бер чүп. Күренми күзгә якты.

Күк һәвәсе аның бар фикрен алды,
Көн-төн ул тик шул бер фикергә талды.

Күккә ашу юлын эзләп баш вата,
Табалмый юл. Йокы алмый төн ката:

«Мин — олы шаһ! Мин җирдә калырлыкмы?!
Чакыртыйм,— ди,— хәйлә белгән халыкны,—

Мөнәҗҗимнәр килсен, гыйлем иясе,
Бардыр ич бер күккә чыгу хәйләсе?

Җыелсыннар, көчләрен бер итсеннәр,
Күкне миңа сәйр итәр җир итсеннәр».

Җыелышты Галәмдәге бар галим.
Кәвыс сөйләде аларга бар гамен.

Галим халык иеп баш уйга талды,
Бу мәгънәсез теләккә хәйран калды:

Күккә ашу юлы сыймый фикергә,
Ничек кеше аяк бассын ул җиргә?

Кеше түгел, фикер ирешмәс анда,
Күкне биләү чарасы юк җиһанда:

«Бичара без берәр чара табудан.
Әгәр инде, кайтмыйм, дисәң, бу юлдан,

Тауга җибәр, бөркет-кошлар оясын
Табып, җыеп кайтсыннар яшь баласын.

Алар үссен сиңа, кулга ияләшеп,
Ит ашаттырт, хезмәтчеләрне дәшеп.

Гүзәл тәхет төзет гуд агачыннан,
Булсын тәхет сандыктай, тик ачылган.

Элеп калҗа дүрт сөңгенең очына,
Беркетелсен тәхетнең дүрт читенә.

Сөңге төбе кошларга булсын камыт,
Сине алар күккә очарлар алып.

Җитим, диеп, сөңге очына — иткә,
Алар һаман ашкынырлар биеккә.

Менә шул тик без табалган бер чара,
Башка берәр юл белмибез очарга».

Шаһ шатланып колак салды киңәшкә
Һәм, атлыгып, шундук кереште эшкә.

Үтте көннәр. Хикмәт әһле әйткәнне
Үтәп Кәвыс, җиткерде очар көнне.

Шат, горур шаһ чыкты тәхет-сандыкка,
Иткә омтылып, кошлар очты күккә.

Алар һаман күтәрелә югары,
Күз алдыннан җир бөтенләй югалды.

Тапмый кошлар иткә җитәргә чара,
Йөрәкләре ачлыктан парә-парә.

Кәвыс бара очып татлы өметтә:
«Ирешәм,— ди,— башта өченче күккә.

Анда, туктап, фәрештәләрнең телен
Өйрәнәм дә беләм үлмәүнең серен».

«Әгәр Алла кабул итмәсә мине...» —
Дип, ук-җәя янына алган иде.

Канат кагар көч калмады кошларда,
Тик торалмый, кайда инде очарга?

Күзне йомып, таштай җиргә төшәләр,
Бер биек тау башына ирешәләр.

Аһ орды шаһ: «Ни күрер безнең башлар?
Тирә-якта — кыялар да тау-ташлар.

Юк алдында бер хезмәтче, бер бәге,
Ятты Кәвыс ташта, янып йөрәге.

Арган кошлар башы ауды камыттан.
Ит барлыгын хәбәр итте тамып кан.

Ирештеләр иткә — сөңге очына —
Һәм очтылар аугa, таулар эченә.

Кәвыс калды тауда, ташлар өстендә.
Үтә көннәр, охшап берсе-берсенә.

Узгынчылар ерак тау сукмагыннан
Күрә: тауга бер җан иясе кунган:

Башындагы алтын таҗдан — йөз сары,
Күзләреннән ага дәрья — яшьләре.

Якын килеп, кызганып сүз каттылар:
«Нинди бәлагә тарыдың, әйт? — диләр.—

Башыңда — таҗ, өстә — укалы кием,
Ник ауныйсың таш өстендә, әйт, бием!»

«Зур бәлагә юлыктым,— ди,— карендәш:
Ташлап илем-көнем, ташка куйдым баш.

Балта чаптым үзем үз аягыма,
Кайталаммы кабат үз торагыма?

Ташламагыз, зинһар, итегез ярдәм,
Очрамасмы Иран иленнән адәм.

Мин — элекке Иран шаһы, белегез,
Зинһар, миңа ярдәм кулын бирегез...»

Аңлап кошлар күккә ашмасын, бәкләр:
«Безнең бурыч — күрсәтү,— дип,— хезмәтләр!»

Мәйданнан ук атланышып атларга,
Шаһны эзләп таралды бар якларга.

Тапмадылар алар әмма шаһ эзен,
Гизеп тауда, япанда кич-көндезен.

Гударз карт, Гив, Тус, Рөстәм беркөнне
Очраттылар таудан килгән төркемне.

Уйладылар: «Нидер беләләр болар,
Әйтмәсләрме безгә кирәк бер хәбәр».

Эндәштеләр: «Уң булсын юлларыгыз!
Каян килү? Кая баруларыгыз?

Без югалттык монда бер кешебезне,
Шул турыда бер хәбәр белмисезме?»

Шундук халык җавап бирде шаулашып:
«Бу якларга килә идек, тауны ашып,

Белдек шунда сез сораган хәбәрне:
Безне Кәвыс сезне эзләргә җибәрде.

Сезне табып алып килсәк янына,
Вәгъдә итте: күмә дөнья малына.

Якында ул, әнә теге зур тауда,
Көтүчеләр янында бер утауда».

Гударз ди: «Шаһ түгел бу, бер бәла,
Башсызланып, тоташ фетнә кубара:

Йә җен белән сугыш-ызгыш кузгата,
Кошлар җигеп яки үзен «күккә ата»,

Шул ахмакка хезмәт итикминде без?
Алда тагын аңардан ни күрербез?

Ни гакыл юк, ни фикер юк башында,
Мәгънәсезгә бил бөк шуның каршында...»

Шулай сөйләп, барып күрделәр аны,
Күргәннәрнең әрнеп ачыды җаны:

Утырган ул көтүчеләр эчендә,
Хайван кебек гамьсез ашау эшендә.

Аягына куйдылар һәрбере баш,
Күзләреннән агызып һәр якка яшь.

Диделәр: «Бу — ни оят? Бу — ни эштер?
Мондый хәлне кем ишеткән, имештер?»

Кәвыс өчен әрнеп, эчләре янды,
Ул әрнүдән ачы сүзләр уянды.

Ди Гударз: «Кая, монда бир таҗны,
Синең ише башсызга таҗ мохтаҗмы?

Синме соң ул таҗ-тәхетләр иясе,
Синдәйләрнең урны — елан оясы.

Ни тилелек белсә адәм баласы,
Бер үзеңдә синең шуның барысы».

Диләр: «Бәла зирәк итә кешене,
Турайтыр тик кабер синең ишене.

Гаҗәп, җаның башсызлыктан туярмы?
Бу йөз беркөн оят хисен тоярмы?

Үзең хурлап әрнетәсең җан итең!
Җиһан халкын үзеңә дошман иттең!

Кем күңеле сау соң синең яраңнан?
Калды, диден, җирне-күкне яраткан,

Ахыр кулың хәтта аңа озаттың.
Җирне ташлап, күк тәхетен күзәттең.

Беләсең ич, гомер көне бик кыска,
Төкерерләр мәңге безнең намуска.

Кем ишетсә хәлең, ирме, хатынмы,
Ләгънәт белән атар синең атыңны.

Килер буын хөкме алда — онытмыйк!
Башсыз яшәп, мәңге ләгънәт укытмыйк!

Тән-җан белән ил-көн бер шаһка мохтаҗ,
Без — коллары, кем башында булса таҗ.

Тик булмасын шаһ файдасыз җилкуар,
Андыйлардан тиз көндә үк ил туяр...»

Батырларның теләге иде изге,
Сөйләделәр бераз нәсихәт сүзне.

Кулын үбеп, аягына куеп баш,
Соң кичерем сорадылар түгеп яшь:

«Бу — тыйнаксыз, ачы сүз җан әрнүдән,
Сез — шаһыбыз, газиз безгә һәрнидән...»

Шелтә сүзен баш иеп тыңлый Кәвыс,
Эче тулы үкенү, оят, намус.

Йөрәк уты кабардай күлмәгенә,
Чарасы юк, тоташ яшь түгә генә.

Бәкләр аны һәрьяктан юаталар:
«Кеше ич без: кемдә юк соң хаталар?!»

Тышка Рөстәм күтәреп чыкты шаһны,
Китерттеләр җилдәй җитез бер атны.

Атланышып, юлга төштеләр алар,
Шаһ — кайгыда, күңел ача башкалар.

Кайткач та, шаһ күп үкенде эшенә:
«Ни йөз белән күреним мин кешегә?!»

Чикмән киде. Кара җиргә куеп баш,
Кырык көн-төн сәҗдә итеп койды яшь.

Көн-төн сөйли Аллага зарын, аһын,
Тәүбә итә, кичерсен, дип, гөнаһын.

Яшьле йөзен тоташ сөртә туфракка,
Баш күтәрми, карамый тирә-якка.

Кабул итте Хода аның тәүбәсен:
Бар гаменнән азат итте гәүдәсен.

Тулды күңеле куанычка, бәхеткә,
Таҗын киде, кабат менде тәхеткә.

Бу хәбәрне белде гаскәр, ил-халык,
Килде алар шаһ алдына, тупланып.

Күз яшь белән җир үбәләр алдында,
Кадре шаһның күтәрелде тагын да.

Калдырмый шаһ бер җанда бер җәрәхәт,
Һәркем, күреп гаделлек, таба рәхәт.

Кайда булса, әрнүле җан күрә ул,
Юата ул, назлый, рәхәт бирә ул.

Шул рәвешчә үтте ничә ун еллар,
Бүләк алып баеп бетте юксыллар.

Шулкадәрле өләште мал, хәзинә,
Булды бер мохтаҗ күренмәс күзенә.

Кәвыс илгә шатлыктан мәҗлес ача:
Көндез — уен, сый — кичтән таңнаргача.

# СИЯВУШ



* * *

Беркөнне Тус, Гив, Гударзны алып,
Эт, кош белән китте ауга кузгалып.

Бер тугай бар, якын төрек чигенә,
Булмас анда киекләрдән ни генә?!

Болар һәрчак шунда ауга чыгалар,
Көн буе аулап киек, талчыгалар.

Ә тугайда — чәчәк: рәйхан, сөнбеле,
Үсә анда бу Галәмнең бар гөле.

Агачларда — җимеш. Ага саф сулар,
Юкка чыга монда ару, ачулар.

Бу юлы да ауладылар күп киек,
Кайсын тотып элмәккә, тере көе үк.

Якын Туран җирендә дә бар тугай,
Диләр: «Җәнлек анда моннан мул бугай».

Гив белән Тус, бу сүз чыккач авыздан:
«Без ник куркыйк,— диләр,— төрек явыздан?»

Узыштырып ат кудылар Туранга.
Килде мәхшәр аккош, киек, коланга.

Кызык булды нәтиҗәсе бу ауның,
Алар җитте итәгенә бер тауның.

Кинәт күреп бер гүзәл кыз шул чакны,
Икесе дә тораташ кебек катты:

Йөзе — җәсмин, буе — сәрви, кара каш,—
Йөрәк туктый тибүдән, кыз карагач.

Болар — киек, әлмәк булды кыз чәче,
Балкый тугай, гүя бер җәннәт эче.

Бу нур барсы шул гүзәлдән бөркелә,
Шикәр ирен елмая, ә күз көлә.

Нечкә билен кочкан алтын билбавы,
Йөзен баксаң — алынадыр күз явы.

Моңа тиң хур сигез җәннәттә булмас,
Җирдә моңа тиң бер гүзәл табылмас.

Күреп аны, хәйран калды батырлар,
Диләр: «Ярабби, искитәр сәнгатең бар!

Бу кем? — диләр,— хур кызымы? Пәриме?
Кояш, төшеп җиргә, шулай йөриме?»

Тиң ут салды икесенең җанына.
Тус сүз кушты килеп бу кыз янына:

«Кем син?! Хурмы? Пәри? Мәләк? Адәмме?
Аймы иңгән җиргә, ташлап Галәмне?

Мәләк булсаң, күккә очмас идеңме?
Пәри булсаң, юкка чыкмас идеңме?

Ялгыз башың нигә чыктың далага?»
«Мин — адәм,— ди кыз,— юлыктым бәлагә:

Атам кайтты исереп, җуеп аңын,
Бер сәбәпсез түкмәкче минем каным.

Китте хәнҗәр алырга, бәйләп мине,
Алды хәнҗәр, тыңламыйча әнине.

Килгән чакта ауды, йокыга талды,
Әни, килеп, мине баудан коткарды.

Качтым өйдән, җан ачысы, куркудан,
Килеп чыктым менә шул тауга, туган».

Тус сорады: «Әтиең кем, нәсәбең?»
«Әтием,— ди кыз,— оныгы Гәрсивазның,

Нәсәбем зур: Фәридун — ерак бабам,
Ә мин менә нинди язмышта янам.

Котым оча: атам килер аңына,
Эзләп килеп җитәр бу тау ягына.

Бер гөнаһсыз мине суймакчы иде,
Өйдән качтым, мин — зур гөнаһлы инде.

Ни бәлаләр, белмим, башыма төшә,
Эзләп килеп, алар монда ирешсә».

Күптән боларның күзе кызга төште,
Кыз сүзеннән йөрәкләр кыза төште,—

Икесе дә, куеп оят, хәяны,
Үзенеке итмәкче була аны.

Борылды да Гивга, диде Тус Нәүдәр:
«Минем табыш, миңа — бу кыз, берадәр!

Ауга төштем, гашыйк булдым мин аңа,
Сабырым юк, йөрәгем дәрттә яна;

Күктән миңа бүген бәхет иреште:
Тозагыма нинди тансык ау төште!

Ычкындырмам аны мин үз кулымнан,
Аның өчен йөз чөермим үлемнән».

Ачудан Гив ала алмый сулышын,
Күзе белән йотардай атын, Тусын.

Кайный ачу, йөзләре кара янды,
Ул сугышка әзер, гайрәт уянды.

Диде: «Батыр, бу сүзең — сүз түгел ич,
Уйлап сөйлә, мин дә күзсез түгел ич!

Күңел бирмә кулыңа кермәс затка,
Күз күп салма, калуың бар оятка!

Тәвәккәлләп, монда без бергә килдек,
Бу тугайга икебез тиң җилдердек.

Искә төшер, минем атны уйла да:
Бу аланга килеп чыкты ул алда.

Ә кыз — миңа, алалмас аны миннән,
Каршы чыкса да дәһшәтле Тәһмәтән!

Минем күңел гашыйк булды гүзәлгә,
Кул сузсыннар, бирмәм Нәриман, Зальгә!»

Бу сүзләрдән Тус та кызды, ярсыды:
«Мин — шаһ улы! Син кем минем каршыда?

Чамаңны бел, минем ярсытма җаным,
Сөйдем кызны! Гүзәлне мин кочамын.

Син үзеңне аны күрмәгәндәй тот,
Миннән үгет: бүгенге көнең оныт».

Ике якта кызганнан-кыза гауга,
Керештеләр берсен-берсе хурлауга.

Тус та, Гив да: «Калганчы,— ди,— оятка,
Чабам кызның башын, тик бирмим ятка!»

Ул арада килеп җитте Гударз,
Сорый: «Нидән буш гауга куптардыгыз?

Юк, койдырмыйм бу гөнаһсызның канын.
Бездә шаһ бар. Тыңлыйк хөкемен аның.

Шаһ хәл итсен. Кем аңарга карышыр?
Бәхәстә кем аның белән ярышыр?!»

Килештеләр. Атландырып бер атка,
Кызны болар алып кайттылар шаһка.

Күз салуга Кәвыс кызның йөзенә,
Гыйшык уты капты аның үзенә.

Шаһның калмады кальбендә карары,
Батырларга ялварулы карады:

«Шәрәф һәм шан булсын,— ди,— атыгызга,
Китердегез тансык ау шаһыгызга.

Ызгыш салган сөякме бу арада?
Бер-берегә усалланып карама,

Сиңа язган ашны берәү йимәс һич,
Сез әйтешкән сүзне кеше димәс һич.

Сарай өчен кирәк мал — харам өйгә,
Килешегез! Бу кыз булачак миңа!»

Бирде аларга кыйммәтле бүләкләр,
Рәхмәт әйтте, бирде мул сый, хилгатьләр,

Болар китте сарайдан, хәйран калып,
Күзләрдә яшь, әрнүле яна калеб.

Кызга ди шаһ: «Гамеңне куй, ниһаять,
Син — сусаган җаныма әбелхәят.

Сараемда булырсың олы хатын,
Иран шаһы тәхете — синең хакың.

Балкый билге йөзеңдә олылыктан,
Син кем кызы, нинди нәсәб-ыруглан?»

«Болгар шаһы, Гәрсиваз оныгы — атам.
Чарам бармы? Мин дә сине яратам».

Шатланып, кызны илттеләр сарайга,
Күргәннәр охшаталар тулган айга.

Боерды шаһ аңа ничә йөз кырнак,
Каләмдәй бармаклары, көмеш тырнак.

Карышусыз булалар хезмәтендә,
Көндезендә, кичендә, кара төндә...

Тәмам булды — җиренә килде бар эш.
Кабат тапты яшьлеген гүя Кәвыс,

Кичә-көндез булды гүзәл янында,
Бирердәй ул аңа хәтта җанын да.

Максатына иреште ахыр ул шаһ:
Бер ул бирде гүзәлдән аңа Аллаһ,

Йөзе тулган айга, кояшка охшаш,
Күргән кеше сурәтенә ияр баш.

Килеп җитте шаһка сөенче сүзләр:
«Тиңсез матур ул,— диләр,— тапты гүзәл.

Чәче — ганбәр, ирне — якут, йөзе — гөл,
Күрсә, кояш оятыннан күзегер!»

Сөенчегә сипте шаһ мал, хәзинә,
Канат үскән кебек булды үзенә.

Бәйрәм ясап, гөрләтеп бар дөньяга,
Сиявуш дип ат куйдылар балага.

Улын күреп сөенде шаһның җаны.
Аның белән тулды бөтен җиһаны.

Бар иде бер бик галим-мөнәҗҗиме,
Таныш иде аңар бар йолдыз гыйльме.

Шаһ алдына чакыртты тиз үк шуны,
Диде: «Остаз, күр, оныттып курkуны,

Йолдызлардан бу баланың язмышын,
Ничек кичәр бу дөньяда җәй-кышын?»

Кабат-кабат күзәтте дә санады
Галим. Ахыр, сынган кебек канаты,

Җиргә атып бәрде ул астрләбен:
«Хакны сөйлим, шаһым,— шул ич таләбең,

Юк, көн бирми замана бу балага,
Юлыгыр ул баш котылмас бәлагә».

Шаһ, бармагын тешләп, моң, уйга талды,
Шатлык биргән өметләре буталды.

Хактан килгән язмыш икән, ни чара,
Кем язмыштан газиз җанын коткара?

Бу серне шаһ әйтми үзгә йә ятка.
Малай үсә. Инде басты аякка.

Гүзәллеге илдә хикәя булды,
Аның даны бөтен Галәмгә тулды:

Матурлыгы — табынырлык күңелләр!
Әдәп! Акыл! Һәркөн яңа һөнәрләр!

Аермады Кәвыс аны үзеннән,
Күзен өзә алмый гүзәл йөзеннән.

Шулай беркөн Рөстәм кунакка килде.
Шаһ алдында ул Сиявушны күрде.

Җир үпте дә, сүз сорап, әйтте Рөстәм:
«Үз өендә бала — мәхрүм дәрестән.

Миңа тапшыр, буш үткәрми көннәрне,
Бирим аңа үземдә бар һөнәрне.

Үскәч, бала илгә башлык булалсын,
Мин укытыйм, миннән белем ул алсын».

Бу киңәшкә куркынып калды хәйран
Кәвыс. Ләкин таба алмады дәрман.

Туймас иде бу баласы сүзеннән,
Куймас иде читкә аны күзеннән.

Тәрбиясез калдырсынмы? Ни чара?!
Тәһмәтәнгә бирде аны бичара.

Диде Рөстәм: «Күрик, нишләр замана?» —
Китте алып Забулстан ягына.

Бала — һәвәс, канәгать Рөстәм аннан,
Ни күрсә дә өйрәнә пәһлеваннан:

Сөңге тоту, гөрзи сугуның серен,
Уктан ату, аркан — калдырмый берен;

Атта чабу, яуны егу иярдән —
Дәрес ала Рөстәм белгән һөнәрдән.

Кичләрендә — мәҗлес, сөхбәт тәртибе,
Белем алу булды аның һәр көне.

Хәтәр эштән, авырлыктан куркырга
Куймый остаз: китәләр ауга кырга;

Юлбарыска ялгыз каршы чыгулар,
Җирдә йоклау, кырда учак ягулар.

Булды шаһзадә бу эшләр остасы,
Күреп уңышын, соклана остазы.

Еллар арты акты да акты еллар,
Остаз белән ярышып ныгый куллар.

Остаз инде үзе шәкерт шәкерткә,
Житез егет охшый лачын, бөркеткә.

Беркөн шәкерт серен ачты остазга:
«Читтә ялгыз охшыйм дуадак казга.

Һөнәремне күрми ич ата-анам,
Мин аларны сагынудан уфтанам.

Күрсә атам, рәхмәт, диер, Рөстәмгә».
Тәэсир итте бу сүзләр Тәһмәтәнгә.

Ул хәзерли шаһзадәгә бүләкләр:
Качыр һәм ат, ука чиккән күлмәкләр,

Алтын корал, ләгыль[1], җәүһәрдән — бизәк,
Кол малайлар, ай йөзле күп кәнизәк.

Чыкмасын дип юлында ул-бу бәла,
Шаһзадәне үзе озата бара.

Шаһ ишетте: шаһзадә кайта илгә,
Рөстәм аны үзе озата килә.

Боерды шаһ: «Бизәлсен,— ди,— бөтен ил!
Шаһзадәгә каршы чыксын хатын-ир!

Юлга чыккан көтү кебек күп халык,
Бәкләр чапты каршы, атка атланып.

Шаһзадәне күргәч төштеләр аттан,
Тез чүктеләр, сәлам биреп ерактан.

Телгә килде курай, быргы, барабан,
Шат авазлар белән тулды чүл-ялан.

Һәммә кеше тоткан алтын савытлар,
Сирпи юлга гүзәлләр хушбуй-гудлар.

Кол, кәнизәк тоткан тулы табаклар,
Тулды сипкән тәңкәгә тирә-яклар.

Сиявушның йөзен иткән тамаша
Аңын җуя, гүя гакылдан шаша.

[1] *Ләгыль* — ал, кызыл төстәге кыйммәтле таш.

Ике яктан гаскәргә юл ачалар,
Шул тәртиптә ирештеләр шаһка алар.

Шаһны күреп, якын килде Сиявуш,
Кояш кебек балкый йөз, күңеле хуш.

Аттан төште бәкләр — аның артында,
Җир үптеләр барсы шаһның катында.

Шаһ күңлендә калмый сабыр-карары,
Хәлсезләнеп, бу гүзәлгә карады.

Тәхетеннән җәһәт төште дә җиргә,
Тотынды ул улы йөзен үбәргә.

Улы йөзен сагынган иде гаять,
Булды күрү — күңелгә әбелхәят.

Буен-сынын күреп хәйраннар калды,
Күңелдәге бар гамь, хәсрәт югалды.

Шаһ Рөстәмгә диде: «Әй пәһлеваным,
Юлларыңа корбаннар булсын җаным.

Миңа һәрчак сансыз хезмәтләр иттең,
Кем хезмәте синекенә булыр тиң?

Минем өстә сиңа — сансыз бурычым,
Ул бурычның өзәлмәм, дим, һич очын,

Хак бирсен хак ул чиксез хезмәтеңә!» —
Тартып алды Тәһмәтәнне катына.

Кулын кыса. Кидерде кыйммәт хилгать,
Бүләк итә сансыз мал, әйтә рәхмәт.

Шуннан илдә башланды бәйрәм-сыйлар,
Җиде көн-төн эчәләр дә ашыйлар.

Бәйрәм узгач, ачып хәзинә малын,
Сиявушка шаһ тапшырттыра барын.

Бирә атлар, качыр, төя, күп коллар,
Аның исеменә яздырта икълимнәр.

Бәхет озак, төгәл тормый — кителә,
Язмыш үртәп, ачы агу китерә —

Ул әрнүле тозак куйган анага.
Гүя кайткан Сиявуш җеназага:

Ул кайткан ел әнисе калды үлеп,
Бер ел үтте әрнүле матәм күреп.

Шаһның әүвәлге хатыны бар иде —
Сарай бикәсе, киңәшче яры иде,

Һамавиран шаһы кызы — Судабә,
Шаһ сарайны тапшырган иде аңа.

Шаһ, Сиявуш беркөн тәхет залында
Утырганда сүз куертып табында,

Бер эш белән Судабә килде кереп,
Хәйран калды ул Сиявушны күреп.

Каны кайнап, йөрәккә капты уты,
Гашыйк булды егеткә шул минуты.

Якын иде һуштан китеп аварга,
Кәвыс сизәр нинди хәйлә табарга?

Тел тотылды, баштан очкандай акыл,
Бәйләнгәндәй булды күңел, аяк, кул.

Шаһы белән сөйләшеп бер-ике сүз,
Китте чыгып, елмаюсыз, көлүсез.

Сараена көчкә кайтып утырды,
Ике күзе кайнар яшь белән тулды.

Хәлен-зарын сөйли алмый кешегә,
Бүлмәсеннән чыга алмый күршегә.

Күз алдында, күңелдә — ул, хыялда,
Аңардан юк моңа йокы да, ял да.

Бер-ике көн шуңар канәгать кылды,
Күңеленә яңа коткы ягылды:

Ничек аны тагын бер кат күрәсе?
Күз алдыннан бер ничек үткәрәсе?

Үткен телле чая бер кәнизәген
Чакыртты ул: «Өзелә,— ди,— үзәгем.

Сиздерми үт Сиявуш аулагына,
Сәламем әйт, төш аның аягына.

Әйт син аңа: дәртендә мин, бичара,
Янам утсыз. Бәхетем, йөзем кара.

Күзем нуры — аягының тузаны,
Көтәм, текәп юлларына күз агы.

Ни югалта, күренсә бер күземә,
Итим җаным кара туфрак үзенә».

Хуш килмәде бу сүзләр Сиявушка,
Диде: «Җаным, йөремә монда бушка.

Куй, син мине булмас эшкә чакырма,
Ханшаны һәм үзеңне җәфа кылма.

Күзәтсә дә ул нәфсенең моратын,
Мин шаһымның хурламам олы атын.

Китермә сүз, колак салма кешегә,
Бу дәрт — йөрәк түгел, Иблис эше лә».

Егет җавабын арачы ишетте,
Җир үпте дә килгән юлына китте.

Аягүрә Судабә каршылады,
Сабыры юк, тиз ул хәбәр сорады.

«Бу киек,— ди илче,— төшми тозакка.
Сабыр кирәк, ау китәр, дим, озакка,

Гүзәл хәлвә, тик чара ни? — Пешмәгән,
Шуңа безнең иренгә ирешмәгән.

Сарыф иттем татлы тел, йөз көләче,
Тик җавабы булды агудан ачы.

Башка чара — хәйлә кирәгер безгә,
Үзе сизми эләксен авызыбызга».

Үтте тагын бер-ике көн зар белән.
Өченче көн торды ханым таң белән.

Шаһка барды. Диде: «Бәхетле шаһым,
Гомереңне озын итсен Иляһым.

Алла сиңа милек — Иранны бирде,
Нәрсә Хактан теләсәң, аны бирде.

Дошманнарда калдырмадың үчеңне,
Бар Галәмгә таныттырдың көчеңне.

Гыйшык белән, наз белән сөрдең гомер,
Галәмдә юк син күрдең гүзәл угыл.

Морадыңа ирештең һәр тарафта,
Сиңа тиң бер шаһ бармы тирә-якта?

Йә, улыңа тиң бармы бу көннәрдә,
Әдәптә, йә дәүләттә, йә һөнәрдә?

Телим, аңа әйт син мәрхәмәтеңнән,
Чыккаласын кайчак синең катыңнан.

Мин дә аңа ана тиеш ләбаса,
Кардәшләрен килгәләсә, караса.

Юк, диме ул, безнең белән эшләре?
Аны күрсәк, диләр кыз кардәшләре,

Аңа без җан белән хезмәт кылырбыз,
Хөрмәт итә, хезмәт итә белербез».

Кәвыс әйтте Судабәгә: «Ай йөзлем,
Йөзең кебек гүзәл һәм тансык сүзең,

Җаның тулы аналык мәрхәмәте,
Җавап булыр аңа — бала рәхмәте».

Судабә шат, китте үз сараена.
Шаһ чакыртты Сиявушны янына.

Диде: «Тыңла, гомеремнең маясы,
Дөнья — синңа, безгә тик — картаясы.

Өч нәрсә бар, кеше һич яшермәслек:
Исереклек, гыйшык, берсе — кардәшлек.

Сараемда ничә кыз кардәшең бар,
Сине күреп танышсак, диләр алар.

Һәм Судабә — сиңа булыр ул ана —
Сине көтә кунакка, яна-яна.

Син — гүзәл, дип гөрли урам, базарлар,
Кардәшләрең сине күрергә зарлар.

Йөз чөермә кардәшләрдән, анадан,
Бар аларга — санамасыннар надан».

Атасының киңәше Сиявушка
Шомнар салды: «Түгел,— ди,— бу сүз бушка».

Уйлый: шулай сынамакчы атасы,
Аның ничек күңелен юатасы?

Уйлый милке: «Куһистанга китәргә,
Телим чиктә, яуда хезмәт итәргә.

Әгәр миңа Судабә булса ана,
Кулын кушсын синең миңа догаңа.

Хатын-кызлар бүлмәсе тансык кемгә?—
Ир-егетне әйләндерә җебенгә.

Хатын-кызлар эчендә күп сүз була,
Ул сүзләрдән кеше гайрәтсез була.

Бикләп булмый илнең авызын сүздән,
Минем хакта сүз кубар ирексездән.

Хатын-кыздан килә иргә күп җәфа,
Мине: «Бар»,— дип мәҗбүр итмә ул якка.

Никадәрле ерак булсам алардан,
Беләм, тыныч, сәламәт җан белән тән.

Мине, зинһар, ул бүлмәдән ит ерак,
Авыр эштә сынаганың яхшырак.

Ирләр эше — чәүган, мәйдан, яу кыры,
Шул мәйданда минем даным артыры».

Йөз чытканын шаһзадә күрә шаһның.
«Миңа бердәй әмре шаһның, Иляһның.

Кызлар ягы әгәр булса җәһәннәм,
Хәтрең өчен керәм, һич чикмимен гамь».

Шаһ куанды: «Уең йөзеңдәй якты,
Сүзең тозлы, ләкин хак, җанга татлы.

Кил, баш тартма минем бу тәкъдимемнән,
Кыз кардәшләр күңелен тап бүгеннән».

Эчке йортта иде хатын-кыз ягы,
Анда басмый бер ир-атның аягы.

Эчке йортның сагы — Фәрзанә иде.
Шаһ аңарга тиңсез ышана иде.

Чакыртты шаһ каршысына шул колын,
Аның кулына бирергә угылын.

Диде: «Бар да алып эчке сарайга,
Күрсәт гүзәл йолдызларны бу айга.

Судабәгә әйт син минем исемнән:
Сөйсен моны артык үз энисеннән.

Түшәсен ул аяк астына ганбәр,
Кызганмасын бүләккә ләгыль, җәүһәр».

Сиявушны ияртеп керде юлга,
Китә биреп сәламнәр уңга-сулга.

Хәбәр очырды Фәрзанә сарайга:
«Бер зур кунак, охшаган тулган айга,

Килә, чыксын олы-кече каршылап,
Хушбуй сипсен юлга кызлар яхшылап.

Хәзерләнсен сибәр өчен табакта
Алтын-көмеш, асылташлар һәр якта».

Бу хәбәргә Судабә бик сөенде,
Бизәнеп, ул алтын тәхеткә менде.

Бизәделәр сарайны гөлләр белән,
Түшәделәр аяк астына келәм.

Энҗе, якут тулы алтын табаклар,
Яшь кызларга тулды бар тирә-яклар,

Гүзәл, җәннәт хуры кебек һәрбере,
Ризван күрсә, көяр иде бәгыре.

Һәр тарафта сыза сазлар шат көйләр.
Кызлар юлга энҗе, алтын чәчтеләр.

Шаһзадә: «Бу — сараймы, җәннәтме?» — дип
Калды күргәннәрдән гаҗәпләнеп бик.

Керде, күрде алтын тәхет сарайда.
Ул тәхеткә янбашлаган Судабә.

Дулкынланган чәче җитә аякка,
Гүзәллеге сибә нур тирә-якка.

Сиявушны күреп торды ул очып,
Каршы килде, муйныннан алды кочып.

Дәрте уты көйдергән иде җанын,
Сылтау тапты, ачты моңа кочагын.

Ул сарылды, күздән, иреннән үбә,
Кайнарлыгы кабынып күлмәгенә.

Оятыннан Сиявуш батты тиргә,
Утка төште, тетри, авардай җиргә.

Ә Судабә сүз кузгата назланып:
«Ник йөрисең сүзең бездән кызганып?

Кыз туганнар йөзең күрергә зарлар,
Аларны да шатландырчы бераз, бар».

Егет үтте кызлар ягына, каушап,
Алды анда гөлдәй гүзәлләр коршап,

Үбә кайсы кулын, кайсы — яңагын,
Шау-шу, чыр-чу гүләтте тирә-ягын.

Сәламләшеп, аннан да китте чыгып,
Сараена кайтты арып-талчыгып.

Күрешкәч, шаһ сорый тәэссоратларын.
«Син калдырган артта Галәм шаһларын,

Сарай — җәннәт, гүзәлләр — хур кызлары,—
Ди Сиявуш,— кайсы шаһның күзләре

Күргән, дисең, мондый гүзәлләр йөзен.
Сиңа тиң юк, Галәмдә син — берүзең,

Фәридун, Җәм, Һушәңме соң тиң сиңа?
Алар ярый кол булырга каршыңа!»

Куандырды атасын шулай егет.
Балкып китте Кәвыс йөзе гөл кебек:

«Борчулардан азат булды йөрәкләр...» —
Улына ул бирә сансыз бүләкләр.

Шатланып, шаһ китте эчке сарайга,
Җыелдылар гүзәлләр тирә-янга.

Шаһ боера аларга күп бүләкләр:
Алтын алка, балдак, атлас күлмәкләр.

Судабәгә килде дә шаһ сүз ата:
«Йә, бу малай нинди тәэсир уята?

Әдәп, гадәт, белем бармы үзендә?
Ничегерәк күренде ул күзеңә?»

Диде хатын: «Ишет сүзнең турысын:
Даның бөек — тәхет, илнең нуры — син,

Сиңа тиң бер хан булмас бу җиһанда,
Улыңа тиң солтан булмас заманда,

Аңа — бөтен Галәм халкы догачы,
Ярашырлык үзенә тәхет, таҗы.

Баштанаяк белем, әдәп үзендә,
Табылырмы аңа тиң җир йөзендә?

Сүз, авазы! Әйтмимсең күз карашын?!
Ә хәясы! — Җирдән күтәрмәс башын!

Ни изгелек итсәң аңа, ярашыр!
Гыйззәтен син аның башыннан ашыр.

Әле менә бер фикер туды миндә.
Рөхсәт биреп, шуны ишетсәң син дә,

Сиявушны ярattым үз улымдай,
Күпме кызлар яши минем кулымда.

Арада бар гүзәлләр олы затлы,—
Аталары Кәй-Пәшин, Ареш атлы!

Ул өйләнер, бәлки, минем кызыма?
Аны кияү итәр идем үземә».

«Бик хуп булыр,— ди Кәвыс,— бу фикерең,
Егетнең мин тартып карармын кылын».

Икенче көн шаһ егеткә аулакта
Киңәш итеп сүз кузгатты шул хакта:

«Сине күрсәм, чумам чиксез рәхәткә.
Телим, син дә иреш шундый бәхеткә.

Мин ишеттем күптән бер мөнәҗҗимнән,
Килә, диеп, бер ул дөньяга синнән.

Ул — булачак тиңсез шаһы җиһанның,
Өйлән, сәбәбенә кереш син аның.

Кемнең кызын теләр булсаң җиһанда,
Алып бирәм аны шул ук заманда».

«Бойрык — шаһтан, баш өсте! — ди Сиявуш,—
Ни әйтсәң дә, каршы чыгармам тавыш,

Тапса кемне лаек дип шаһым — атам,
Шуны телим мин дә, шуны яратам».

Яна йөрәк Судабә фетнәсеннән,
Аңлый, бу да — шул, аның хәйләсеннән.

Ул төн кичте. Судабә торды таңда.
Яна йөрәк Сиявушның дәртендә.

Бизәттерде сарайны мең бизәккә:
«Сиявушны чакыр»,— ди кәнизәккә.

Бизәнде дә үзе тәхеткә чыкты.
Җуйды сабрын, көтә-көтә талчыкты.

Бусагага җиткәч егет аягы:
«Хуш килдең,— ди,— әй җанымның кунагы»,—

Очып төшеп, аны кулыннан алды,
Үз янына — тәхетенә чыгарды.

Билен кочкан. Мәгъшукына сыена.
Чакырттырды кызларны каршысына.

Гөл яңаклы, кара күзле гүзәлләр
Килеп, тәхет каршысына тезеләләр.

Диде хатын: «Бу гөл йөзлеләрне күр,
Боларга тиң булмас җәннәтеңдә хур.

Сал боларның берсенә шәфкать күзең,
Хатынлыкка ал берсен, сайлап үзең».

Тора кызлар, өметтән балкып гөлдәй,
Очып килеп кочагына керердәй.

Үртәлүдән тиргә бата, кызара,
Мескен егет күз дә салмый кызларга.

Китте кызлар, ишарә иткәч ханым.
Ә Судабә егеттән сорый тагын:

«Ирнең һаман ачылмаган, бөредә!
Ошамыймы бу кызларның бере дә?

Алар — корбан синең йөзең нурына,
Ата берсен, һәм ул булыр куйныңда».

Авыз ачмый сүзгә һаман Сиявуш.
Ә Судабә гыйшык мәеннән сәрхуш:

«Җаным, аңлыйм, ник йомык синең күзләр,
Айны күргән нигә дип йолдыз күзләр.

Мин бар икән, кем аларга карасын?!
Мин дәвалыйм йөрәгеңнең ярасын,

Беләм, беләм, миңа тешләреӊ кыза!
Мине күргән — карасын нинди кызга?

Кил, икебез ант белән сүз беркетик,
Шуннан икәү акыл белән эш итик.

Мин дә янам синеӊ дәртеӊдә, җаным.
Ни боерсаӊ, мин — юлыӊда корбаныӊ.

Күрәсеӊ бит, дәрттән бәгырем — кандыр,
Иреннәреӊ балына мине кандыр.

Синеӊ нурлы йөзеӊ күргән сәгатьтән,
Көн-төн дими, дәрттә яна җан һәм тән.

Гыйшык уты оят пәрдәсен ягар,
Синеӊ гыйшкыӊ калдырмады миндә гарь».

Кочаклады, кысты тәхет читенә,
Ирнен үбә, йөзен ышкый битенә.

Янды егет оят, гарьлек утында,
«Ни йөз белән күренәм,— дип,— атама?

Юраганым менә инде юш килде:
Тиӊсенми бу хәтта шаһны — этине!

Курка идем шул хатын-кыз — бәладән,
Ишетәмме инде ата нәләтен.

Әгәр миннән хәзер чыкса каты сүз,
Яла тага, шиксез миӊа, хәясыз.

Телгә калам, бөтен илдә хур булам,
Әтиемнеӊ ләгънәтенә юлыгам.

Кирәк монда акыл-хәйлә чарасы,
Ничек башны моӊардан коткарасы?»

«Син,— ди егет,— тиӊсез Галәм эчендә,
Синдәй гүзәл юк ул Чиндә, Мачиндә!

Шаһ бар икән, сиңа күз салса бер ир,
Шаһ ачуы аны, йортын көйдерер.

Ничек салыйм күз син кояш йөзенә?
Кем утыра арысланның тезенә?

Кызың бирсәң, кабул итәм, сүзем юк,
Ләкин башка йөзгә багар күзем юк!

Бәләкәен. Үссен, көтәм, карышмыйм,
Шул нияттән читкә чыкмам каршы мин.

Үзеңне һәм мине ташлама утка,
Беләсең бит: Кәвыстан Галәм курка!

Минем өчен ана син, газиз ана:
Начар баккан анага — утта яна!

Бар булган сүз калсын ике арада,
Ант, сер саклыйм. Син дә җиңел карама».

Утка төшкән, кызарган оятыннан,
Китте егет Судабәнең катыннан.

Кич булды. Шаһ килде эчке сарайга:
«Таптыңмы кыз,— ди,— безнең тулган айга?»

«Бар кызларымны күрсәттем үзенә,
Күз дә салмый һичберсенең йөзенә.

Кызыңны, ди, үскәч, кабул итәрмен».
«Рәхмәт,— ди шаһ,— күңелемне күтәрдең».

Шаһ боерды ул кызга күп бүләкләр —
Энҗе, җәүһәр, алтын, ука күлмәкләр.

Бу малларга Судабә бик куанды,
Көннәр үтте. Эчтә дәрт һаман янды.

«Сиявуш!» — дип, эчтән чыга сулышы,
Аны тели, калмады сабыры, һушы:

«Ярабби! — ди.— Нинди чара табасы?
Күкне каплый, аһ, дәртенең карасы.

Ул гүзәлне ничек кертим кочакка?
Мин — ялкында, ул боз кебек бер чакта!

Әгәр ятсам алдында, дәрттән үлеп,
Су каптырмас миңа, рәхиме килеп.

Аның өчен янармын кайчангача?
Аһ-зарыма кайчан колагын ача?»

Тагын аны чакыртты сараена,
Тагын алды тәхеткә үз янына:

«Мәрхәмәтсез, күз салмыйсың йөземә!
Гыйшык аһын камчы иттең үземә.

Ул аһларның сөреме күккә ашты,
Тән, җаныма ачы ялкын тоташты.

Ничен миннән чөерәсең йөзеңне,
Кызганасың бер кәлимә сүзеңне?

Күрәмсең? Мин — суга сусаган гөлмен!
Бетте сабрым, мин дә бит таш түгелмен.

Җиде ел бит, гамеңнән, әй кояш йөз,
Бер мизгелгә калмады күзем яшьсез!

Синнән башка ярдәм итәлми һичкем,
Димисең бит: «Ничек хәлләрең, мескен?»

Ни була соң, сөендерсәң җанымны?
Фида итим җанымны, җиһанымны.

Күпме бүләк биргән булса атаң, мал,
Ике тапкыр артык бүләк миннән ал.

Кулымнан тот, мин аяктан егылдым,
Сиңа кавышу дәртеңә мин ягылдым.

Бетте сабрым. Калмады хәл, чыдамым,
Бу язмышка артык түзалмый җаным.

Йә сөясең, юк минем башка чарам,
Йә Галәмгә яман атың чыгарам.

Син аяусыз, ник мин сине аяем?
Ачы дәрттә җаным телгәлим даим?»

Бу сүзләрне ишеткәч, Сиявуш та
Күп вакытлар килә алмады һушка.

Ахыр әйтте: «Әй Галәмнең матуры,
Синең ирең — минем атам, ахыры,

Юк, хыянәт италмыйм мин әтиемә,
Үзең саф кал, минем намуска тимә.

Буем бирмәм, ни килсә дә башыма,
Хәтта риза бар Галәм җәфасына,—

Үлем тансык миңа бу әңгәмәдән,
Риза булам, башсыз калса да бәдән».

Бу сүзләрдән шаша язды Судабә:
«Әрнер өчен җаным сине сөйдеме?

Мәрхәмәт юк тамчы синең җаныңда!
Кайчангача җаным утка ягыла?!

Күрсәтәм мин сиңа шундый әрнүне,
Менә шунда искә алырсың мине».

Тартып ертты ул киемен, якасын,
Тырный битен, борнын, йөзен баса кан,

Күккә ашты череλдәвек авазы,
Башын бәрә, чәчләрен йолка үзе.

Бу хәлләргә игътибар итми, егет
Китеп барды, үлемгә барган кебек.

Ыгы-зыгы, шау-шу сарайда купты:
Кем — юата, кеме — яшькә булыкты.

Хезмәтчеләр чик куялмый тавышка,
Хәбәр иттеләр бу хәлне Кәвыска.

Килеп җитте сарайга Кәвыс тиз үк,
Күрә: ызгыш, тетрәнә гүя җир-күк.

Күрә: хатыны, әрнүләр салып җанга,
Җылый, йөзе-башы булашкан канга;

Үкерешә тирәдә кәнизәкләр,
Әрнү зары, өзелерлек үзәкләр.

«Ни булды?» — ди. Көтмичә җавап сүзе,
Судабәгә туры йөгерде үзе.

Диде: «Ярабби, купты монда ни гауга?
Ник үзеңне хур итәсең җиһанга?

Җенләндеңме? Әллә үз чирең бармы?
Ник куптардың бу кадәр чыр-чу, зарны?»

Судабә дә шаһның килгәнен күрде,
Илереп, ул аяк өстенә торды.

Аягына төшеп Судабә шаһның,
Диде: «Ишет сәбәбен үксү-аһның.

Болар бар да — сөйгән, битсез улыңнан.
Килде бүген: алды ике кулымнан,

Оят пәрдәсен йөзеннән күтәрде,
Миңа сарышып, тәхеткә утырды.

Сөйли миңа шашып оятсыз сүзен,
Кабатларга ул сүзне кыймый йөзем.

Тилердеңме, ни кылануың, дидем,
Мин түгел ич, кәләшең — кызым минем.

Мин янам, ди, синең гыйшык утыңа,
Әрсезләнеп, тәннәремә тотына.

Йөрәгем, ди, синең дәртеңдә яна,
Ярсуымны назыңда кандырсана.

Хак бирде, ди, безгә кавышу чакларын,
Әрәм итмик вакыт, ач кочакларың;

Кызыңны мин сылтау иттем, ул бала,
Син барында, кемгә кирәк дөньяда.

Сине күргән — атасына сатамы,
Китәрәм, ди, ике арадан атамны.

Атам китә, сине хатын итәмен,
Татып яшим хөкем, мәхәббәт тәмен.

Оят кирәк, тукта, дидем, хәясыз,
Хәрәменә атаның кем сала күз?

Кем атаның түшәгенә күз сала,
Кыяматтә мәңге тәмугта яна!

Сөя атаң сине, тиңләп җанына,
Кул салырга телисең син канына?

Җитәр, диде, сүз озайтып утырма,
Буйсын миңа, вакыт уздырып торма.

Мин башымнан кичәм синең юлыңда,
Ул карт түгел, мин булырмын куйнында!

Чыдамадым, бер суктым яңагына.
Сөйрәп алды да ул мине янына,

Таҗны сугып төшерде дә башымнан,
Күлмәгемне аерды якасыннан.

Мин кычкырдым. Ул битемә тырнагын
Батырды да ялтыратты аягын».

Хәйран калды Кәвыс тыңлап бу зарны,
Йөрәгенә гүя хәнҗәр кадалды.

Мондый нәрсә көтми иде улыннан.
«Нәрсә чыкмас дисең яшьләр кулыннан?

Хурлау, әрнү, җәбер күрмәсә, хатын
Күтәрерме сәбәпсез сарай халкын?

Дөрес чыкса әгәр Судабә зары,
Бу малайга тиеш хөкем карары,

Ил эчендә үгет, гыйбрәт булырлык,
Эчке сарайның гайбәтен куырлык».

Боерды ул бушатырга сарайны:
«Чакырыгыз монда,— диде,— малайны!»

Тәхетенә утыртты Судабәне:
«Фаш ит,— диде,— күзе алдында аны».

Күренүгә Сиявуш, кызды Кәвыс:
«Әй, битеңдә калмаган оят, намус!

Бире кил дә хөкемемә бир җавап:
Керттем сине бу якка, битле санап.

Балам, дидем, син битсезгә инандым,
Ил алдында хурлык утында яндым.

Бу — кан юлы. Тик хаклык йолар башың,
Сөйләп хакны — җаныңны коткарасың».

«Галәм шаһы! Бу эшне,— ди Сиявуш,—
Ныклап тикшер: кем — гөнаһсыз, кем — явыз.

Кара йөзгә пәрдә булмасын акшар,
Ялганчының, димә син, күзе шартлар...» —

Дип, Сиявуш бар булган хәлне ачык
Сөйләп бирде. Ә Судабә: «Мактанчык,

Оят бел,— ди,— шаһым, ышанма аңа,
Ул килде дә үзе бәйләнде миңа.

Мин күрсәтәм синең кызга бүләкне,
Бу ди, миңа кызың, малың кирәкми.

Син кирәк, ди, кирәк, ди, синең назың,
Мине коча. Мин күтәрдем авазым.

Буемда бар: балага үткән чагым,
Буа баламны, дим, синең кочагың.

Мин карыштым, бирмәдем буем аңа,
Күлмәк ерта! Бит тырный! Дими «ана».

Уйлый Кәвыс: «Гаепле берсен-берсе,
Хакны табу җиңел булмас, ахрысы.

Кирәк моны ныклап тәфтиш итәргә,
Болай мөмкин ялгыш юлга китәргә».

Тикшереп, ул улын исни, кочаклый,
Юк, моңардан мәй, хушбуй исе чыкмый;

Иснәп карый шуннан соң Судабәне,
Мөшек, ганбәргә чумгандай бәдәне!

«Күрәсең,— ди,— гөнаһ бу бәдбәхеттә,
Чабыйм башын, утырмасын тәхеттә».

Кулы бармый, якынлык бар күңелдә:
«Ул яр булды зинданда, кара көндә,—

Диеп искә ала Һамавиранны,—
Үстерергә бар бит ничә оланны...»

Ярар,— диде,— шулай язгандыр тәкъдир,
Ни буларын килер көннәр күрсәтер».

Сиявушка рөхсәт бирде китәргә,
Үзе чыкты сарайга ял итәргә.

Күрә хатын: шаһның күңеле суына,
Эшне аңлый — ачуланмый улына.

«Кирәк чыгарга бу эшнең очына,
Юлыгам,— ди,— юкса шаһның үченә».

Янә мәкер-хәйлә эзли Судабә,
Әрнү-үчтән калмагачтан чыдамы.

Хезмәтендә бар сихерче бер хатын,
Эче тулы мәкер, гүя кара төн.

Соңгы айлар ул йөри иде йөкле,
Судабәгә йөге булды кирәкле.

Дәште аны Судабә аулагына,
Сердәш итеп сөйли сер колагына:

«Шаһ алдында җиргә,— ди,— төште йөзем,
Ярдәмчем бул, һәлак булам ялгызым.

Балаң төшер дару эчеп, бир миңа,
Менә күр, дип, төртим Кәвыс борнына.

Менә нишләде куркытып Сиявуш!
Дип, сарайда күтәрсәм икән тавыш.

Инаныр ул сүземә, әрнер җаны,
Юкка чыгар миңа яман гөманы».

Диде хатын: «Җаным — юлыңа корбан,
Эчәм дару, бирәм дәртеңә дәрман».

Узган иде балага Әһриманнан,
Котылырга юл эзли иде аннан.

Дару эчте. Охшашлы шайтан-җенгә
Игез бала төшертте каршы төнгә.

Килде, диде: «Менә сиңа юл ачык,
Берне түгел, бирәм ике балачык».

Судабә дә бик куанды бу эшкә,
Күмде моны җәүһәр, алтын, көмешкә:

«Качып яшә, кит тә үз эшеңдә бул,
Бу арада оныт син сарайга юл».

Балаларны салды ул алтын тазга.
Тагын бирде ирек ачы авазга.

Эчке сарай тавышка тулды кабат,
Кәнизәкләр юата алмый карап:

«Йөкле идем, төшердем ике балам,
Бу әрнүдән нинди чара табалам.

Теге көнне ябышты, кысты, явыз,
Бу бәлагә гаепле тик Сиявуш.

Күз кыздыра анасына, кара йөз,
Менә нинди хәлгә калдым карагыз.

Яман күздән хәтта саклана идем,
Малай табам, диеп шатлана идем,

Ике малай — бәгыремнең парәсе,
Бу ярадан ничек җан коткарасы!»

Кәнизәкләр илерешә, җылаша,
Җылау шавы гөрләп күкләргә аша.

Аулагында йоклап ятканда Кәвыс
Күзен ачты, ишетеп әче тавыш.

Ди сакчыга: «Барып белеп кил, туган,
Кайда, нидән тагын бу чыр-чу туган?»

Ул арада хәбәрче дә иреште.
Кәвыс, тыңлап, борчылып, төстән төште.

Торып китте хатыны аулагына,
Соң айларда гашыйк ул аңа гына,

Күрә: Судабәсе, барлык кыз-кырнак
Илерешә, әрнеп, йөзләрен тырнап.

Игезәкләргә тап булды шаһның күзе:
«Ни афәт бу?» — диде, калтырый үзе.

Тагын күздән яшьләр түкте Судабә:
«Теге көнне әйткән идем сиңа да,

Йөгем бар, дип, Сиявуш, дип, орынды,
Нәтиҗәсе менә килде, күр инде.

Миңа түгел, анда аңа ышандың,
Күз алдыңда менә, шатлан,— эше аның».

Уйлана шаһ: «Гаеп малайда булса?
Чик бу эшкә куймый булмый лабаса...»

Кәвыс ярсып юнәлә сараена,
Мөнәҗҗимнәрне чакыртты янына.

Диде: «Ахыр, бу эшкә бармы дәрман?
Итсәгезче бу мөшкел эшне асан! —

Табыгыз бу игезәкләрнең йолдызын,
Күрсәтегез миңа бу сернең йөзен?»

Мөнәҗҗимнәр күк йөзен актардылар,
Йолдызларын таба алмый ардылар:

«Йолдызы юк, гел караңгыга тарта,
Игезләргә,— диләр,— Әһриман — ата.

Синнән түгел, Судабәдән дә түгел
Болар, шаһым, юкка төшермә күңел.—

Диләр,— аз да гаеп юк Сиявушта,
Хатын гөнаһлы, гаепле бу эштә».

Судабәне сүгә шаһ күңеленнән,
Тик саклана ил-халыкның теленнән.

Күреп шаһның тагын тынып калганын,
Хатын тагын утта көйдерде җанын.

Шаһзадәне юлыктырам дип үчкә,
Тагын үзе кала ич үкенечтә.

Тагын түкте шаһ алдында ул яшен:
«Шаһым,— диде,— меңнәргә җитсен яшең,

Күрсәт инсаф, гадел хөкем ит мине,
Күрдең ләса ике үлек нәнине.

Минем хәлгә, гаҗәп, салмыйсың күзең,
Ялгыз башым каян табыйм мин түзем?»

«Җаным, сабыр ит,— ди шаһ Судабәгә,—
Тоташ сибеп торма син тоз ярага,

Синең сүзгә кереп әл дә эш итәм,
Эзәрлеклим гөнаһсызны. Ишетәм:

Һәр тәфтиштә аның юк, дип, гөнаһы,
Кемгә төшәр, дисең син, аның аһы?

Шуны раслый әнә бар мөнәҗҗимнәр,
Син бахырны котырта димен җеннәр.

Түз, сабыр ит, тикшерик, белик барын,
Катгый булыр шунда минем карарым.

Сөйләп бирде мөнәҗҗимнәрнең сүзен:
«Сихерчене таптырып күрәм үзем.

Син-мин түгел, ул — балалар анасы,
Шулай диде мөнәҗҗимнең барысы».

«Шаһым,— диде коты очып Судабә,—
Мөнәҗҗимнәр сүзен сүз дип сөйләмә.

Һәркем әйтә, ялганчылар ич алар,
Кукләр кайчан, кемгә серне ачалар.

Белсәләр дә, биктә тотмас телләрен
Шаһзададән курку хисе кемнәрнең?

Кем белми соң, яклаучы шаһзадәне —
Тәһмәтән бар. Кем яклый мин бәндәне?

Матур сөйләп, күңелеңне табалар,
Яклаучысыз миңа яла ягалар.

Син аларны яклашсаң хөкемеңдә,
Даулыйм хаклык мин кыямәт көнендә.

Алла бар бит, син итмәсәң илтифат!
Мин — әрнүдә. Син пошмыйсың. Алар шат.—

Дип такмаклап түкте тагын кан-яшен,—
Яклар иде, булса монда кардәшем!»

Кызганудан күзләрендә яшь шаһның,
Көчле булды аңа тәэсире аһның.

Ул юата, иркәли хатынын сыйпап:
«Гайрәтсез мин бу эштә, сүлпән, син хак.

Тик кайгырма. Ышаныч туса җанда,
Уйнатырмын шундый буран җиһанда,—

Фаш итәрмен бар мәкерләрен аның,
Тик бу эшне сер саклар идең, җаным».

Тагын Кәвыс ашыкты аулагына.
Мабедләрен җыйдырды ул янына.

Киңәш сорап ачты аларга серен:
«Бер мәсьәлә. Каплаган өстен сөрем.

Ике кеше арасында бар тавыш.
Белалмадым: кайсы хаклы? Кем явыз?

Кайсына да җәзага бармый кулым,
Берсе — хатын. Берсе — шаһзадә — улым.

Гаепләне, әйтегез, ничек табыйм,
Явызлыкка ничек мин балта чабыйм?

Озак уйлый хәкимнәр, башны иеп,
Киңәшәләр, алай, дип, болай, диеп.

Мондый фикергә килделәр ахырда:
«Борынгыдан шундый гадәт бар кулда:

Әгәр кеше юлыкса бер ялага,
Киң мәйданда хаким зур ут ягала.

Кем гаепне яла, диеп маташа:
«Мин — хак»,— диеп үтсен ялкын-ут аша.

Ул хак булса, ут пешералмый аны,
Әгәр пешсә, ачыла сүз ялганы.

Бу икенең берсен ялкында сына,
Башка юл юк, шунда тик җаның тына».

«Күңелгә хуш киңәш»,— диде. Хатынга
Килде: «Ялкын нур өсти,— ди,— алтынга.

Ялкыннан үт. Хак булсаң, котыласың,
Кызыл алтын кебек саф, пакь каласың».

«Сынау мине куркытмый,— ди Судабә,—
Ян, диң, янам, керәм утка, суга да.

Тик беләсең: минем бар бит гозерем,
Күз алдында яңа бала төшердем.

Сиявушның нинди бар соң дәлиле,
Аны түгел, утка кертәсең мине?»

Әүвәл сына угылыңны ул утта,
Ул янмаса, мин булырмын чиратта.

Сиявушны китертте. Әйтә хәлне.
«Бу бәладән артык күрәм әҗәлне,

Уттан әче пешерә җанны яла,
Як утыңны. Ул ояттан коткара!»

Ташыттылар коры утын киң кырга,
Калдырып тар сукмак, атта үтәргә.

Күзәнәкләп, таудай өйделәр аны,
Ут төрттеләр. Күргәннең чыгар җаны.

Тәмуг гүя җирдә авызын ачты;
Ярсу ялкын күккә җитеп тоташты.

Сиптерәләр утка нефть һәрьяктан.
Тамашага халык килгән, йөрәк — кан.

Бу кызудан эри еракта ташлар,
Күмер булып егыла очкан кошлар.

Төтен бетте, калды тик балкып ялкын.
Салып әрнү, дәһшәткә кала халкын,

Әтисенә якынлаша Сиявуш,
Ат өстендә әйтерсең бер очар кош.

Оятыннан гөл кебек кызыл йөзе,
Ак киемнән, алтын таҗ кигән үзе.

Шат елмаю иреннәрдә, йөзендә,
Балкый бәхет чаткылары күзендә.

«Мондый ялкын! Кем котылыр аңардан?» —
Шаһ йөрәге әрнеп булды кара кан.

Аттан төшеп, атага кылды сәҗдә.
Әтисенең әрнүләрен сизгәч тә:

«Борчылма,— ди.— Ку кайгыны йөрәктән,
Саф ут кайчан хакыйкатьне көйрәткән?

Янам утта, әгәр булса гөнаһым,
Исән чыгам, гаепсез булсам, шаһым!»

Менде атка. Атылды янган утка.
Күз алдыннан юк булды бер минутта.

Ялкын гүя шаһ җанына тоташты,
Әрнү, үксү даладан күккә ашты.

«Иляһи,— ди егет,— сакла ояттан,
Ил күзендә һәлак иттермә уттан!»

Агымсудай качырды янган утны
Күз яшьләре, ялкын эчен суытты.

Хәбәр барып иреште Судабәгә.
Тоз сиптеләр гүя яңа ярага,

Ул, тузынып, сарай өстенә чыкты.
Янган утка гүя үзе тончыкты.

Күмер булып күренде утта яры,
Күкне телде әрнүле ачы зары.

Ә Сиявуш ялкын эчендә гизә,
Яшь сәмәндәр гүя ки утта йөзә,

Фәрештәдәй гөнаһсыз, пакь булганга,
Ялкынны Хак итте гөлбакча җанга.

Шулай утта бөтерелеп бер сәгать,
Шаһ алдына кайтты егет сәламәт.

Йөзе балкый, гүя нурда чыныккан,
Гүя корыч, балкып, сандалга чыккан.

Котылгандай булды уттан бар халык,
Бар да карый шаһзадәгә таң калып.

Сиявушка мактау җырлыйлар алар,
Энҗе, алтын бүләкләр яудыралар.

Аттан төште Кәвыс улы алдында,
Үксеп үбә, кочагына алды да.

Күрә: хәтта кигән киеме ап-ак,
Ут тимәгән, тимәгән көл йә туфрак.

«Ул явызны юлыктырам каһәргә»,—
Диеп, Кәвыс ярсып кайтты шәһәргә.

Ул каршына китертте Судабәне:
«Ил алдында хөкем итәм,— ди,— аны!

Әй фетнәче! Хаин! — ди,— йөзе кара!
Газабыңнан кем бар сине коткара?

Хаясызның яла сүзенә бактым,
Янар утка газиз баламны аттым.

Юк итмәкче идеңме Сиявушны?
Максатың ни? Ник күтәрдең тавышны?

Дошман итеп балага үз атасын,
Ил алдында мине мыскыллатасың!

Казандың син үзеңә йөз карасы,
Каты булыр сиңа бу эш җәзасы!

Син хур иттең мине бөтен Галәмгә,
Ни йөз белән күреним мин адәмгә?

Юк! Син хур бул: астырам сине дарга!
Илгә гыйбрәт — чукысын тәнең карга!»

«Әй гаделлек чишмәсе,— ди Судабә,—
Бир газабың, әрләп, җаным кыйнама,

Яклаучысыз бу илдә ялгыз башым,
Ата-ана юк янымда, кардәшем,

Булмас яклап сүз әйтәсе зат янда,
Тимәс сиңа куркыныч та, зыян да».

«Мәкерле җан,— ди шаһ,— һаман танамсың?
Дарга фәкать хәйләдән тукталамсың?

Бәкләр, нинди җәза тиеш явызга?
Утырмагыз су капкандай авызга».

Диде бәкләр: «Хөкем — шаһка — иренә,
Ни боерсаң, җиткерербез җиренә.

Гөнаһы зур. Гаебе баштан аша,
Җәза тиеш гаебенә яраша».

«Җәллад! — диеп кычкырды Кәвыс шунда.
Палач гүя җирдән купты каршында.—

Илт мордарны бар, элеп кил тиз дарга,
Азык итсен явызны козгын, карга!»

Чыр-чу купты, илерешә кыз-хатын,
Такмаклыйлар үксеп Судабә атын.

Күкләр тетри, бу әрнүле авазга
Шаһ сискәнде. Уйга калды беразга.

Аяк өскә Сиявуш калка шунда,
Җир үбә дә атасының каршында:

«Шаһым, кич,— ди,— моның кашык канынман!
Минем өчен моның кич гөнаһыннан!»

Белә егет: үкенә шаһ ахырдан,
Судабәсез язар иде акылдан.

Бар ачуы төшәчәк Сиявушка,
Ташламыйм, ди, үземне утка бушка.

Шаһ үзе дә тик сылтау көтә иде:
«Кайтаралмыйм сүзеңне, җаным»,— диде.

Укып рәхмәт күңелдән, шаһ улына
Бирә сансыз мал-бүләкләр кулына.

Ачуланып Судабә бу тавышка:
«Шаһны дошман итәм,— ди,— Сиявушка.

Дус булсалар, монда юк,— ди,— миңа көн,
Ызгышса, ул миңа сыеныр, бәлкем».

Арта кабат шаһ гыйшкы Судабәгә,—
Кара мәче улы белән арага.

Арта көнләп шомнар, шикләр, ачулар,
Шаһзадәгә кайда күңел ачулар?!

Беркөн хәбәр килде ләкин шомчыдан:
«Әфрасияб, яу чабам, дип, көч җыйган,

Сөһрәб үчен сылтау итеп котыра.
Йөз мең батыр, берсе мең иргә тора.

Саранчадай ябырылды бу якка,
Тиз чара тап, сузмаенча озакка».

Бәкләр килде. «Яу бар,— диде шаһ,— чиктә,
Тына белми Әфрасияб ничек тә,

Кайчангача вәгъдәләрен таптар ул? —
Сөһрәбе юк, инде җәза тартыр ул.

Үзем барам! Башын чабам, ниһаять,
Галәмдә бер калсын дастан-хикәят».

«Син тәхеттә утыр,— диләр зур бәкләр,—
Боер, барып күрсәтик без хезмәтләр:

Барып салыйк башын аяк астына,
Без ызгышыйк, ә син, шаһым, ярсыма!»

Ишеттеләр бәкләр мондый җавапны:
«Җиңел түгел җиңү Әфрасиябны.

Аңа һәркем теше үтәр дисезме? —
Җиңсәм, тик мин җиңәрмен ул мисезне.

Кемне итәм ышанып гаскәргә баш?»
«Мине җибәр, мин барыйм»,— ди Сиявуш.

Уйланды шаһ. Тирә-якка каранды.
Егет аның күнен итте караңгы.

Тулысынча ышанып Судабәгә,
Казый иде тирән баз бу балага.

Бәлки, төрек җитәр моның башына?
Чик куяр бу шик-шөмнарның барсына.

Калдырмас хан бу җилбәзәкне тере.
Кирәк булмый анда шаһның мәкере:

«Ярый,— ди,— яу кырында көч сына.
Ал алтын, мал, ачык сиңа хәзинә,

Алтын белән һәр эш җитә ахырга.
Син — җитәкче. Бар, гаскәрне җый кырга!»

Шаһ янына чакыртты Тәһмәтәнне:
«Киңәшчегә күрмим синнән бүтәнне.

Шәкертеңә бул киңәшче син яуда,
Йоклый алам тыныч мин син уяуда.

Синең исем ирешкән яу кырында,
Каласы юк мәйдан дошман кулында».

Диде Рөстәм: «Боер тик мин колыңа,
Җаным бирәм, шаһым, синең юлыңа.

Ул түгел, без — шаһзадәгезгә мохтаҗ.
Башыбызга — аягы тузаны таҗ».

Туйдырды шаһ аны мал, нигъмәт белән,
Куандырды кыйммәтле хилгать белән.

Көн-төн илдә гүләде барабаннар,
Җыелдылар мәйданга пәһлеваннар.

Сансыз гаскәр күмде тауны, даланы,
Байракларның очы телде һаваны.

Шаһ, ачтырып хәзинә капкаларын,
Алтын-көмеш, малга туйдырды барын.

Пәһлеваннар җанын итеп шулай хуш,
Яу юлына аяк басты Сиявуш.

Шаһ күңеле кара кайгыда калды,
Улы белән гүя шатлык югалды.

Сизә күңел: күрешүләр юк башка,
Сагына күңел, тиңли улын кояшка...

Гаскәр Забул чикләренә баргачтан,
Шаһзадәне каршы алды Заль-Дастан,

Җәннәткә тиң сарайга урнаштырып,
Кунак итте аны, күңел ачтырып.

Әңгәмәдә тыңлап Заль дастаннарын,
Сый-мәҗлестә каршы алып таңнарын,

Сәер итеп гүзәл гөлбакчаларда,
Берничә көн рәхәт кичерде анда.

Кузгалдылар. Үтте алар Гератны,
Алып аннан яуга барлык ир-атны.

Мәрв аша юл тоттылар Бәлхкә,
Яуга дәшеп, аваз салып халыкка.

Тураннарга башлык Гәрсиваз иде.
Аның кул астында калган Бәлх иле.

Сул — Сипәһрәм, уң кул булган Барманга,
Ташкын булып кергән алар Иранга.

Хәбәр килеп ирештe Гәрсивазга:
«Иранлылар чыктылар каршыбызга.

Алда — Рөстәм. Башлык икән — Сиявуш,
Сансыз гаскәр, карасаң — китәрлек һуш».

Гәрсиваз тиз атчабар куды ханга.
«Бар гаскәрне китер,— диеп,— Иранга,—

Язды Рөстәм, Сиявушның хәбәрен,—
Үзем,— диде,— хәзер яуга керәмен».

Бар гаскәрен ул Бәлхкә китерде.
Капка бикләп, шәһәр эчендә торды.

Капка алдында башланды бәрелешләр,
Акты каннар, җилкәдән очты башлар.

Өч көн, өч төн булды туктаусыз сугыш.
Шаһзадәгә язмыш китерде уңыш:

Бәреп кереп, шәһәр алды иранлар.
Качты илдән Барманнар, Сипәһрәмнәр.

Ташлап юлга бар коралын, бар малын,
Иран явы котын алды аларның.

Кереп Сиявуш урнашты шәһәргә.
Чират җитте шаһка хатка-хәбәргә.

Язучыны китертте. Яздырды хат,
Мәдех итте Ходаны башта кат-кат:

«Түзми, Бәлх безгә капкасын ачты,
Туранлылар аннан Тирмизга качты.

Хисапсыз күп мал, корал төште кулга.
Безнең гаскәр барып җитте Җәйхунга.

Аргы ярда урнашкан Әфрасияб.
Кем утырыр аның гаскәрен санап?

Мин туктадым. Рөхсәт көтәм шаһымнан,
Боерык килсә, шундук кичәм Җәйхуннан...»

Шатлык хәбәр барып җитте Кәвыска,
Куанды ул җиңүгә, мал-табышка.

Шундук җавап хат яздырды улына:
«...Күзем нуры, җаным корбан юлыңа.

Ил алдында, шөкер, йөзең агарттың,
Өлкәнлектә, хөкем, кадердә арттың.

Таҗ-тәхетне яңадан күмдең данга,
Зәһәр эчерттең узынган дошманга,

Авызыңда әле ана сөте исе,
Бар дошманның синең кулны татыйсы.

Синең кебек улы булган ата-ана
Нинди бәхет таба җирдә, шатлана.

Дошманның син каты кактың тузанын,
Әфрасиябның газабын суз аның,

Дәһшәт салып тор каршында, ашыкма,
Кирәк түгел, аргы як ярга чыкма,

Тик онытма, әфсен, хәйлә аңарда,
Мәкер җитәр бар дөньяңны ягарга!

Бу як ярга чыкса, сабагын укыт,
Китсә, арттан иске пумала ыргыт».

Атчабарга шундук тапшырды хатны.
Очты чапкын, күрми караны-акны.

Хатны алып уку белән Сиявуш
Киңәшләрен атасының күрде хуш.

Ә Гәрсиваз, качкач ташлап Бәлхне,
Ярга куеп гаскәрләрен — халыкны,

Хәбәр алып килде Әфрасиябка:
«Гаскәр белән качып чыктык бу якка.

Килде Рөстәм (тетрим ишетсәм атын).
Гаскәр басты кырны, гүя кара төн.

Сугыш иттек өч көн, өч төн Бәлхтә,
Безнең гаскәр йокы, ялсыз ялыкты.

Ә Иранннар күбәү алар: бергә — ун,
Чиратлашып ялын күрә, йоклавын,

Ничәү баса бер ауганның җиренә!
Минем гаскәр чигенә дә чигенә,—

Ташлап качты соң шәһәрне, бар малны...»
Әфрасияб шундый итеп карганды,

Энесенә ашардай булып бакты,
Көн караңгы, күренми күзгә якты:

«Китмәс мәңге инде йөзең карасы,
Китердең син миңа йөрәк ярасы.

Юк бул күздән, хәсрәт, каршымда торма,
Кальга кулдан ычкындырган — батырмы?..»

Куды моны. «Бирмәсме җанга талда?»
Мәҗлес корды — бәкләр сыйлана алда.

Әйләнәләр мәйгә тулы касәләр,
Кичкә кадәр эчәләр, сөйләшәләр.

Йокы төште Әфрасияб күзенә,
Бәкләр китте, тынлык тапты үзенә.

Ярты төндә гүя алалар җанын,
Ул илереп куркытты сакчыларын.

Дәһшәт алды хезмәтче, сакчыларны:
Шаһ — идәндә, үзе күрми аларны.

Калтырана, никтер ялт-йолт карана,
Хезмәтчеләр килалмый якын аңа.

Китерделәр чакырып Гәрсивазны,
Ул абыйсын коча, юата, назлый.

Әфрасияб уянган кебек булды,
Үксеп, аһ-уһ, диеп, гүя буылды.

«Синҗа, җаным, ни булды? — ди Гәрсиваз,—
Ичмасам, бер авыз ачып каршы дәш».

«Сорама хәл, бераз алыйм тынымны,
Ышаныйм бер: чынлап та котылдыммы?»

Шактый заман энесенә таянып,
Күзен ачмый утырды, калтыранып.

«Дошманына кеше теләмәс моны,
Дәһшәтле төш тетрәндерде җанымны.

Бер үзәнлек күрдем, тулы еланнар,
Авыз ачкан, телен озайткан алар;

Күктә тулган үләксә козгыннары,
Күзне чукып алыр кебек алары;

Очлы тимер кебек ташлар өстендә —
Минем чатыр, шул еланнар эчендә;

Бар бәкләрем, гаскәр минем тирәдә,
Аларга да курку салган күләгә.

Исте кинәт кайдандыр шомлы җил дә,
Чатырымны йолкып ташлады җиргә.

Чапкан кебек ава гаскәр тузанга,
Дәрья кебек ага каннар үзәнгә.

Куркып, әрнеп, һәркем түгә канлы яшь,
Кем: «Әти!» — дип илерә, кем: «Карендәш!»

Тирәдә юк бер хәерле галәмәт,
Гүя купкан җирдә мәхшәр, кыямәт.

Килеп чыкты гаскәр Иран ягыннан,
Тимер кигән барсы, калкан ябынган.

Һәрберсендә озын сөңге. Очында —
Кеше башы. Калдым куркынычында.

Минем өскә килә барсының аты.
Бер кеше юк янымда. Куркам каты.

Килде алар. Мине урап алдылар,
Кул аякка каты тышау салдылар.

Бер батыры салып элмәк муйныма,
Илтте сөйрәп Кәвыс шаһның алдына.

Шаһ янында шундый гүзәл бер егет,
Фәрештәдәй, яңа туган ай кебек.

Арысландай ул урыннан сикерде,
Бер явызы аңа кылыч китерде.

Чапты башым. Улап җан ачысыннан,
Җансыз гәүдәм идәнгә очты сыман...»

«Өндә була ласа төшнең киресе,
Яхшы төш бу, тынычлан»,— ди энесе.—

Хәким, мабед чакырт, калдырмый берен,
Әйтеп бирсен алар төшнең тәгъбирен».

Хәкимнәрен чакыртты, олыларны,
Утыртты ул төш юрарга аларны:

«Төш сөйләрмен. Аны, аның юравын
Һичберәүгә сөйләмисез берәвең.

Төшнең сере ачык күренсә сезгә,
Миңа тик хак сүз булсын телегездә.

Сизсәм әгәр бер ялган сүзегезне,
Калдырмыйммын исән-сау үзегезне».

Өләштерде күп бүләк кунакларга,
Сөйләп бирде төшен соңра аларга.

Каш җыерып, хәкимнәр уйландылар,
Әрнү белән уфтаныштылар алар.

Курку яше мөлдери күзләрендә,
Авыз ачып әйталмый сүзләрен дә.

Алар хәлен күзәтте Әфрасияб:
«Бар хәтәрне күрсәтегез,— ди,— санап!»

«Сөйлә, дисең, җиңел димсең шулкадәр,
Күрә торып, кеше кабамы зәһәр?

Хакны сөйләп, койыйкмы җаныбызны,
Хан ант итсен коймаска каныбызны».

Сүз башлады иң карт, иң олы мабед:
«Хан боера, сөйләмәс идем дә бит.

Хәлләр тора шулай, хан җәнапләре,
Алда илнең бар авыр сәгатьләре:

Бер зур гаскәр, килеп, Туранны баса,
Бер шаһзадә була ул гаскәр башы.

Калмас бәласез төректән бер адәм,
Туран эче — тула мәет, кызыл кан.

Сиявушка монда ирешә бәла,
Иран шулай Сиявуш үчен ала.

Хак язмышы. Аңардан кем котыла?
Оч куккә! Кач җирнең җиде катына,

Котылу юк! Сине эзләп табалар,
Бер сукбайдай күреп, башың чабалар.

Менә шул ул безгә күренгән серләр.
Ни чара бар? Без язмышка әсирләр!»

Агу кебек ачы бу сүзләр ханга.
Яңа әрнү төште куркынган җанга.

Куркуыннан качты ул аулагына,
Көчле сакчы куйдырып як-ягына.

Очты баштан сугыш, табыш һәвәсе,
«Аһ, табылса шул бәланең дәвасы?!»

«Сиявушка,— диләр,— бәла ирешә,—
Үчен алам, диеп, Иран тырыша».

«Туктатам мин аның белән сугышны,
Шул, бүгеннән кичектермим бу эшне.

Кирәк түгел, бирәм илнең яртысын,
Тик, Ходаем, алма көнем яктысын.

Сарыф итәм бар хәзинәм бу юлга,
Булышмасмы язмыш юлын буарга,

Нишлик? Үзе каршы безгә замана,
Юлыгабыз бу юлда гел зыянга!»

Ул чакыртты алдына олыларны,
Таныштырды уе белән аларны:

«Карары юк һич,— диде,— бу җиһанның,
Нигә чабам, эттәй, артыннан аның?

Дөнья, диеп, азмыни мин яу чаптым,
Шәһәрләрне, илләрне утка яктым.

Ничә мең җан койдым яу мәйданында,
Ничә калды әрнүдә, монда-анда?

Нахак каннан җәелә илгә золым!
Кара көннән яктырак хәтта үлем!

Хаким басса җәбер, көчләү юлына,—
Кара афәт ул халкына, иленә.

Максат итсә патша яуны-талауны,
Илендә ул баштан кузгата яуны.

Әбелхәят көчләп сибелсә илгә,
Ил бәхетен очырып иде җилгә.

Золым артса, хәтта корый җимешләр,
Агач көя, картлар шулай димешләр.

Мин дә, ай-һай, күп иктем җиргә золым,
Юмакчымын инде золымнан кулым.

Кайчангача бирәм гомерем зыянга?
Шул, бүгеннән итмим җәбер бер җанга.

Иран белән туктатам сугышларны,
Солых өчен корбан итәм башларны.

Сезне менә чакырдым шул киңәшкә,
Сез ни дисез? Ризамы мондый эшкә?»

«Бик мәслихәт! Уйларың изге, әй шаһ,
Озын итсен гомер юлыңны Аллаһ».

Хан шунда ук боерды Гәрсивазга:
«Шушы юлда инде эш күрсәт безгә,

Ал үзеңә ике йөз кеше юлдаш,
Бар, Сиявуш аягына куй син баш.

Шаһзадәгә тапшыр син сәламемне,
Әйт: солых, дип көйдерәм мин җанымны,

Ташлыйм корал, төшәм аттан, карендәш,
Сиңа игән башыма син орма таш».

Әзерләтте аңа кыйммәт бүләкләр:
Алтын таҗ һәм кылыч, ука күлмәкләр,

Атлар, алтын җиһазы, ауга — этләр,
Алтын чылбыр белән тоткан егетләр,

Алтын, көмеш, келәм, мал бирде йөк-йөк —
Җиде икълим хиражына җитәрлек.

«Риза булмый шаһтан алган өлешкә,
Тур һәм Сәльм юл ачтылар сугышка.

Без риза, диң, нигә безгә яу кыры,
Тыныч яшик, без — туганнар, ахыры?!

Сине язмыш бүген җибәргәч монда,
Солых тусын ул ызгышлар урнында.

Рөстәмне дә димлә, көндер солыхка,
Синең остаз күнәр синең холыкка».

Хәзерләнеп, Гәрсиваз юлга төште.
Шундук Җәйхун ярларына ирешәте.

Көймәләргә төяп халкын, бар малын,
Елга буйлап Бәлхкә тотты юлын.

Шаһзадәгә хәбәр бирде сакчылар:
«Төрекләрдән дәрәҗәле илче бар,

Гаскәр башы — Әфрасияб энесе
Илче булып сиңа килә», янәсе.

Дәшә Рөстәмне Сиявуш киңәшкә:
«Күрик, килгән Туран биге ни эшкә?»

Ул арада Гәрсиваз килеп керде,
Хөрмәт итеп, шаһ тәхетеннән торды.

Гәрсиваз да җир үбә шаһ алдында,
Урын бирә шаһ аңа үз янында.

Исәнлеген, хан саулыгын сораша.
Җавап бирә илче, әдәпкә яраша.

Укый мактау, кыла шаһка догалар,
Тәкъдим итә ханның бүләген аңар,

Рөстәмгә дип җибәргән бүләкләрен —
Алтын, көмеш, ләгыль, якут, гәүһәрен,

Колларына тапшыра бер-бер артын,
Соң укый ул Әфрасиябның хатын.

«Солыхны ул,— диде уйчан Сиявуш,—
Олы максат дибез без дә, сөябез.

Ләкин уйлап үлчик эшнең һәрьягын,
Шуннан инде алырсың хат җавабын.

Ә хәзергә безгә син — кунак. Әйдә,
Берәр атна сүз бирик фәкать мәйгә.

Корыйк мәҗлес, күңелләрне шат итик,
Йөрәкләрне бар гамьнән азат итик».

Һәм башланды мәҗлес, уеннар, сыйлар,
Гәрсивазны олылыйлар, назлыйлар.

Арттырдылар тирә-якта сакларны,
Әзер тоталар һөҗүмгә сафларны.

Диләр: «Булмасын хәйләсе бу ханның,
Булып калмыйк хур, көлкесе җиһанның».

Шаһзадә һәм Рөстәм чыкмый аулактан,
Тикшерделәр бу тәкъдимне һәрьяктан.

Табалмыйча әллә ни хәйлә, мәкер,
Җавабына яздылар мондый фикер:

«Без солыхка һәрчак әзер, ризабыз.
Тик хәзергә шундый бер шарт язабыз:

Ышанганчы ниятегез хаклыкка,
Йөз иң зур бәк бирәсез тотаклыкка.

Шуннан шаһка без хәбәрче салырбыз,
Ул ничек дип боерса, башкарырбыз».

Гәрсиваз да язды үзеннән бер хат:
«Хасыйл булды, күп шөкер,— диде,— максат,

Тик бер шарт та безнең алга куялар:
Хан кардәше йөз бәкне сорый алар.

Төзде Рөстәм аларның исемлеген,
Хатны укып белерсез кем-кемлеген.

Без аларны, диләр, сыйлап тотарбыз,
Шартны сезнең як бозса тик, атарбыз».

Хатлар биреп җибәрде бер кешесен,
Хан, ишетеп, көенде бу эш өчен.

Ничек бирим йөз дустым — йөз терәкне?
Сыйлар өчен алар аңа кирәкме?

Алар хезмәте белән ич патша мин,
Ни эш кырам ул бәкләрдән башка мин?

Бирәм, дисәм, башыма бер бәла бу,
Юк, дисәм, төш?! Илдән, җаннан кулың ю.

Уйлап-уйлап торды да,— тик ни чара? —
Йөз зур бәген бирде шаһка, бичара.

Үзе шундук калган гаскәрен алып,
«Кангга күчәм»,— диеп китте кузгалып.

Ташлап китте барысын: Сәмәркандны,
Бохара, Сугд, Чачны һәм Сәпиҗабны.

Килде Рөстәм, шатланып, Сиявушка:
«Тәбрик итәм, явың китмәде бушка!

Нинди җиңү! Күргән моны кайсы шаһ?
Синең бәхет коткарды, без ялгышсак.

Тиз хәбәр ит сөенечне атаңа,
Хәзер үк яз озын итеп хат аңа.

Җибәр әйдә өенә Гәрсивазны,
Хәзер инде ул куркыталмас безне».

Бирделәр күп бүләк аңа, ханына,
Озаттылар зурлап Туран ягына.

Яздырды хат, чакыртып язучысын,
Хәбәр итеп булган хәлнең барчасын.

Хәбәр белән шаһка җибәрик кемне?
Ышандыра алсын иде ул әтиемне.

«Үзсүзле шул, дуамал бик шаһ Кәвыс,
Үзем барыйм, тагын чыкмасын тавыш.

Күндералмас кеше аны солыхка,
Мин сүз тапсам фәкать андый холыкка»,—

Диде Рөстәм. Риза булды Сиявуш:
«Синең баруың күренә миңа хуш,

Холыксыз карт солыхка, дим, чебенләр,
Тик син аны чыгармассың җебеннән».

Хатны алып, Тәһмәтән юлга төште,
Тиз көннәрдә шаһ Кәвыска иреште.

Каршылый шаһ аны, тәхеттән торып,
Коча, үбә, хәл сорый, күңеле тулып.

Сөйли Рөстәм ни хәл баштан узуын,
Бирә шаһка шаһзадәнең язуын.

Кәвыс шундук ачып укыта хатны.
Ачу гүя сарайга ялкын якты:

«Сугышка ич җибәрдем сезне анда,
Тоз сибәсез нигә сез минем канга?

Беләсез ич һәммәң Әфрасиябны,
Күңелендә аның безгә солыхмы?

Бөкерене турайткан кем? Йөзе акка,
Сабыйлыктан улым төшкән тозакка.

Ә син кайда? Бар дөньяга макталдың,
Шул мәкернең ала алмадың алдын?!

Куптардылар, мин барам, дигәч, тавыш:
Һәммәгез бит, барсын, диде, Сиявуш.

Кайтмады үч! Явызлыкка ач кочак!
Сез куйдыгыз минем муенга пычак.

Бүләк, имеш! Сез хатынмы? Ир кеше!
Ул бит яуда алыр малның өлеше.

Барың, җебеп, яудан, диң, баш тартабыз!
Мин баш тартмыйм! Дөньяда әле бар Кәвыс!

Бүген юллыйм бер ышанычлы кеше,
Өчлап чыга алыр дим ул бу эшне.

Бүләк малын җыеп яндырсын өеп,
Куанмасын дошман, тетрәнсен көеп.

Богау салып алган туранлыларны,
Җәяү монда куып килсен аларны.

Мин аларның монда башын чаптырам,
Солыхларын сүнмәс утка яктырам!

Үзем китәм, гаскәр алып Туранга!
Көн калдырмыйм ул мәкерле еланга».

«Чишмә, шаһым, ачуның бәйле кулын,
Риза булмас моңа иң баштан улың,—

Диде Рөстәм,— акыл белән уйлап бак:
Галәм халкын хөкемеңә бирде Хак,

Начармыни дошман үзе баш исә?
Нинди кылыч иелгән башны кисә?

Улың хаклы. Улында юк һич гаеп.
Әгәр инде Әфрасияб, көчәеп,

Яу күтәрсә, үкенеп бу солыхка,
Син тыныч бул, сабак мин ул халыкка

Укытырга тик үз өстемә алам.
Ил алдында оятка кала балаң,—

Ант бозу ул — иман бозу лабаса,
Нинди иргә, кайчан бу эш яраша?»

Бу сүзләрдән шаһ тагын да ярсый да:
«Син гаепле! Син — сәбәпче барсына! —

Ди батырга.— Малга күзең аларттың!
Сабыемның яшьтән йөзен каралттың!

Кирәкмисең, бар, утыр Забулыңда.
Мин хәл итәм, мин әле патша монда!

Ата сүзеннән баш тарта нинди ул?
Бала түгел, дошман була инде ул.

Бойрык бирәм, хәзер китә анда Тус.
Әгәр баш тартса сугыштан Сиявуш,

Яуга баш — Тус. Сиявушны кайтарып,
Хөкем итәм, сабак алсын бар халык».

Карамый шаһ улына, Рөстәменә,
Сүз әйтергә калмады сылтау менә.

«Хезмәт итсә әгәр артык миннән Тус,
Мин дөньяда кеше булып йөрмәм, дус!» —

Дип, Тәһмәтән, ишекне ябып каты,
Ачуланып сарайдан чыгып чапты.

Шаһ янында калмады хезмәт кулга,
Шул чыгудан китте кайтып Забулга.

Ачулы шаһ, шундук чакыртып Тусны,
Гаскәр белән юлга чыгарга кушты.

Сиявушка яздырды ул озын хат,
Солых өчен аны шелтәләп кат-кат:

«...Уйлый идем, булырсың, дип, арыслан,
Карт көнемдә авыр дәртемә дәрман.

Ә син барып алдандың шул төлкегә,
Калдың Галәм алдында бит көлкегә.

Беләсең ич аның дошманлыкларын,
Ул игә ич бар газап орлыкларын.

Кайчан, кемгә булган дус — иске дошман?
Алырсың йортын, дип бит эче пошкан.

Син алдандың матур кәнизәкләргә,
Вак бүләккә, кирәкмәс бизәкләргә.

Гаскәр белән Тусны җибәрәм менә,
Колак сал син аның киңәшләренә.

Монда озат «Туран кунакларыңны»,
Тырыш, уйла ничек йөз акларыңны:

Батырасың Туранны кара канга,
Йә кайтасың хөкемгә, тормый анда».

Чапкын атта алдан җибәрде хатны,
Сиявушны бу хат утларга якты:

«Йөкләргәме йөз Туран бәге канын,
Ничек бирәм Хакка җавабын аның?

Намуслы ир ничек антын бозала?
Кәвыска ни? Уенчык тик без аңа!

Әгәр кайтсам? Шаһ ачуы! Судабә!
Кайтыр юл юк, аны хәтта сөйләмә.

Судабә бар анда, зәһәрле елан,
Ул еланнан мин ничек җан коткарам?

Башны иеп китсәм Туран ханына,
Халкым каргар, булам илнең хаине».

Ул, сорашып белгәч Рөстәм хәбәрен,
Ул батырның хур ителү хәлләрен,

Уйлап-уйлап килде дә бер карарга,
Ике дустын чакырды ул сарайга,

Зәңги Шауран, Гударз улы Бәһрамны,
Аларга ул сөйләде бар хәбәрне:

«...Шаһка ярыйм, дип түкермәм антыма,
Кан коюны башлап бирмәм халкыма.

Шаһ йөрәге Судабә тозагында,
Кайтмыйм анда аждаһа кочагына.

Юкка чыгам, китеп дөнья читенә,
Котылуга бар бер юлым тик менә.

Дустым булсаң, Зәңги, сиңа бер йомыш
Йөкләр идем, шуны үтәргә тырыш:

Хәзер алып бар халкын каршы якның,
Бар бүләген безгә Әфрасиябның

Илтеп тапшыр исән-сау үз кулына,
Ата гаебен ул такмасын улына.

Минем аңа тагын бар үтенечем.
Бер юл кала качарга, минем өчен.

Рөхсәт итсен Туран аша чыгарга
Миңа, булган янымда юлчыларга.

Бер җаваплы хезмәт, Бәһрам, бар сиңа:
Гаскәр, байрак — син җаваплы барсына.

Күз караңдай барын саклап торасың,
Тулы, исән-сау Туска тапшырасың...»

«Шаһзадә, бу хата уйны куй, димен,
Ачудан тик туган синең уй, димен.

Зинһар, безне янар утларга атма,
Тәхет ташлап, ятим илне елатма.

Ялгышса да, ата бит һаман ата,
Аңлар беркөн: аңарда икән хата.

Хат яз, аңлат, без барыбыз ялварыйк.
Син сугышма, сугышка тик без барыйк,

Без җиңәрбез, әткәң сине кичерер,
Иран синсез ничек соң көн кичерер?» —

Бәһрам, Зәңги киңәш бирде аңарга,
Тик шаһзадә колак салмый аларга:

«Ант, иман бар, ата хөкменнән өстен,
Иман сатып, җиңү табалмый һичкем.

Антлар бозып җиңүгә мин ышанмыйм,
Вәгъдәсез алалмыйм таҗ-тәхет, шан мин.

Янар утка керәм, кайтмыйм Кәвыска,
Шул зинданнан качтым ич бу сугышка.

Теләмисез миңа ярдәм итәргә,
Туры килер үземә алып китәргә.

Ә гаскәрне тапшырам бер Аллага,
Минем кулда башка чара калмады».

Бәһрам, Зәңги, бу сүзләрне ишеткәч,
Агыздылар күзләреннән ачы яшь.

Диләр: «Корбан юлларыңа җаныбыз,
Һичкем түгел, тик син — безнең ханыбыз,

Ымла гына, керербез янар утка,
Икеләнеп тормабыз бер минутка».

«Алай булса,— ди шаһзадә Зәңгигә,—
Оч Туранга, куй аягың өзәңгегә.

Әйт: мин бүген, бозмас өчен антымны,
Дошман итәм хәтта менә атамны,

Кул селтәдем тәхетенә, таҗына,
Ярдәм сорыйм синнән бер мохтаҗыма:

Котылырга шаһ күзеннән, кулыннан,
Кирәк миңа качу Туран юлыннан.

Җир читенә, бер тын илгә качамын,
Кулы җитмәс булсын миңа атамның».

Китерделәр җыеп Туран бәкләрен,
Йөкләделәр ханның бар бүләкләрен

Кәрван итеп барын тезделәр сафка.
Зәңги алды йөз пәһлеванын сакка,

Кузгалдылар. Көнне ялгап кичәгә,
Ашыгалар, ашамый, эчмичә дә.

Якынлашкач, хәбәр иреште ханга:
«Кәрван килде Сиявуштан Туранга!»

Ул арада Зәңги килеп иреште,
Хөрмәт итеп, хан тәхетеннән төште.

Үпте дә җир Әфрасияб алдында
Зәңги, аны хан утыртты янына.

Әфрасияб тыңлый да маҗараны,
Кала утта кабат, куркуда җаны.

Әзерләтте дә сый-табын кунакка,
Үзе Пиранны чакыртты аулакка.

Аның кардәше Пиран — мәшһүр Туранда,
Бар гаскәргә башлык иде ул анда.

Илнең тиңсез, курку белмәс батыры,
Күп һөнәрле, аннан да күп акылы.

Әфрасияб сөйли хәлне Пиранга:
«Бүләк кайтты. Бәкләр сыймый Иранга,

Шаһзадә дә безнең якка күз ата,
Туран аша качарга сүз кузгата.

Рөхсәт итсәм әгәр мин бу балага,
Илне Иран төшерер дим бәлагә.

Син шул хакта нинди киңәш бирәсең?»
«Кунакчыллык — безнең борынгы рәсем.

Сиявушны Галәм мактый таң калып,
Кабул итү кирәк аны, шатланып.

Үткәрмә син, калдыр аны бу илдә,
Якының ит, аңа кызыңны бир дә.

Аны гүзәл, холыклы, дип мактыйлар,
Намусы — пакь, әйткән сүзе — хак, диләр.

Ул бит безнең биргән бәкләрне яклап,
Таҗ-тәхеттән ваз кичкән, намус саклап.

«Хаклык!» — диеп, шаһ әмерен тип, тапта! —
Бар икән шул үзендә батырлык та.

Бер аягы Кәвыснең инде гүрдә.
Үлсә, тәхет кемнеке? Уйлап күр дә,

Тиз үк язып үзенә җавап күндер,
Татлы сүзләр белән аула, сөендер.

Чакыр. Кыз бир. Онытмас изге атың,
Монда калса, булыр кулың-канатың.

Әгәр булса Иран иленә солтан,
Ике илгә, димәк, син ул — ата, хан.

Әйтик, беркөн ата һәм ул яраша,
Яхшылыгың хакы тагын да аша.

Бу хәлләргә син тиеш куанырга,
Хөрмәт күрсәт, бар сыең куй аңарга».

«Синең фикер төпле һәрчак, дәлилле,
Әмма бер уй һаман борчый ла мине:

Бу бит була муенга елан тагу!
Нәрсә була еланда? — Фәкать агу.

Иске дошман — елан, диләр ич картлар.
Бармы елан зәһәрен җуяр шартлар?

Кем үстерсә арысланның баласын,
Көтсен әрнү, үкенечкә каласын».

Диде Пиран: «Синең дошман — атасы.
Сиявушның бармы андый хатасы?

Солых, дидең. Ул, баш тартып җиңүдән,
Солых бирде сиңа ихлас күңелдән,

Ул, ваз кичеп Ватан, ата, тәхеттән,
Бәкләреңне коткарды һәлакәттән.

Без аңардан күрдек фәкать игелек,
Аңа бездән рәхмәт тиеш иң элек».

Ышандырды ханны Пиран киңәше.
Инде калды бер язучыга эше.

Язучысын чакыртып, Сиявушка
Матур итеп бер хат язарга куша:

«Ишеттек хәлне Зәңги Шаураннан:
Солыхыбызга атаң бик ачуланган.

Ул хәбәрдән без дә кайгыга баттык,
Куаныч һәм тынычлыкны югалттык.

Атаң белән бозылышса арагыз,
Безгә кил син, зарыгып көтеп калабыз.

Читтә ни бар? Наз, сөюгә син хаклы,
Бөтен Туран бүген үк синең яклы.

Син, таҗ ташлап, яклап Туран бәкләрен,
Онытылмас иттең изгелекләрең.

Хәзинә, ил, халык — ихтыярыңда,
Илең ит тә яшә иркендә монда.

Әгәр берчак, китәм, дисәң, атаңа,
Мин, мал биреп, сине озатам аңа.

Ачылмастан синең бәхет капкасы,
Минем җан да юк тынычлык табасы.

Кил, син — кунак, син хуҗа бул сарайга,
Без тик шөкерләр укырбыз Ходайга».

Хат язылды. Зәңгине чакыра да
Әфрасияб хатны тапшыра аңа.

Бер минут та вакыт үткәрми бушка,
Илче тиз үк ирешә Сиявушка.

Хатны укып, авыр сулап, Сиявуш
Диде: «Язмыш. Башка юл юк. Илем, хуш.

Дошманнан кем көтә дә бит игелек,
Баш коткарыр юл кирәк шул иң элек».

Утырып ул язды хат атасына:
«Бу — улыңның соң сәлам хаты сиңа.

Белмим, миңа нигә болай каныктың —
Тоташ сынау, бәла, газапка аттың?

Синең сарай тәмуг булды улыңа,
Гел үртәнү, әрнү чыкты юлыма.

Акланыйм, дип, хәтта кердем утка мин,
Котылырга тик тырыштым юкка мин.

Котылыйм, дип, Сугыш аждаһасына
Үзем аттым — ярый алмадым сиңа.

Дошман җиңдем, илгә тынычлык яулап,
Син торасың тагын куркытып-янап.

Зыяныма тырыша гел замана,
Нишләсәм дә ярый алмыймын аңа.

Мине күрсәң, ачуың гына арта,
Син тыныч бул: кайталмыйм сиңа, ата!

Ни бирсә дә язмышым, кайтмыйм өйгә,
Читкә китәм, йөрәгем кәбаб көйгә».

Хаты киткәч, чакыртты ул Бәһрамны:
«Сиңа йөклим, дус, байрак, гаскәр, малны.

Исән саклап тапшыр аларны Туска».
Олыларны ул чакырырга куша,

Болай диеп боерык бирә аларга:
«Мин бүген кич китәмен аргы ярга,

Илче булып килгән ди анда Пиран.
Мин югында сезгә баш була Бәһрам».

Баш иде дә таралыштылар бәкләр.
Сайлады да йөз сугышчы хезмәткәр,

Кирәк кадәр төятә гәүһәр, алтын,
Бай җиһазлы ала йөз гарәп атын,

Алтын зәрле йөз кол-хезмәтче алып,
Кара төндә китә юлга кузгалып.

Үксеп-елап, алар Җәйхунны кичте.
Тиздән Тирмиз шәһәренә иреште.

Халык аның юлына сибә чәчкә.
Юл тоттылар аннан кузгалып Чачкә,

Аннан Кыпчак-ташка табан алды юл,
Ял итмәкче булды бераз анда ул.

Хәбәр барып җитте Әфрасиябка:
«Сиявуш,— дип,— качып чыкты бу якка».

Аңа каршы күндерә хан Пиранны,
Гаскәр, мең бәк озата бара аны.

Сиявушка җибәрә бүләк, маллар:
Алтын, көмеш, атлар, алтын кораллар;

Фирүзәдән гүзәл тәхет ясата,
Дүрт ак филен шаһзадәгә озата;

Юлбарыслы хан байрагын алалар,
Каршыларга кунакны кузгалалар.

Сиявушка якынлашкач та Пиран,
Телгә килде кырда быргы, барабан.

Шат көй, җырлар авазы күккә аша,
Балкый кызыл байраклар тиң кояшка.

Бер-берсенә алар каршы чыктылар,
Берсен-берсе чын күңелдән кочтылар.

Түбәнчелек күрсәтеп бер-беренә,
Күчермичә сүз дөнья хәлләренә,

Сорашалар саулык, юл борчуларын,
Ишетми дә гаскәрнең чыр-чуларын.

Диде Пиран: «Хуш киләсең бу илгә,
Сине күрдем, рәхмәтләр бу тәкъдиргә:

Төштә генә күргәндә дә бу йөзне,
Итәр иде егет шатлыгы безне.

Безнең күңел-җаннар булсын тарагың!
Бездә табылыр бар кирәк-ярагың.

Бу мин — Пиран, ханның гаскәр башлыгы,
Йөз егерме мең гаскәрнең барлыгы,

Унике мең кардәшләрем — бәкләрем,
Әзер үтәргә синең хезмәтләрең».

Ирештеләр бергәләп Кыпчак-ташка.
Чират күчте сәламнән сыйга-ашка.

Җәннәттәй бер бакчага урнаштылар,
Туйганчы бер шунда күңел ачтылар.

Гүзәл бакча, кая күз салсаң да — гөл,
Җире — мөшектәй хуш ис, үлән — сөнбел.

Күргәч тә бу гөлбакчаны Сиявуш,
Батты моңга, ялтырый күзендә яшь.

Искә төште Забулның бакчалары,
Рөстәм... Инде күрәсе юк аларны.

Гөлбакчадай сөекле Ватан — Иран...
Шиңде кинәт гөлдәй ул шул кайгыдан.

Үкенә ул, ник киттем, дип, Ватаннан.
«Ни булды?» — дип сорашып тормый аннан,

Аңлый Пиран, юата шаһзадәне:
«Син — дөньяның иң бәхетле адәме:

Бөеклеккә өч галәмәт синдә бар,
Ул сыйфатлар җирдә тагын кемдә бар?

Беренчесе: син — онык Кәй-Кобадка,
Хаклы варис дөньяда бөек атка.

Бере: телең йөзең кебек сөйкемле,
Тансык хак сүз кол итмәс дисең кемне?

Өченчесе: кем йөзең нурын күрә,
Ихтыярсыз аягыңа баш ора.

Күк — тәхетең, якты кояш — таҗ сиңа!
Бу ике ил ярышып мохтаҗ сиңа.

Кайгырма һич этиең рәнҗетүенә,
Хан — этиең, мин — хезмәтеңдә менә,

Анаң синең ич — Гәрсиваз өеннән,
Син чит түгел, җаным, безнең кавемнән».

«Йөзең көләч, сүзләрең — әбелхәят,
Ди шаһзадә.— Сине күрдем, ниһаять.

Синең даның — дастан телдә, бар илдә,
Сине күрергә ниятем бар иде».

«Ни үкенеч! Шул көндә мин бу хәлдә.
Бу хәлдән бит шатлыклырак әҗәл дә.

Сиңа, кардәш, бар минем үтенечем.
Бу ил — зиндан, гүр кебек минем өчен.

Син сүз бирсәң, дус, таяныч булырга,
Мин чыдармын бу Туранда калырга,

Юкса бүген качам дөнья читенә,
Белгән кеше күз салмасын битемә».

Диде Пиран: «Ку кайгыны җаныңнан,
Булам якын мин сиңа туганыңнан.

Күпме булса милкемдә кол, хәзинә,
Шул бүгеннән тапшырам мин үзеңә.

Ни йомышың төшсә дә, юк, димәмен,
Баламнан бит сине артык сөямен.

Күтәр халык эчендә хөрмәтемне,
Син дә үтә минем бер хаҗәтемне:

Сиңа лаек минем гүзәл кызым бар,
Шуны миннән кәнизәклеккә син ал».

Кайгы бетте. Ага бакчага сыйлар,
Ял иттеләр, егылганчы сәкыйләр.

Кояш җирне чәчәк иткән бер иртә
Болар тагын Кангга сәфәргә китә.

Шат сөйләшеп, тиз ирештеләр Кангга.
Бу ил халкы охшаган арысланга:

Ирләр — батыр. Чәчәктәй — хатын-кызы.
Гүзәл һавалы — кышы, яз, җәй, көзе.

Бөтен җире тоташ гүзәл гөлбакча:
Сайрый былбыл, гөл аңа йөзен ача.

Тирә-ягың гүя Чин потханәсе,
Җәннәт багының җирдәге данәсе.

Көмеш тәнле, фәрештәдәй гүзәлләр
Табакларда алтын-көмеш сузалар.

Җиргә мөшык, хушбуй, ганбәр сибелгән,
Гүя туфрак хушбуйга әйләндерелгән.

Туран ханы каршы килә ерактан.
Аны күреп, Сиявуш төште аттан.

Бер-берсенең муйнына салдылар кул,
Үбешәләр, гүя ата белән ул.

«Фетнә китте, бар Галәмне иттең хуш,
Яуга килеп монда, әй шаһ Сиявуш.

Тур ул берчак кызып чыгарды гауга,
Бар Галәмне батырды сугыш-дауга.

Хаким иде Җиргә — курку, көч, кылыч,
Талган халык, инде йоклар бер тыныч.

Син ул солых бүләк иттең илләргә,
Халык чыккан, рәхмәт, дип баш иярге.

Сине мин дә улым итеп яратам,
Бәйрәм итәм көнең, кайгың таратам».

Шаһзадә дә рәхмәт әйтеп үбә җир:
«Сугыш, солых — Алладан язган тәкъдир».

Алып кереп култыклап сараена,
Утырта хан тәхеткә үз янына.

Шаһзадәнең сокланып нур йөзенә,
Диде: «Кәвыс җәбер иткән үзенә:

Шундый гүзәл, намуслы, батыр бала
Бүләк иткән бу сукыр тәкъдир аңа,

Картлык белән шашкандыр акылдан ул,
Кемдә булган бар җиһанда мондый ул?

Нәрсә көтеп, читкә сине ул ата?
Эх, без булсак синең белән ул-ата?!

Ял ит юлдан күңелең теләгәнчә,
Үз өеңдә, нәкъ үз өеңдәгенчә».

Итә бүләк иң гүзәл бер сараен,
Гөмбәзеннән түбәндер кояш-аең;

Бар хезмәткә әзер кол-кәнизәге,
Йөзе — чини барының, чәче — зәңге.

Ял иткәч тә чакыртты мәҗлескә хан.
Зур сарайга иң зур бәкләрен җыйган,

Өстәл сынар, әзерләнгән мул сыйлар,
Татлы моңлы җыр сызалар җырчылар.

Сиявушны алды хан үз катына,
Тостлар әйтеп, пыялалар тотыла.

Күбәләктәй сәкыйләр оча алда,
Кәвыс, Иран — хәтердән чыкты бар да.

Авыз итеп әргавани шәрабтан,
Күңелләргә керде җан. Тән дә дәрттән

Очар кебек. Дуслык сүзләре кызды,
Бусы мактый, хан кунак итә, кыстый.

Исерделәр. Күзләргә кунган йокы.
Хан сарайга озаттырды кунакны.

Әфрасияб булды кунакка әсир,
Йокы бирми гүзәл сын, көчле тәэсир.

Чакыртты ул хезмәтчесе Шидәне:
«Таңнан ук син зур бәкләрне җый, яме.

Алтын, көмеш, күп итеп әсбаб корал,
Затлы маллар казнадан күпләп бар, ал;

Оялмаслык алсын затлы бүләкләр,—
Боер минем исемнән,— барлык бәкләр

Сиявушка җыелышып барасыз,
Уянганын аның көтеп торасыз.

Күз ачкач та, шатлык кунсын йөзенә,
Ил чит җирдәй күренмәсен күзенә».

Сый-мәҗлестә туктаусыз бәйрәм итеп,
Сиздерми дә китте бер атна үтеп.

Әфрасияб, исенә төшеп кайдан,
Беркөн әйтте: «Уздырсак микән мәйдан?

Теләк булса, сиңа да анда бар эш,
Безнең илнең ирләре белән ярыш.

Сине, диләр, чәүганның пәһлеваны,
Диләр, үзе өйрәткән Рөстәм аны.

Безнеӊ бәкләр дә күз салсын остага,
Башка ярышлар табарбыз без тагы».

«Ханым, без туп, сугарга язмыш оста.
Хан теләге — безгә бойрык. Баш өсте!»

Коршап алды мәйданны халык таңда.
Килде бәкләр, шаһзадә белән хан да.

Халык карый таң калып Сиявушка,
Кояш күреп килалмый тора һушка.

«Минем якта,— ди хан,— Гәрсиваз, Гөлбад,
Җиһан, Пиран, Нәстихән, булсын Пулат.

Синең якта — Һуман, Руин һәм Шидә,
Әрдҗасп, Әндримән — бик оста барсы да».

«Мине оялтма,— ди ханга Сиявуш,—
Каршы торалмыйм мин сиңа, иям баш.

Бу шартымны, ни була, итсәң кабул:
Минем белән син үзең бер якта бул.

Каршы куеп, минем йөзем кызартма,
Хан бар чакта, каршы түгел без — артта».

«Акыл, әдәп һәрвакыт синең сүздә,
Мин уйнамыйм, тик һөнәр күрсәт безгә.

Олы-кече көтә синең уенны,
Тынычлан да уенга бор уеңны».

«Фәрман — ханнан. Башым — туп чәүганыңа,
Тик тагын бер фикер килде аңыма:

Бер як торсын бу Туран бәкләреннән,
Ә мин алыйм ярдәмче гаскәремнән».

«Шулай эшлә, ничек теләсәң,— ди хан,—
Максат — күрү синең уенны, әй җан».

Тураннардан чыкты мәйданга җиде,
Хан аларга уенга тупны чөйде,

Сиявуш та алты егет ала да,
Ташланалар алардан туп аларга:

Гүя арыслан атылды мәйданга,
Гүя кояшны элгән ул чәүганга.

Тузан эченә кереп ул югалды,
Җиңел генә тупны бәкләрдән алды,

Куа тупны ул бер баштан бер башка,
Гүя тубы тими дә җиргә, ташка,

Гүя ул туп ябышкан чәүганына,
Килә алмый бер бәк тә туп янына.

Хан шатланган. Бөтен мәйдан гөр килә.
Егет — йондай җиңел, мәйданда җилә,

Бөтерелә, атыла ул туп кебек,
Һәрчак җитә тупка һәммәдән элек.

Кем бар, кайчан күргән мондый уенны,
Унөч керпе куа гүя куянны.

«Шундый тусын туса адәм анадан,
Җирдә бу — бер, ир исменә яраган,

Күргәнем юк моңа тиң мин җиһанда!» —
Дип сокланып беталмый, карап хан да.

Хан боерды, туктадылар. Сиявуш
Хан алдына килеп тагын иде баш.

«Синең кебек кем уйнаган туп — чәүган,
Чәүганыңа җаным мең булсын корбан.

Һич күрмәгән куаныч бирдең безгә,
Егетлегең тиң икән нурлы йөзгә.

Җәя тарту, ук атуда, ишеттем:
Җирдә сиңа булганы юк, имеш, тиң.

Үтенечем, күңлең авыр алмаса,
Ул һөнәреңне дә итсәк тамаша».

«Баш өсте!» — дип, Сиявуш ала җәя,
Үлчәгәндәй, җәясен кулда чөя.

Җәя җебенә шаһзадә кул орды,
Бер мизгелдә бөгеп, җәясен корды.

«Тукта! — диде, җәягә кул сузды хан,—
Җәяң каты корычтан кебек, туган,

Ялгыз кеше корачак түгел ич бу,
Уйнагандай гына элдең аңа бау».

Җәяне ул ычкындырып керештән,
«Гәрсивазны сыныйк,— диде,— бу эштән».

Гәрсивазга бирде. Ә ул җәяне
Кыса, баса бар көченә, әвәли,

Ярсып-ярсып, гайрәт белән керешә,
Китералмый ул җәяне керешкә.

Мәйдандагы халык — атлы, җәяү дә —
Шаккаталар мондый каты җәягә.

Арып бетте Гәрсиваз, тиргә батты,
Соң җәяне ачудан җиргә атты.

Әфрасияб ул җәяне кулга алды,
Мең газаплар чигеп, көчкә коралды.

«Кора идем яшь чакта каты җәя,
Вакыт үткән инде, көч тә азая.

Иранда да тик Рөстәмгә бу кулдыр.
Ал җәяңне, күрсәт һөнәр, куандыр».

Илтеп куйдылар бер нишан ерак ук.
Егет аны карап торды беравык,

Күтәреп, бер җәясен атып алды.
Уртасына нишанның ук кадалды.

Тагын атты — баштагы укны яра,
Шул ук ояга бусы да кадала.

Борыла да ата ул җилкә аша,
Тагын шул ук ояда ук! Тамаша!

Сигез укны атып кадап бер төпкә,
Баш ия ул, килеп Әфрасиябка.

Мәйдан халкы рәхмәт укый, гөр килә,
Әфрасияб бер уһылдый, бер көлә.

Аннан алар сарайга юл алдылар,
Корып мәҗлес, җамаяк кулга алдылар.

Тостлар әйтеп Сиявуш шәрәфенә,
Сүз бирделәр әргәван шәрабына.

Әзер тора хезмәтеңдә сәкыйлар,
Әргануннан агыла моңсу көйләр.

Дәрт кузгатып назлый җанны җырчылар,
Халык кызды — ишетелә чыр-чулар.

Әфрасияб аулап күңелен батырның,
Табыйм, диеп, Сиявушның хәтерен,

Бирә хилгать, бүләк итә күп маллар,
Хәйран кала бу байлыкны күргәннәр.

Торып рәхмәт укый шаһзадә ханга.
Хан да торып: «Хуш килдең,— ди,— Туранга.

Хак йөзеңне аермасын күземнән,
Мин яраттым сине артык үземнән.

Кайт та ял ит, иртәнауга чыгабыз,
Бирик вакыт тик күңел ачуга без».

Хәзерләнә таңнан юлга аучылар,
Хан йортында күтәрелде шау-шулар.

Этләр — бәйдә, җилкәдә — ау кошлары,
Хан гаскәре, Сиявушның кешеләре,

Шау-гөр килеп, сибелде киң далага.
Киек җанвар гизә, кая карама.

Күзе төшеп еракта бер аһуга[1],
Аның артыннан Сиявуш ат куа.

Таң калдырып бар халыкны (син кара!),
Куып җитеп, ауны элмәккә ала!

Әмма шулчак үләннәр арасыннан
Аның өстенә атыла арыслан.

Яшендәй тиз тартып алып кылычны,
Ул икегә чабып яра ерткычны.

Шаккаттылар туранлылар бу хәлгә,
Ни афәт бу — дошман булса гаскәргә?!

Җитезлеген, батырлыгын мактыйлар:
«Көчеңә тиң шөһрәт җирдә тап!» — диләр.

Сиявуш күп һөнәр күрсәтте ауда,
Күп җәнлекне атты, төшерде бауга.

Бар авын ул гаскәрләргә таратты,
Һөнәрләрен күреп, халык яратты.

Һәммәдән хан артык соклана аңа,
Һәр уңышын күреп, җаннан куана.

[1] *Аһуга* — киеккә.

Аудан кайткач, тагын башланды сыйлар,
Аннан бәкләр һәркөн бәйрәм ясыйлар.

Шаһзадәне, ханны кунакка дәшеп
Күрсәттеләр зур хөрмәт, нәүбәтләшеп.

Онытылды ил, ата, яралары,
Көннән-көнгә хан белән аралары

Якынлаша. Хан онытты бәкләрен,
Кирәксенми аларның хезмәтләрен,

Сиявушны таңнан ала янына,
Тик ул кирәк киңәшенә, ялына.

Беркөн Пиран катты сүз Сиявушка:
«Егет, күрәм, гомерең үтә бушка.

Бу җиһанга гүя килгән бер көнгә,
Дус-иш, яр юк, катнашмыйсың һичкемгә.

Кызыл гөлләр яңагыңнан нур ала,
Атың-саның илдә тиңсез югары.

Атаң, әнә, тора гүр якасында,
Калыр дисең кемгә таҗ-тәхет шунда?

Иран, Туран сиңа бәйле өметен,
Туранда да дус-иш арттыр, егетем.

Туранда да күбәйсен иптәш-кардәш,
Зур нәсәптән үзеңә тап тиң кәләш!

Алла — ялгыз, бар зат яралган парлы,
Сау егеткә ялгыз яшәү зарарлы.

Галәмдә иң гүзәл кызлар — Туранда,
Өч җиткән кыз, гүзәл бар әнә ханда;

Өч гүзәл кыз үстерә Гәрсиваз да,
Шулай ук өч кыз бала үсә бездә.

Иң гүзәле — олы кызым Җәрирә,
Теле татлы, үле тәнгә җан өрә.

Бер кызымны атаган идем сиңа,
Кирәк тапсаң, караваш ит каршыңа.

Кыскасы, тиз тап тиңеңне, сал яучы,
Бөтен Туран сине: «Шаh!» — дип санлаучы.

Кире какмас hичкем үтенечеңне,
Мәхәббәттә балкыт моңлы эчеңне.

Бераз уйлап җавап бирде Сиявуш:
«Синең йортың минем җаныма иң хуш,

Кабул итәм, бир миңа Җәрирәңне,
Мин дә бозмыйм сиңа биргән вәгъдәмне».

Бу сүзләрдән канатлангандай Пиран
Сараена кайтты. «Хатын, бер куан,

Кияү булмакчы үзеңә Сиявуш».
Бу хәбәрдән кыз күңеле булды хуш.

Сузмый эшне, гөрләтеп туй иттеләр,
Кояшны ай кочагына керттеләр.

Калды гүя кайгы, Кәвыс еракта,
Урын алды бәхет, шатлык йөрәктә.

Язмыш инде көләч йөз белән бага,
Һәркөн бәхет — бүләге шаhзадәгә.

Көн артыннан көннәр шулай актылар,
Сиявушны яраталар, мактыйлар...

Уйчан Пиран беркөн килде киңәшкә:
«Минем кызым лаек сиңа кәләшкә.

Тәкъдир сиңа тик башка язмыш язган,
(Казалардан үзе сакласын Яздан).

Туран ханы сөя сине чамасыз,
Киңәшче дә, табындаш та аңа сез.

Алсаң кызын, ныгытып бу дуслыкны,
Булыр илдә синең тамырың ныклы.

Кызы Фәрәнгис — Галәмдә бер матур,
Булмас сигез җәннәттә тиң аңа хур.

Буе — сәрви, күзе — йолдыз, төн — чәче,
Иреннәре әбелхәят дисәңче!

Өйлән, үз бул, син шаһ, хан сараенда,
Колдай булсын һәркем синең яныңда.

«Язмыш, дисең! Тәкъдирдән качкан бармы?
Димәк, күрмим атам йөзен, Иранны.

Дастан, Рөстәм — тәрбиячем, таяныч,
Бәһрам, Зәңги — берсен күрмә, аяныч!

Белгәнең ит, качыр юлларым бармы?
Язмыш бер-бер юллый миңа боларны».

«Ку күңелдән,— ди Пиран,— Иран гамен,
Тәкъдир сөя буенсынган адәмен.

Бүген монда синең сарай, синең таҗ,
Иран түгел, Туран син шаһка мохтаҗ».

Ул шатланып китте хан аулагына,
Кул кушырып, карамый як-ягына.

Бер сүз әйтми тәхет алдында торды.
Бу хәлгә хан гаҗәпләнеп утырды:

«Ни зарың бар? Нигә бу болай тору?
Синең данда мактала безнең ыру!

Гаскәр синдә, хәзинәнең ачкычы,
Мин — бары хан, Туранда — син баш кеше,

Ил, тәхетне син афәттән йоласың,
Теләгеңнән юк баш тартып торасым».

Диде Пиран: «Хәерле эш йомышым.
Угыл кебек якының — Сиявушың

Йомыш белән мине юллады сиңа.
Рәхмәт укый хөрмәтеңә, барсына.

Сыендырды, кайгымны бүлеште, ди,
Иранннан мин күрмәдем бу өлешне, ди.

Өметем бар: угыл итсен үзенә,
Өйләндерсен ягъни мине кызына.

Дуадак мин ялгыз ханның илендә,
Нәсәбем юк, әтием, әнием дә.

Ата булып кушса, ди, Фәрәнгискә,
Мин Иранны төшермәс идем искә».

Бу сүзләрдән ханның төсе бозылды:
«Мин аңардан кызганмыйм,— ди,— кызымны,

Тик беләсең, шундый бер сүз бар илдә:
Башлы кеше елан тыгамы җиңгә?

Өендә кем ерткыч баласы багар,
Үскәч ерткыч, баштан хуҗаны кабар.

Күпме булса мөнәҗҗим Туран, Чинда,
Беләсең ич, әти, мин тугачтин да,

Чакырта да йолдызларны карата,
Нилә булып бетә, дип, бу балага.

Мөнәҗҗимнәр әйтәләр беравыздан:
«Оныкк күреп бер угыл яки кыздан,

Бу тәхетен — илен җилгә очыра,
Гомерен дә шул оныгы үчерә;

Туран халкы кырыла шул баладан.
Котым оча минем шушы бәладән.

Бүген безгә кунак кына Сиявуш,
Йөзен күреп, шуның өчен күңел хуш.

Кунак итеп, түбәмә дә чыгарам.
Ә өйләнсә, беләм мине чагарын.

Юк, бу сүзең авызыңнан җил алсын,
Сараема белеп дошман җыямсың?»

Диде Пиран: «Мәңге шат яшә, ханым,
Минем сүздән әрнү күрмәсен җаның.

Уең — хата Сиявушка карата:
Дошман булыр затны күңел ярата

Аламы соң? Чит, чирканыч була ул.
Күңел сизгер, күңел барын белә ул.

Мөнәҗҗимнәр сине саташтырганнар,
Әйтче, кайчак хак сүз әйталган алар?

Кемгә язмыш хәбәр итсен килерне?
Юлламый Хак бу һөнәргә бер ирне.

Алма, диләр, башка алардан кайгы,
Бар кешегә ни килере — караңгы.

Сиявушка, икеләнеп тә торма,
Бир кызыңны. Минем дә сүзне тыңла.

Бу икедән туган бала Иранга
Шаһ булачак, сиңа тик — кол: син — баба!

Сиңа каршы, синең кулда үссә ул,
Бер ачудан күтәрерме дисең кул?

Язган булса сиңа тәкъдир әзәлдән,
Котылырмын, димсең, качып әҗәлдән?

Дәүләт үзе кергән чакта кулыңа,
Килешми, хан, сүз бирү куркуыңа».

«Синең сүздә һәрчак акыл баш. Аны
Куеп, мин дә эшли алмыйм башканы.

Ул кызымны үзеңнеке дип кара,
Син баш: моңа бир йә тапшыр башкага».

Бу сүзләргә Пиран гаять куанды,
Шаһзадәдән килеп сөенче алды.

Аннан кайтты ашыгып сараена,
Гөлшәһәрне — хатынын дәште янына,

Диде: «Хатын, бер эш тора бит алда —
Кыз яучылап бүген бардым мин ханга,

Сиявушка яучылап Фәрәнгисне,
Бу эшкә хан итте җаваплы безне».

Диде хатын: «Аллам! Син нинди ата?
Үз кызын кем инде утларга ата?»

«Куй,— ди Пиран,— ызгыш, шелтә гәпләрен,
Күрү кирәк кыз озату хәстәрен».

Бу сарайда Гөлшәһәр — хуҗабикә,
Акыллы, эшчән, сүзне сузмыйча күпкә,

Алды ирдән хәзинә ачкычларын,
Актарды мал, кызганмыйча көчләрен.

Хәзерләде кызга хисапсыз бирнә:
Чин ефәге — җитәр мең кат киеменә;

Утыз йөклек алтын-көмеш табаклар,
Кашык, чүмеч, чәшкәләр-чинаяклар;

Төрле келәм — алтмыш төягә йөклек;
Ука чиккән — кияүгә кием күпләп;

Ике таҗ һәм тәхет; урындыклары —
Хисапсыз күп, кызыл алтыннан бары;

Һәммәсендә ләгыль, якут бизәкләр;
Хезмәтенә — ике йөз кәнизәкләр,

Өч йөз көчле хәбәш, рум коллары;
Йөз мең акча — кызга бирнәгә бары.

Икенче көн бар шул малларны алып
Китте кызның сараена, кузгалып.

Аның белән хатын-кыз — кодачалар,
Алар анда уйнап күңел ачалар.

Пиран исә барып ханны алды да,
Кузгалдылар кияү-егет алдына,

Туйга, диеп, күп зур бәкләрне алып.
Сый башланды илдә, гөрли бар халык.

Никях укып, вакыт үткәрми бушка,
Кичен кызны бирделәр Сиявушка.

Җиде көн-төн өйгә кайтмады кеше,
Барысы туйда, ашау да кәеф — эше.

Егет кызны ошатты, кыз — егетне,
Сөешүдә көн артыннан көн үтте.

Ул арада хан әзерли кияүгә
Бүләк, корал, кием кирәкле яуга:

Көтү-көтү сарык, төяләр, атлар,
Хезмәтенә олы бәкләр, солдатлар,

Милек итеп бирә Чинны, Мачинны,
Җиде көнгә боера илгә сыйны.

Башланадыр тагын сый, җыр, тантана,
Бәйрәм итә ил-көн, гөрли, шатлана.

Үтте бер ел шулай бәйрәмдә, сыйда,
Оныттылар гамь-кайгыны барысы да.

Килде ханнан шатлыклы илче беркөн:
«Рөхсәт, кияү карап әйләнсә милкен.

Күңеленә хуш шәһәр чыкса юлыңда,
Хаким булып кала ала ул анда».

Юл ярагы әзерләп үтте айлар.
Телгә килде беркөн табыл, сорнайлар,

Купты шау-шу, кәрван кырга агыла,
Юл алдылар Хутан, Мачин ягына.

Хатын-кызлар — уртада, арбаларда,
Күч күчкәндәй, нидер гөрләшә бар да.

Юлдаш булды гаскәре белән Пиран,
Мәшәкать тә, ул барда, була бәйрәм.

Якынлашкач кәрван Хутанга берчак
(Пиран иде хаким бу илгә һәрчак),

Олы бәкләр чыкты каршы алырга.
Бер ай кунак булды кәрван аларда.

Кич — кунакта, көндез — ауда Сиявуш,
Бер иркенләп итте ялда күңлен хуш.

Тагын сорнай алга, юлга чакырды,
Җыеп, бәйләп төяделәр чатырны.

Тагын Пиран юлдаш булды аларга.
Күчте тормыш утактан арбаларга.

Гизде алар чиксез Чинны, Мачинны,
Каршылый ил хөрмәт белән хакимне.

Бәйрәм кебек бизәлгән юлда илләр,
Гөрли җырлар, күтәренке күңелләр.

Каршы ала бәкләре, олылары.
Җир күтәреп тора алмас сыйлары.

Бер авылга җитте алар берчакны,
Бер як — диңгез, таулар бизи бер якны,

Мыжлый киек урман, тау тирәсендә,
Саф чишмә — һәр куак күләгәсендә.

Бу саф һава, бу гүзәл җир күркендә
Карт та кабат егет булыр бер көндә!

«Менә бу ил,— ди Сиявуш Пиранга,—
Тарта тәнне, рәхәтләр бирә җанга.

Менә шунда бер шәһәр корсам, димен,
Рәхәт, тыныч шул илдә торсам, димен,

Күтәрелсен сарайлар ханга лаек,
Бакча булсын урам, тулсын халаек...»

«Син — ирекле. Әгәр боерсаң миңа,
Үз акчама зур шәһәр салам сиңа.

Миңа нигә акча, вакыт — буш көннәр?
Алар синең хезмәтеңдә үтсеннәр».

«Синең нурлы йөзең күргәннән бирле,
Гүя явыз язмышым миннән бизде.

Минем бөтен байлык синнән ләбаса!
Кунагым бул. Эшемне кыл тамаша».

«Үзем эшлим,— ди Сиявуш Пиранга,—
Ядкәр булып калсын эшем Туранга.

Илгә изге ядкәр калдырсын кеше,
Тик тузан ич аның гомере, гәүдәсе».

Бар иде бер олы тау шул арада,
Тирә-ягы бакча, кая карама,

Ә тау текә, биек — болыттан ашкан,
Аңа баксаң, бүрегең төшә баштан.

Тау өстенә койдырды таштан койма,
Хәтта кошлар очып үталыр димә.

Ике җирдә ике ишек уелган,
Анда авыр корыч капка куелган.

Кереп бикләнсә ун кеше кальгага,
Бирмәс, килсен ун мең батыр алмага.

Капкалардан үтеп кергәч тә адәм,
Хәйран кала: анда — бер олы Галәм:

Анда шәһәр, сарайлар, ташпулатлар,
Урамнары — бакча кебек куаклар;

Түтәл-түтәл һәр якта кергәч үк тә
Ләлә, рәйхан, җәсмин һәрчак чәчәктә;

Һәр тарафта челтер-челтер су ага,
Моны күргән һәр әрнүдән савыга;

Рәхәт җылы җәен-кышын һавасы,
Гөрли татлы, моңлы кошлар авазы.

Күргән әйтер: монда (Фирдәвес багы)
Яман юлга басмас кеше аягы.

Кальгага ул Каңгы диеп бирде ат,
Нәтиҗәсен күреп эшнең, булды шат.

Килеп юлдан Пиран белән тау аша,
Урамнарны алар итте тамаша.

Күреп Пиран шәһәрне калды хәйран:
«Бу гүзәллек килде башыңа кайдан?

Бәхетле син, илһамлы җаның, йөзең,—
Мең яшә дә бар рәхәтен күр үзең».

Бу сүзләрдән Сиявуш бер аһ орды,
Пәрдә кебек булып йөзе агарды.

Диде Пиран: «Кайдан, җаным, бу аһың?
Искә төште тагын нинди гөнаһың?»

Илһамлы бер галим иде шаһзадә,
Кайчак гүя күздән пәрдә төшә дә,

Үткәннәрне, киләчәкне күрә ул,
Вакытларны ярып эчкә керә ул.

Киләчәкне телгә алгач та Пиран,
Ни буласын күреп, ул калды хәйран.

Ачылды аңа киләчәкнең бар эше,
Үз тәкъдире, шәһәр, дәүләт язмышы.

Моңсу, уйчан җавап бирде Пиранга:
«Шундый халәт килә дә минем җанга,

Киләчәкнең бөтен сере ачыла,
Күңел, мескен, аны күреп ачына.

Күр инде син минем кысыр гамәлне:
Шәһәр төздем, уйламый да әҗәлне.

Күктән өскә калыккан манаралар,
Дидем: җиңү миңа бирерләр алар.

Богау икән төздем, «бакча» дип атап!
Тау ныгыттым вөҗданыма — кара тап.

Каза шулай күзен бәйли кешенең,
Уңын-суңын күрми шул ул эшенең.

Гомер юлың җитсен соңгы ноктага,
Син шәһәр төз, йөгер, эшлә, туктама!..»

Уйлый Пиран: сагына бу Иранын,
Шул кузгата өметсезлек буранын.

«Зинһар, җаным, буш хыялга баш орма,
Әрнү белән күңелеңне шаштырма.

Ышанма син, сорыйм, күрәзәлеккә,
Нигезе юк, сызлау сала үзәккә.

Беләсең ич, сине сөйдек барыбыз,
Баласыннан якын күрә ханыбыз.

Минем сиңа, ышан, дәүләтле ханым,
Тиясе юк тузан кадәр зыяным.

Кирәк булса, җаным корбан юлыңа,
Шундый дуслык сиңа дошман буламы?»

«Фәрештә син, тик кеше сурәтендә,
Атам булдың, туганым кара көндә;

Җуя жанның әрнүен татлы сүзең,—
Ди Сиявуш.— Тик тәкъдир?! Уйла үзең:

Язмыштан кем кемне саклап калалган?
Ышан, сүнгән минем йолдыз, каралган.

Сөйлим сиңа, тукта, тыңла чак кына:
Минем башны хан боерып чаптыра.

Килә, минем шәһәремә утыра,
Минем исмемне Туранда бетерә.

Кача алмам бәладән бер карыш та,
Син дә киртә куялмассың язмышка.

Шуннан инде мәхшәр килә Туранга,
Хәбәр барып ирешкәч тә Иранга,

Халкым минем үч алырга ташлана,
Җир күрмәгән дәһшәтле яу башлана.

Кан диңгезе кубачак тамчы каннан,
Бер гөнаһсыз меңнәр үтәр җиһаннан.

Бар эшенә үкенер Туран ханы,
Тик үкенү туктатамыни аны?

Заман үзе кылыч күтәрсә илгә,
Бар байлыгы Туранның оча җилгә.

Ил таланган, шәһәрләр барсы янган,
Дәрья суы тозлы түгелгән каннан».

«Әрне, үртән — буласы эш булачак,
Кем дөньяда бар соң мәңге калачак?

Килдең Җиргә, димәк, беркөн үләсең,
Борчылырга моның өчен нигә соң?

Киләчәк ул кайгылардан, кил, кичик,
Бәйрәм итик, бакчада күңел ачыйк».

Корылды зур табын. Килде җырчылар.
Өстәл биле сыгылырлык мул сыйлар.

Саз авазы йөрәкләргә сала наз,
Бәхетлеләр вакыт үлчәп санамас.

Кызды мәҗлес. Бер атна шулай алар,
Бәйрәм итеп, мәй белән шаяралар.

Шунда ханнан чапкын килде Піранга.
Хан боерган: «Кайтып торма Туранга,

Гаскәр җый да диңгез аша көймәдә
Кирәк булыр Һиндка барып килергә.

Түләмиләр, хираҗ аннан ал җыеп,
Юл уңае Синдка да кер, мал җыеп;

Кылыч белән аула миңа Хәзәрне,
Эшкә кереш, алу белән хәбәрне».

Піран ачты хәзинә сандыкларын.
Җыйды гаскәр. Алды да солдатларын,

Сузмый күпкә, кузгалды ерак юлга.
Җамаягын кабат күтәрде кулга.

Шаһзадә дә зарыкмый ялгызлыктан.
Беркөн иртән купты тузанерактан,

Хан чапкыны китерде хат аңа да:
«...Сагынып,— ди хан,— йөрәкләрем яна ла!

Ташла Чинын, кайт кабат сараема!
Милек моннан ал, бир дәрман җаныма...»

Бу хуш хәбәр, дуслык, чакру авазы
Тәэсир итте. Шаһзадәнең һәвәсе

Кангда түгел инде, шаһ сараенда,
Сафка тезде батырларын барын да,

Төяләргә йөкләтеп бар мал-милкен,
Туранга дип юлга төштеләр беркөн.

Кичкән чакта Хөррәмбаһар даласын,—
Шаяруын шук язмышның кара син —

Яңа бер дәрт биләде шаһзадәне:
«Корам шунда Сиявушгард шәһәре!..»

Туктадылар. Эш башланды. Эш кызды.
Сарай арты күп сарайлар торгызды.

Күтәрелде коймалар, манаралар,
Буе, иңе — ике фәрсәхкә барыр.

Китә алмый шаһзадә ташлап эшен,
Гөлбакчага күмде ул шәһәр эчен.

Салдыра ул сурәтләр диварларга,—
Үткән шаһлар җыелды, гүя бар да

Күрсәтелгән берәр хәл тормышыннан:
Әнә Кәвыс тәхетендә. Пошынган;

Сәламләргә җыелган пәһлеваннар —
Рөстәм һәм Гив, Тус, Нәүзәр һәм Бәһрамнар;

Гүя тере Әфрасияб — тегендә;
Тора Пиран — алдында, хезмәтендә;

Бераз артта — башын чөйгән Гәрсиваз...
Мондый сарай, сурәт кеше ясамас!

Сарай түгел, бу бит — җәннәт бакчасы!
Гөрли гүя, тере гүя барчасы!

Шәһәр даны җәелде бар Галәмгә,
Остасына таң кала һәр адәм дә.

Кайткан чакта Пиран Һинд, Синд иленнән,
Хәбәр алды Сиявуш шәһәреннән.

Шаһзадәне сагынганга чамасыз,
Шул шәһәргә юлын борды чарасыз.

Күрештеләр, кочыштылар, шат алар.
Бу шәһәрне оҗмахка охшаталар.

Диде Пиран: «Җаным юлыңа корбан,
Кем бар җирдә мондый могҗиза корган?

Бу — синдәге белем, илһам җимеше,
Күргән дияр: әфсендер бу, җен эше».

Күрде кызын: Җәрирә йөккә уткән,
Әнисенә кайтырга уйлый икән.

Аны алып, сәламнәр алып ханга
Фәрәнгистән, юнәлде ул Туранга.

Кайтып, ханга сөйләде хәлнең барын:
Һиндта, Синдта сугыш-яу кылганнарын,

Бар хираҗны ничек җыеп алганын,
Юл хәлләрен һәм күреп таң калганын

Сиявушның шәһәр салу һөнәрен:
«Ул сарайлар һушын алмас кемнәрнең?

Җәмшид, Шамшад — аның алдында бала.
Җәннәт бу, дип, күргәннәр хәйран кала.

Ул да, яшим, ди, сагынып ханымны,
Корбан итәм, ди, юлымда җанымны».

Ишеткәнен сөйли хан Гәрсивазга:
«Кирәк булыр хәл белү барып сезгә.

Бакча итте. Шәһәр корды тау-ташта,
Иран дәрте калмады дим ул башта.

Тап күңелен, сораш кирәк-ярагын,
Илт күп бүләк, уйламый юл ярагын,

Хәзинәдән мул йөкләт көмеш, алтын,
Күп итеп ал кол-каравашын, атын,

Төя йөз йөк, ефәк-атласын таслап,
Мул бүләк ал Фәрәнгискә дә хаслап».

Гәрсиваз да эшне салмады артка,
Мең бәк алды, йөкләтеп төя, атка

Бар бүләкне, Хутан юлына төште.
Тиздән барып Сиявушка иреште.

Шаһзадәгә җитте хәбәр бер таңда:
«Ханнан илче иреште,— дип,— Хутанга,

Зур бүләкләр килә Гәрсиваз алып,
Кәрванында меңләп кол, меңләп халык!»

Шат Сиявуш каршы чыкты кунакка.
Берсен-берсе алдылар кочакка:

«Гомер бирсен сиңа Хак мең яшәргә,
Бик шат булдым тагын күрешүләргә.

Юллар авыр, арытмадымы артык?
Хан исәнме? Шул безгә олы шатлык!»

Гәрсиваз да хан сәламен тапшыра,
Бүләкләрне тәкъдим итә барсына.

Хан хилгатен кидерә Сиявушка.
Гүзәл шәһәр рәхәтләр бирә һушка.

Карый алар сарайларны сокланып:
Шәһәр — бакча! Бәйрәм гүя, шат халык!

Көнләшүдән Гәрсиваз калды тынсыз:
«Туранга хан булмакчы бу ватансыз!

Юкса нигә шәһәр төзи бу чүлдә?
Бер елда бит, бары бер ел эчендә!

Тагын бер ел әгәр калса Туранда,
Әфрасиябка калыр тик гүр анда!

Кирәк булыр юлын кисәргә моның,
Исән чакта әле җаның, иманың...»

Ә шаһзадә сизми моның уйларын,
Шат, күрсәтә бар гүзәл сарайларын.

Сый әзерли: «Тансык,— ди,— кунак безгә»,
Куя тәхет янында Гәрсивазга.

Җыр, музыка, бар сарай тулган назга,
Бии кызлар, ярсу дәрт салып сазга;

Күбәләктәй сәкыйләр әйләнәдә,
Гөрли бәкләр шат, кызу әңгәмәдә.

Шаһзадәгә шунда ирешә илче:
«Улың бар! — ди,— шаһым, озат сөенче!

Сау котылды Җәрирәң — тапты малай!
Туптай егет! Гүзәллектә — тулган ай!

Бәйрәм итеп гөрләде бөтен Туран.
Фаруд диеп исем куштырды Пиран.

Манчып кулын зәгъфранга нәнинең,
Сәламе дип сабыйның һәм «әни»нең,

Ак атласка бастырып чапкын атта,
Җибәрделәр үзеңә менә хат та».

Бу хәбәргә әй сөенде Сиявуш,
Чапкын күңлен бүләк биреп итте хуш.

Фәрәнгискә чапты Гәрсиваз белән.
Фәрәнгис тә куанды. Чаң саз белән

Аваз салып, килегез, дип, бар илгә,
Бәйрәм башлый ул да атап бәбигә.

Олы хөрмәт күрсәтә Гәрсивазга:
«Иң кадерле кунак ул — син,— ди,— безгә!»

Атасының исәнлеген сораша.
Гәрсивазда көнчелек хәттин аша.

«Бәхет балкый, хатынның йөзен нурлап,
Туран таҗын болар алмакчы урлап.

Юкса нидән бу кадәр шат балкулар?
Бу сау икән, тәхеткә зур курку бар!

Юкка саный мине, Әфрасиябны,
Гүя өзгән күптән исәп-хисапны».

Кояш чөйгәч тә йөздән төн пәрдәсен,
Нурга күмеп җирен, күген — һәммәсен,

Уен белән шат итим, дип, кунагын,
Иртән таңнан алып тубын-таягын,

Әзерләтте уен кырын Сиявуш.
Кунак торгач: «Булсын,— ди,— күңелләр хуш,

Мәйдан корып, туп-чәүган уйнап алыйк,
Исән көндә күңел ачыйк, куаныйк.

Кичсен вакыт уен, мәйдан эчендә,
Кем бар калган мәңге дәүран эчендә?!»

Ярыш ачып туп сугарга, батырлар,
Атка менеп, киң мәйданга чаптылар.

Башта Гәрсиваз мәйданга туп чөя.
Сиявуш та, гүя киерелгән җәя

Тоткан уктай, шул мәйданга атыла.
Тупны шундук шартаягына элә.

Чукмарының башы гүя тулган ай.
Гүя Галәм үзе аңа чәүган, әй!

Күк көчләре тупны суырып алган күк,
Бер мизгелдә күктә юкка чыга туп.

Ата тупны. Мәйданда оча үзе,
Бөтерелә, иярмәс кеше күзе...

Туктап, алар тәхеттә алды урын.
Гаскәрләре биләде ярыш кырын.

Башлык кунак оялганын онытты.
Гаскәрләре бик тиз үк тупны отты.

Өермәдәй бөтерелә атлылар...
Сөңге чөя... Җәядән ук аттылар.

Гәрсиваз да күршесенә сүзката:
«Нәсәбегез бар Галәмне шаулата,

Алар шанын каплады синең даның,
Күрсәк сөңге сукканың, ук атканың?..»

Хуҗа тагын шундук атланды атка,
Биш кат көбә утырттырды бер якка.

Һәрбересен күтәрәдер тик батыр.
Яшендәй тиз шул якка куды атын.

Ата милке мәшһүр сөңге кулында,
Дан казанган Мазандиран кырында

Филдәй ярсып, гүя очып килә дә,
Шул дәһшәтле сөңге белән көбәгә

Шундый чәнчә: биш кат көбәне тишеп
Үтә сөңге. Шуннан соңгысын ишет:

Биш көбәне сөңгегә элеп атта,
Күтәрә дә баш аша артка ата.

Гәрсивазның ун солдаты бергәләп
Күтәрмәкче көбәләрне. Бәргәләп

Мәш килделәр, кузгаталмый урыннан.
Ә Сиявуш чыкканы юк уеннан,—

Ул мәйданга куйдыра дүрт кат калкан,
Ике корыч җәүшан өстәтә арттан.

Билендә — алты, өч ук — кулда. Калка да,
Төзәп тормый, иярennән ата да,

Һәр ук тишә алты корыч калканны.
Шаккатып ил мактады пәһлеванны.

Килеп тәхеткә утырды Сиявуш.
Иртән иде Гәрсивазның күңеле хуш.

Көнләшүдән инде йөрәге янды,
Күңелендә ярсу ачу уянды...

«Нәүбәт килде,— диде,— безгә ярышка:
Көч сынашыйк иярдән аударышка.

Бу көрәштә миңа тиң юк Туранда,
Син дә оста, дан казандың Иранда.

Көч сынашыйк, әйдә, чыгып мәйданга.
Аттан егып, ирешалсам мин данга,

Ил алдында миңа син баш иясең.
Аусам, үземне юк «батыр» диясем».

«Юк, сөйрәшмик, оят бу,— ди Сиявуш,—
Бергә үткән көннәр булсын җанга хуш.

Затың олы, көрәшкә намуссынам,
Атым, үзем көрәшсез үк буйсынам,

Куй мәйданга иң макталган батырың,
Аның белән бераз ат уйнатырмын».

«Әй пәһлеван,— диде аңа Гәрсиваз,—
Ярышуда оялырлык нәрсә аз.

Билбаулардан элеп, сөйрәп иярдән,
Көч сынашу, көрәш калган кемнәрдән».

«Юк. Хәвеф бар,— ди Сиявуш җавапта,—
Ярыш — сугыш. Син дә мин — каршы якта.

Кызу. Ярсу. Ачу алар артында...
Син — хан улы, калсаң аяк астында?..

Баш өсте, дим, бар әмереңә баш иям,
Тик көрәшмик, дуслыкны бозмыйк, иям.

Күрим дисәң бу көрәштә сылымны,
Бер батырың каршы бастырмыйсыңмы?!»

«Юк, баш тартмыйм мин көрәштән, куй, батыр,
Мин түгел ул аяк астында ятыр!» —

Гаскәргә җар салды шунда Гәрсиваз,
Тынлык — җавап, һичкем чыгармый аваз.

Кем ашкынып торсын мондый ярышка,
Оят, хурлык кына калса табышка?!

Озак тынлык. Ниһаять, бер батыры
(Исеме Горуй-Зирих, ул — Пишәң улы)

Аваз бирде: «Башкалар тартсалар баш,
Үзем чыгам, минем йөрәк какшамас.

Аны күреп, Сиявуш кашын чытты.
«Турсайма, дус: безнең зур батыр чыкты»,—

Ди Гәрсиваз. Сиявуш ди җавапта:
«Синнән башка юк тиңем сезнең якта,

Һич югында, икәү торсыннар каршы,
Җиңүемә ышаныр иде барсы...»

Чакырдылар. Ярдәмгә Тимер алып
Чыкты. Халык карый аңа таң калып.

Котың алыр: манарадай буй-бәдән,
Булыр икән филдәй гәүдәле адәм!

Алар икәү ташланды Сиявушка,
Шаһзадә да вакыт үткәрми бушка,

Башта җилдәй Горуй алдына чыга,
Билбавыннан элә дә җиргә ега.

Яшендәй тиз соң борыла Тимергә,
Тимер өлгерми аңына килергә.

Корычтай кул иңсәдән кысып ала,
Аны ханы алдына китереп сала.

Гүя элгән кыскычына зур кошны,
Бөтен мәйдан гөрләп аны алкышлый.

Кара көйсә дә, чыгармый чырайга
Гәрсиваз... Соң алар кайтты сарайга.

Җиде көн-төн тукталмый бәйрәм-сыйлар,
Уенчылар җыр-биюдә ярсыйлар.

Сый, бүләкле бәйрәмнәр үтә-китә,
Гәрсивазның китәр көннәре җитә.

Шаһзадә хат яза Әфрасиябка,
Ант яңарту, рәхмәт тула бу хатка.

Күп бүләкләр әзерләп ханга сала,
Тантанада гаскәр юлга кузгала.

Юл буенча сафлар, сокланып шактый,
Кунак иткән шаһны, шәһәрен мактый.

Ачу ярсый Гәрсиваз күңелендә:
«Килмешәктән оят күр үз җирендә!

Илнең асыл батырларын, чын ирне,
Исемнәре данлы Горуй, Тимерне

Хур итте бит! Ни күрсәтмәс ул тагын,
Чик куймасаң, туздырмасаң утагын?!»

Узып булмый ачу, ярсуын җанның...
Кайтып житте утагына ул ханның.

Бүләкләрне, шаһзадә хатын бирде.
Хатны укып, Әфрасияб сөенде.

Бу куаныч Гәрсиваз күңелен телә.
«Кая чара? Табасы нәрсә генә?!»

Төне буе ник бер йомылсын күзе,
Төнне ертып күренүгә көн йөзе,

Күтәрелеп, сарайга ул алды юл,
Бер карарга килгән: ханны алдый ул.

Хан алдына үткәргәч аны сакчы:
«Юк, каласым килми булып алдакчы,—

Дип сүз башлый.— Сөйлим Сиявуш хәлен,
Тик ятмаган — тапкан егет әмәлен.

Бел: Ираннан йөри хәбәрчеләр дә,
Илче салган Румга, Чин-Мачиннарга.

Инде шактый гаскәр җыйган үзенә,
Игътибар ит, колак салсаң сүземә,

Искә төшер Ирәҗ-Тур маҗарасын!
Юк итмәссез ут белән су арасын,

Гасырлардан килгән дошманлык, шомны,
Ата-бала үпкәсен басасыңмы?!

Кем соң кайчан җилне тышаулый алган?
Үзлеге — үч аның, дуслыгы — ялган!»

Гәрсивазның сүзләре салды утка,
Җуйды, тыныч тапмый хан бер минутка.

Дөрес, башта җавап — ханнарча аның:
«Мондый хәлдә ашыгу — гөнаһ, җаным.

Бер-ике көн уйлыйм моның һәрьягын,
Шуннан соң тик ишетерсең җавабым...»

Өч көннән соң, сугыш киемен киеп,
Коралланып Гәрсиваз җитте килеп.

Хан да, аны утыртып үз янына,
Бора гәпне шул мәсьәлә ягына:

«Терәк булыр бер кешем юк туганнан,
Сиңа ышанам, син дә мин — без бер каннан.

Ә Сиявуш — җиде ят шул! Нитәсең?!
Җиде яттан нәрсә өмет итәсең?!

Баштук, күреп куркыныч төш, кот очты,
Читләтергә тырыштым куркынычны.

Тәкъдим иттем аңа дуслык, туганлык,
Тәхет бирдек, кыз, олылап сыйладык.

Сугышмыйм, дип, ул да тәхетен ташлый,
Намус, әдәп күрсәтә — көчле, башлы...

Ни боерсам, чыкмады бит сүземнән,
Курку бетте. Мин канәгать үзеннән.

Кызым бирдем, улым-киявем иттем,
Туганлашып, бу дуслыкны беркеттем.

Кызга өстәп олыс бирдем, хәзинә...
Дошман итеп карый алмыйм үзенә.

Сылтау тапмыйм аның белән сугышка,
Нәрсә дияр Галәм халкы ул эшкә?

Хак каршында, илдә моңа юк хакым.
Иран нишләр, күрсә шундый гөнаһым?

Кул сузсам бу арыслан баласына,
Тарымам, димсең, баш китәр бәласенә?!

Тик бер юлны белә, күрә күңелем хуш:
Атасына кайтып китсен Сиявуш.

Тәхетме аны көтә анда, богаумы?
Тик безнең ил күрмәс булсын зур яуны!!!»

«Килешалмыйм,— диде аңа Гәрсиваз,—
Сиявушны озатуның табышы аз,

Ә баласе башны, илне җуярлык,
Кирәк монда төптән уйлау, уяулык.

Дошман ул, дип, аны моннан озатсаң,
Дошманлыкка анда аңа эш асан.

Син бит аны кардәш иттең, үз иттең,
Эч сереңне — кимчелегең белгерттең.

Дошман якка илдән җил дә чыгарма,
Дигән сүз бар. Уйла. Кирәк чыдарга.

Шул шул, үстерсәң өеңдә юлбарыс,
Беркөн аңа җим буласың — шул бар эш».

«Синең сүздә дә хаклык бар, туганым,
Шуңа да бит катты баш, талды җаным.

Үкенсәм дә бүген үткән эшләргә,
Соң шул инде, терсәк җитми тешләргә.

Бер юл күрмим фетнәдән котылырга,
Кала, Хакка тапшырып, тик торырга.

Юк, ашыкмыйк, көтү мөмкин булганда,
Вакыт үзе юл күрсәтер бер алда.

Көтик, күрик: вакыт елмаер кемгә?
Буйсынмый шул тәкъдир безнең хөкемгә.

Яхшысы шул: чакыртамын да монда,
Үзем күрәм ни бар аның уенда?

Явыз уе барын белсәм, ишетсәм,
Кем гаепләр, ачу белән эш итсәм?!

Явызлыкка усаллык тышау таба!
Бу эштә дә юл тотам шунда таба».

Тик ниятен Гәрсиваз шундук бозды:
«Чакырдың ди. Килер, димсең, ялгызы?

Син чакырсаң... Гаскәр белән ябырылса?
Әзерләнә, шуңа омтыла ласа!

Әйтеп торам, Сиявуш инде — башка,
Хәзер аны санама син юашка.

Танымассың хәтта Фәрәнгисеңне,
Шаһ килене! Хурлый безнең ишене!..

Шаһ кәләше! Җир күрке! Олы күктән!
Фәрәнгис тә (безнең кан!) инде — бүтән.

Күреп шундый «гүзәл йөзле» хуҗаны —
«Тирән акыл иясен!» «Изге җанны!»

Гаскәрләрең алар ягына шуса?
Кемдә чукмар, көтү буйсына шуңа.

Көтүе юк көтүчегә калырсың,
Сизмәссең дә тәхетеңне аласын.

Ул кешене, ым кактыңмы шул чакта,
Ташланыр дип уйлыйсыңмы кочакка?!

Кайчан соң булган арыслан дус филгә?
Ут белән су кайчан сыешкан бергә?..»

Гәрсиваз тик шундый сүзләрне тезә,
Шым дөрләтә, ханның өметен өзә.

Хан да инде тик шундый «киңәш» көтә,
Шундый сүздән тик җан өрә, җилкетә.

Шулай да ул (имеш, сабыр, тыныч, нык)
Җитди эштә күрсәтми ашыгычлык.

«Сабыр төбеннән алмакчы сары алтын»
(Тик җилбәзәк белми чама, сәгатен).

«Әфрасияб алмас җилбәзәк атын...»
Шулай чыдый, ашыктырмый максатын.

Ә күңелдә — тәмуг, дошманлык уты.
Шул максатка буйсынган һәр минуты.

Ә Гәрсиваз һәркөн май сибә тора,
Хан ярсуын шашар хәлгә арттыра.

Котыртудан туды көткән нәтиҗә:
Хан чакыртты Гәрсивазны бер кичә,

Куып җибәрде сарайдан бар бәкне:
«Шул, хәзер,— ди,— оч! Китер ул имгәкне!»

Язып шундук кулга тоттырды хат та:
«Син, газизем, оныттың безнең хакта.

Сагындык бик. Хатны алуга, юлга төш,
Кызым белән минем сарайга җитеш.

Безнең күңел — нурлы йөзеңә сусау.
Бу якта да тау-далада тулы ау,

Мул сарайда сөт, бал, май да, шәраб та.
Үз шәһәреңне сагынган сәгатьтә,

Кем тоткарлар? Комачау булмас бер дә,
Син каршымы мәҗлес корырга бергә?

Көн-төн — эштә. Кирәктер ял да таңда.
Ял итәрсең. Юаныр каенатаң да».

Шат Гәрсиваз хатны алып кулына,
Гаскәр белән чыкты фетнә юлына.

Күңелендә ачу, мәкер кыздырып,
Максатына очты, җилдән уздырып.

Сиявушка илче юллый ул, хат та:
«Каршылыйм, дип, зинһар, салма оятка.

Олылыгың, синең башкарган эшләр
Алдында соң кем генә минем ишләр.

Син бит — патша! Син бит — бөек шаһ улы!
Килештерми даның юк-бар шашуны.

Тәкәллефең[1] телә минем күңелне.—
Мине оялтмау сиңа җиңел түгелме?!

Мин килә, дип, тәхетеңнән торма син,
Бер мәртәбә булсын сүзем тыңла син...»

Хатны алып, Сиявуш калды хәйран:
«Болар нигә? Максат ни? Тапкан кайдан?..»

Шәһәргә кергәч кунак, чыкты каршы,
Тәбрикләшә, канәгать тыштан барсы.

Хуҗа сорый хан саулыгын, юл хәлен,
Гаилә, ил, сарай, дөнья хәбәрен.

Гәрсиваз да, үтәп йола-гадәтне,
Тапшыра хан сүзләрен, бирә хатны.

Хатны шундук алып ачып укый да:
«Хан юлына без,— ди,— корбан, җан фида!

---

[1] *Тәкәллефең* — ясалмалыгың, кылануың.

Синең белән өзәңгегә өзәңге,
Мин дә моннан суытырмын эзләрне».

Күңел уктай очты Әфрасиябка.
Әмма хуҗа бурычлы бит кунакка,

«Сезгә тиеш бу юлдан ял ике-өч көн.
Иркегездә — сарай, бакчам, бар милкем.

Мәҗлес корып, өч көн бәйрәм итәбез
Һәм, мин — әзер, өч көннән соң китәбез».

Бу җавапка куанмый Гәрсивазы,
Гүя җавап мәкере җепләрен өзде.

Бу пакь намус барса Әфрасиябка,
Тик Гәрсиваз калачак бит оятка.

Ачылачак моның бар ялганнары,
Кертелерсеңме сарайга аннары?

Моңарга да кирәк хәйлә табарга,
Бу да тиеш эләгемә кабарга...

Торды озак текәлеп Сиявушка,
Эчтән үкси, күзләре тулды яшькә.

Сиявуш та тетрәнде, моны күреп:
«Җаным, сөйлә: ни бар? Үксеп, үкереп,

Тик яшь чыга. Булыйм юлыңа корбан,
Ялгыз итмәм. Сине үксеткән кем бар?

Батыр яшен, беләм, тик яла сыга,
Оныт кайгың, мин дошман-ялачыга,

Ул мәкергә үзем мин булам калкан.
Кыерсытса хәтта хан, каушап калмам.

Киттек. Барам синең белән ул якка,
Сүз катармын хәтта Әфрасиябка.

Нигә саксыз кагыла намусыңа,
Син хезмәттә, хурлык лаекмы сиңа?

Юк, кактырмам, булам мин синең яклы,
Яхшы беләм ич мин Әфрасиябны:

Ачуланса, җуя үлчәм чамасын,
Рәнҗеталыр хәтта газиз анасын.

Беләм, үзе үкенә, ачу үткәч...
Гафу итәр, хәлнең чынын ишеткәч.

Әгәр кемдер сине каралткан булса,
Ул — дошманым, хәтта ки атам булса.

Тик исмен әйт, синең белән бергә без
Ул фетнәдән дә котыла beләрбез,

Бар фикерем, акыл көчем җигәрмен,
Мәкер, яла тылсымнарын җиңәрмен...»

«Пәһлеван,— ди Гәрсиваз җавабында,—
Хан да какмый, юк илдә дошманым да.

Миннән көчле, миннән данлы кем анда?!
Синең кайгың — бер әрнү минем җанда.

Ирәҗ хәле яхшы таныштыр сиңа.
Туктый белми Тур башлаган фаҗига.

Иран-Туран — берсе су булса, берсе — ут,
Ике арада дуслык гомере — бер минут.

Иран шаһы — Әфрасиябка дошман.
Әфрасиябта Турдан да кайнар кан.

Әле явызлык бәйләүдә — йокыда.
Уянсамы?! Ни күрербез, йа Хода!

Агриресны искә төшер: туганы
Бер гөнаһсыз үтерттерде бит аны!

Күпме башны үз кулы белән чапты!
Ни эшләмәс чылбырсызланган чакны?

Син килгәннән бирле янам мин утта,
Нишләрбез, дим, фетнә уянган минутта?

Тик куаныч, хезмәтең бирдең илгә,
Бер эшең юк, шом салырлык күңелгә.

Шайтан исә вәсвәсәләгән ханны
Сиңа каршы, кыям, ди, синең җанны.

Әйтмәде, дип, үпкәләмәссең, дидем,
Сер сакларга чамам җитмәде минем...»

Җиңде Сиявуш әрнү, моң, сагышны,
Карар катгый: югары чөйде башны.

«Борчылма,— ди.— Минем якта Алла бар.
Акыллы хан ялгангамы алданар?

Ул бит мине якын итте үзенә:
Олыс бирде. Өйләндерде кызына.

Хәзер китәм синең белән янына,
Хакыйкатьне җәеп салам алдына.

Хаклык барда, ялганның теле кыска,
Ышанам мин, явызлык калыр аска.

Нигә соң хан минем бәхетем каралтсын:
Гаебем юк, намусым пакь, карар чын...»

«Әй беркатлым! — ди Гәрсиваз.— Саф җанлы!
Хәзер күрсәң, танымас идең ханны.

Өметең өз аның аңын ачудан,
Язмыш хөкеме, ул котырган ачудан.

Үгет сөйләп, арыслан тырнагында
Кем хак даулар, башта акыл барында?

Аңыңа кил: элек күрдем, дип, хөрмәт,
Кулың белән муеныңа салма элмәк.

Назлап сине, бүләкләп зурлаганда,
Дуслык кына булгандыр димсең җанда?

Агрирес аңа синнән якын ла! —
Башын чапты, уйла шуның хакында.

Нишләтәсең? Холкы шундый шул ханның:
Хакны сукмый санга, сүзен туганның...

Ачы тәҗрибәм, акылым киңәшен
Шундый хәлдә килде сиңа бирәсем.

Чынын әйттем. Инде үзеңә кара.
Йортың ташлап, хаклык, диеп, бичара,

Шәһәр арты Туранга шәһәр салдың...
Нәрсә таптың? Хан каһәренә тардың».

Шулай дип, ул күзеннән түкте яшен,
Йөрәк түрендә дөрләтеп хәйләсен,

Күзендә яшь, Сиявуш калды хәйран:
Тагын бәла! Ярдәм көтәргә кайдан?

Шундый яшьли, хәят атканда чәчәк,
Гомереңне киссә явыз күрәчәк?

Йөрәк әрни. Кайгыдан йөз каралды.
Сүнде бар дәрт. Башын түбәнгә салды.

«Белмим, нишләп хан ачуын кузгаттым?
Сүз әйтмәдем. Яхшылыкка күз аттым.

Гел яхшылык итте ул да миңа да,
Шуңар җаным әрни, күңел моңая.

Ярый. Ишсен бар ачуын өстемә,
Күтәрермен карышмыйча берсенә.

Гаскәр алмыйм, хәзер алдына барам.
Гаебемне аңласам, китәр ярам».

«Әй пәһлеван,— ди Гәрсиваз,— сүземә
Бер колак сал: тапшыр эшне үземә.

Кем соң, кызып, үз-үзен ата утка,
Колак салмый ярдәмгә әзер дуска?

Син сабыр ит. Кабат мин аңа барыйм,
Үгет белән үчен үчереп карыйм.

Уңып юлым, салалсам үзен эзгә,
Кичекмәстән хәбәр итәрмен сезгә.

Өметем зур Хакның мәрхәмәтенә,
Кодрәт белән салса кеше рәтенә.

Корбанлыктай мәнсез торма тик син дә:
Моннан түгел ерак — Иран, Рум, Чин дә.

Иран — илең. Баш тартырмы Чин синнән?
Илчеләр сал, хәбәр ал һәрберсеннән.

Әгәр дә мин хан ачуын басмасам,
Хәбәр килер. Мөшкел хәлләр — качмасаң.

Көтеп торма килеп башың чапканны.
Озатканда кире минем чапкынны,

Син шәһәрнең чык икенче ягыннан
Юлга, качып һәлакәт тырнагыннан».

Хуш килгәндәй бу үгет Сиявушка,
Тора нәүмиз тыңлап, килалмый һушка.

Риза була: «Нишлим? Чыкмыйм сүзеңнән.
Киңәш көтәм, хәбәр көтәм үзеңнән.

Көен табып, ханны салалсаң эзгә,
Гомер буе бурычлы булам сезгә».

Чакыртты бер язучысын. «Яз,— ди,— хат!»
Язды башта Тәңрегә мактау кат-кат.

Соң мактады — акыл, үлчәмлелекне.
Ханны зурлый, илен, Туран, милекне.

«Мәңге хан бул, хаксызлыкны чит итеп,
Гадел хикмәт ияләрен иш итеп.

Онытасым юк иткән игелекләрең,
Синнән — минем тормыш, көн, милекләрем.

Менә тагын чакыргансың кунакка,
Тик әлегә баралмыйбыз ул якка:

Авыр йөктән Фәрәнгис бик кыйнала.
Аштан калды, ярдәмләшәм мин аңа.

Көн-төн дими утырам баш очында,
Китсәм, җуям — аны да, тынычым да.

Күңел кошым сезнең якларга оча,
Баралмабыз, Фәрәнгис котылмыйча.

Ул терелгәч исән котылып йөктән,
Кузгалырбыз, мин юлга әзер күптән».

Мөһерләнеп, Гәрсивазга күчте хат.
Ала Гәрсиваз алмаш өч очкын ат.

Көн-төн дими алмаштырып аларны,
Өч тәүлектә үтә ерак араны.

Уйда — мәкер, телдә — әвәләп ялган,
Ханга җитте. Гүя ут капкан, янган.

Хан шаккатты: «Янгын бармы, шашасың?
Тиз әйләндең, очтыңмы илләр аша син?!»

Җавап бирде: «Белсәң әгәр чын хәлне,
Үзең миннән артык кызарсың әле.

Хур иттеләр илчеңне ил алдында,
Каршы чыкмый! Хатын кулга алмый да!

Бусагадан уздырмады үземне,
Әйттермәде, тыңламады сүзеңне.

Иранлылар тәхет тирәсен сырган,
Туранлыны куган, качырган, сөргән.

Корал чыңы анда, гаскәр шау-шуы.
Чин, Румнан ага гаскәр ташуы.

Туздырмасаң тиз бу шөпшә оясын,
Илне үлем якасына куярсың.

Һәм Иран да карап тормас лабаса?!
Укмашсын тик, алар Туранны баса.

Шул көчләргә ничек каршы торасың!
«Үлмим! Котылыйм!» — дисәң, ашыгырсың...»

Әфрасияб хәбәрдән шартлый язды.
Зур хыянәт иске дауны кабызды.

Турдан туган ачуга ут тоташты,
Хан тетрәнде. Ярсуы хәттин ашты.

Энесенә җавап кайтарып тормый,
Бирде әмер — гөрли барабан. Быргы

Гаскәрләрне ашыгыч яуга даулый.
Купты мәхшәр, гөр килә шәһәр, шаулый.

Чәчәкле Канг гүя далага акты.
Купты тузан. Күренмәс булды якты...

Гәрсивазны озатып, Сиявуш та
Шактый заман килалмый торды һушка.

Күреп сорый хатыны серне ачуын:
«Үпкәңме бу? Кайдан борчу-ачуың?..»

«Якты йөзлем,— ди Сиявуш аңарга,—
Инде дошман Сиявуш Тураннарга.

Гаебем юк, ник ярсыйлар? Шаккатам,
Хәлемне бер саташуга охшатам.

Күрәм, җитте соңына гомерем юлы,
Мин — йоклаучы, бәйләүле аяк, кулы...»

Бу юраудан сискәнде Фәрәнгис тә,
Һушы китте. Һич килә алмый искә.

Чәче тузды. Иренен чәйнәп канатты,
Күзләреннән яшь урынына кан акты.

«Атаң Кәвыс үчле, сиңа каныккан,
Илең — Иран диялмыйм. Мин дә куркам.

Рум — ерак. Чин да булмас таяныч.
Кайда чара? Ник хәл болай аяныч?!»

«Безгә,— ди ир,— бер теләктәш — Гәрсиваз,
Сабыр итик, ышанычым гәрчә аз.

Өметем шул: яклап, аңлатып чынын,
Бәлки, басалыр ул ханның ачуын...»

Чара күрми сүнмәс утта яндылар.
Өч көн, өч төн йокысыз уфтандылар.

Дүртенче төн арудан йокы басты.
Төн берендә Сиявуш гүя шашты,—

Коты очып, тузынып һәм илереп
Ыргып торды котырынган фил кебек.

Юатмакчы, гүзәле алды кочакка.
Сарай купты. Ут алдылар. Учакка

Ягып алой белән гамбәр, бүлмәне
Төтәттеләр хуш ис белән. Бу мәлне

Хатын ирен юата, назлы кочып:
«Нинди төштән уяндың котың очып?..»

«Сөйлим. Ләкин белмәсеннәр, сер сакла.
Төштә күрдем ташкын елга. Берчакны

Яр буена куркыныч яу агыла.
Дәһшәтле ут ыргый минем ягыма,

Куркып качам. Калмый ут минем арттан,
Үсә бара, урый ул төрле яктан.

Утта калып, көл булды шушы калам.
Мин елгага ташланам, батам, янам.

Әфрасияб явы миңа карый да
Утка әйләнә елга, су, яры да...»

«Хан, күрәсең, карыша Гәрсивазга...
Ят, тынычлан, йом да күзең беразга.

Уйлау, юрау калып торсын яктыга,
Кирәк, диләр, юрау төшне яхшыга...»

Көчәйттерде сарайның сакчыларын.
Бар тарафка юллады шымчыларын...

Тиздән кайтты күзәтче Канг ягыннан,
Шашкан, киткән төсе — коты алынган:

«Зур яу! Басып килә илнең бар ягын!
Әфрасияб! Күтәргән яу байрагын...»

Килде хәбәр-киңәш Гәрсиваздан да:
«Хан тузына, ярсый юктан, аздан да.

Сиңа аны очратмавың яхшырак,
Ал гаскәрең, кит, юлыннан бул ерак.

Очрашырсыз, аңлашырсыз, ул тынгач,
Ачу сүнеп, акылына утыргач...»

Хыялга да китерми алдашканын,
Борчылудан тетрәү ала шаһ җанын.

Моны күргән Фәрәнгис юатмакчы:
«Дөрес киңәш. Китеп торганың яхшы.

Тулпар атың юлга чыккан минуттан,
Коткарасың мине дә борчу-уттан...»

«Әй җаным,— ди Сиявуш җавабында,—
Соңгы мизгелләр бу синең яныңда.

Мин бетердем эчеп гомерем зәһәрен,
Төшем растка чыкты: беләм, үләмен.

Яшәү сытты, булып авыр йөк миңа,
Гүрдән башка сыеныр урын юк миңа.

Үтсен гомер вәхшиләр тырнагында,
Бәхет кошы Хомай торсын яныңда.

Азагы — бер: җим буласы әҗәлгә
Шулай үлем сулыштай үз адәмгә.

Синең буйда алты айлык йөгең бар.
Бер зарым тик: шуны югалтма, зинһар.

Миңа насыйп түгел күрү Иранны,
Хан ачуы ятим итә баламны.

Гүр, кәфен юк миңа хәтта Туранда —
Башсыз гәүдәм аунап калыр тузанда.

Чабылган баш тәгәрәп калыр җирдә.
Кызганучым, догачым булмас бер дә.

Хан яулары сиңа да кул саларлар.
Пиран сине һәлакәттән аралар.

Сине йолып алыр ул үз йортына.
Ни тузынган явызлык та бер тына.

Бер ир бала китерерсең дөньяга,
Кәй-Хөсрәү дип исем куярсың аңа,—

Минем нәслемнең йөз агы булачак,
Иранның ул данлы шаһы булачак.

Коткаручы сезне килер Ираннан,
Минем илгә алып китәр Пираннан.

Шаһ тәхете күчәр Хөсрәү кулына.
Гаскәр җыеп басар ул яу юлына.

Бу тәкъдирне кем соң үзгәртә алган?!
Басар җирне диңгез кебек тагын кан,

Туган җирең таптар Рәхеш тоягы,
Иңнәрендә уйнар Рөстәм таягы.

Минем каным?.. Кан үче, дип, ираннар,
Туктый белми, Туран канын коярлар...»

Өзгәләнеп Фәрәнгисе бу фалга,
Илерә-үкси авып төште дә алга,

Чәчен йолкый. Тырнап йөзен канатты,
Яше түгел, күздән гүя кан акты.

Каргый әрнеп үзләренең тәкъдирен:
«Нигә тудык?! Нигә үстек, әй ирем?!

Язмыш безне корбанлыкта үзенә
Үрчетәме — элми зарны күзенә?..»

Түзалмыйча Фәрәнгисе зарына,
Шаһ юнәлде ярсып ат абзарына,

Алып чыкты кара туры яшь атны —
Өердә бер, мәшһүр тулпар Бехзадны.

Муйнын кочып, колагына пышылдый:
«Айрылабыз, өмет кошым, хуш инде.

Очкын атым, ычкын кырга — иреккә,
Калма дошманнар кулына милеккә.

Кырларда гиз кыргый аттай, наян оч,
Улым үскәч, бул аңа тик таяныч...

Дошманга?.. Ат!..» Хезмәтчеләр чакырды,
Бар тулпарның аяк сеңерен чаптырды.

Алтыннарын чәчте чүл комнарына,
Сарай, милке — җим ут ялкыннарына.

Карап торды янып калганчы көлгә.
Нөкәрләрен туплады да төркемгә,

Һич сыеныр җир табалмый бер җанга,
Йөз тотты ул тагын илгә — Иранга.

Газиз шәһәр чүлдә күздән югалды,
Шулчак алда зур хәрәкәт кузгалды:

Әфрасияб җитеп бәйләгән юлны! —
Гаскәр баскан тауны, үзәнне, чүлне.

Сиявушка нөкәрләре сүз ката:
«Без аз, диеп шомланып тору — хата,

Кирәк икән без аварбыз тузанга,
Әмма сиңа юл ачарбыз узарга...»

«Бу корбанны кабул итмим! — диде ул,—
Бу дөньяда бикле инде миңа юл...

Исемемә, нәселемә кара тап,
Әгәр китсәм, кунаклык хакын таптап.

Аусам, үзем авам явыз кулыннан,
Чигәсем юк намус, бурыч юлыннан.

Күк хөкеменә карышу да куркыныч,
Аласым юк, күтәрмим кулга кылыч.

Бу хакыйкать борынгылардан калган —
Кем язмышны сугышып җиңә алган!»

Әфрасияб әйтте боларга ымлап:
«Моның серен Гәрсиваз белгән чынлап.

Сугышмакчы, баштанаяк кораллы.
Талкан итеп туктатмасам боларны!..»

Сиявуш та шунда аңа сүз ката:
«Ханым нигә мондый зур яу кузгата?!

Кыяр булсаң минем җанны нахакка,
Ничек җавап бирермен дисең Хакка?!

Тагын кубар бар дөньяда сугышлар,
Кан коелыр, синең башка — каргышлар...»

Җикеренеп бүлде сүзен Гәрсиваз:
«Күп сайрадың! Җитте, сүзне ит,— ди,— аз!

Соң син үзең ник гаскәрле, кораллы?
Кемне сыйларга дип алдың боларны?

Кем яу белән каршы чыга ханына?..»
Һәм Сиявуш килә алмый аңына,

Хыянәтле сүзләрдән катты калды,
Бар мәкерен бу «дус»ның аңлап алды.

Әрнеп әйтте: «Әшәке җан икәнсең,
Килеп-китеп, син хыянәт иккәнсең.

Хан үчле, дип килеп мине алдадың...
Нинди мәхшәр кубар? — Аңлый алмадың.

Үз башыңны янчер бу мәкер, ялган:
Ызгыш иккән иртән дау урып алган.—

Шуннан соң ул тагын эндәшә ханга:
Ханым, тыел, илне батырма канга!

Лаексызлар сүзен дөрескә алма,
Кылычка сүз биреп оятка калма.—

Кул буясаң ялгышып минем канга,
Имин булмас үз башың да, Туран да».

Ярсып тагын Гәрсиваз салды аваз:
«Янап хурлый, ханым, безне бу явыз!

Бирмә җавап! Сүзенә салма колак,
Кылычка юл бирү монда яхшырак».

«Син хак, туган. Шуны уйлыйм үзем дә...»
Һәм гаскәргә кул изәде һөҗүмгә.

Ә Сиявуш, бозмаска, диеп, антын,
Кылыч алмый, качарга кумый атын.

Гаскәре дә тугрылыклы әмергә,
Корал алмый басып торалар бергә.

«Сез карышмау туктаталмас кылычны,
Җитте: инде алмыйча калмыйм үчне.

Һөҗүмгә! — дип илерә хан.— Тапагыз,
Берсен куймый тапап җиргә таптагыз!»

Һәм мең нөкәр турап җиргә таптады.
Җирнең йөзен уттай кызыл кан алды.

Кылыч, сөңге тәрткәләнде биккә дә,
Каны акты. Очып килеп лепкәгә

Кундырды да, Горуй аны бәйләде,
Сөйрәп, җәяү хан алдына әйдәде.

Йөзе чи кан. Киеме баткан канга,
Ачы язмыш әрнүе тулган җанга,

Күмеп мыскыл, көлү, хурлау, каһәргә,
Кайтардылар сөйрәп, җәяү шәһәргә.

Кырыс хөкем чыгарды шундук хан да:
«Эзе, исеме калмас булсын җиһанда,

Сукмак кермәс читтә тын чүл табыгыз,
Шунда илтеп, моның башын чабыгыз!»

«Хан, ялгышма! — дип шаулашты олылар,—
Сиявушның нинди гөнаһлары бар?

Хөкем итик. Ник сусыйсың канына?
Юктан бетмәс бәла такма җаныңа,

Агулама иккән җимеш агачың,
Җимешендә үзең зәһәр кабарсың».

Тагын Гәрсиваз кушылды арага,
Тагын сибә тоз сүнмәгән ярага.

Пиран картның энесе бар, яшь Пилсам,—
Шыттыру юк, яуда үзен фил дисәм,—

Картлар сыман киңәш бирә ул ханга:
«Ачу барда, кулың буяма канга.

Котырыну, ачу — шайтан фигыле,
Андый хәлдә хөкем — явыз шөгыле,

Андый чакта булмый гадел хаклык та,
Нәфрәт кенә уятасың халыкта.

Эш үткәчтән үкенерсең үзең дә...
Була алмый хаклык ачу күзендә.

Хөкем итмә ачудан ярсыганда,
Богаулат. Сал зинданга. Ятсын анда.

Чын җәзасын табарсың ашыкмастан,
Ачу шиңгәч, нык уйлап аек баштан,

Һәм, гомумән, чапканда таҗлы башны,
Башы барлар азагын уйламасмы?

Шаһ ни әйтер? Рөстәм моңа ни әйтер?
Алар үчен болай кытыклау хәтәр.

Сиявушны Рөстәм улыдай иткән!
Бу хөкмеңне кем аңлый алыр икән?

Моңа түгел, бу — кизәнү Рөстәмгә,
Нигә инде фетнәгә ут өстәргә?!

Читтә калмас Кәвыс улы Фәриборз,
Күтәрелер Гөргин, Фәрхад, Гударз, Тус.

Бер баш чабып, Туран батачак канга!
Артын уйлыйк, фетнә якмыйк җиһанга...»

Моны тыңлап уйга талды хан бераз,
Тик коткысын куймый һаман Гәрсиваз:

«Ни сөйләгәнен беләме бу бала?
Син туралган иранлыларга кара!

Иран алар канын дауламас димсең?
Исән калса Сиявуш дигән исем,

Кан дауларга дәшәр Чинын, Рум илен...
Исән исеме илнең сындырыр билен!

Икеләнү, шикләнүне артка ат,
Яу башланган. Дошманның көчен таркат.

Шомнар, уйлар сәгате калды артта,
Елан башын чап, аяк аска тапта.

Үзең куркыт кылыч, гөрзи шавыннан,
Кулны коткар юк шомнар тавышыннан.

Һәлакәт ул — моны сау калдыруың,
Шул бүген без тазартыйк җиңү юлын.

Моны саклап баш тартсаң чын җиңүдән,
Андый яудан мин бүген үк чигенәм.

Башым йолып качам читкә, аулакка,
Яки, җәлләп, моңа җиңү яулатма!»

Горуй, Тимер яклады Гәрсивазны:
«Әллә безгә башка дошманнар азмы?!

Бу дошманың капты, төште тозакка,
Җиңим дисәң, үтерт, сүзне озайтма.

Син гаскәрен кырдың. Ул — ят. Ачулы
Иң чын дошман, истән чыгарма шуны».

Җавап бирә хан аларга борчылып:
«Бу — мин каптым, интегәм тыпырчынып.

Беләм, моның тузан кадәр юк гаебе,
Чәбәләнде безнең гомерләр җебе.

Чынга чыкты мөнәҗҗимнәр юравы:
Сиявуш тик шомлы тәкъдирем авы.

Ул Туранга бер афәт булып килде.
Шул дәһшәтле афәт башланды инде.

Гафу итү бәлаләргә юл ача.
Башын чапсам, менә аннан тамаша!..

Яу кубачак. Кояш та канга батар,
Тураныма, миңа яңый зур хәтәр.

Котылыр юл юк, кылны яр син кырыкка.
Ычкынмаслык каптым тәкъдир — корыйкка...»

Авыр хәбәр Фәрәнгискә иреште,
Нечкә күңел кара кайгыга төште.

Әрнеп, туфрак, көл сипте ул башына.
Шашып чапты этисенең каршына.

Тезләнде дә таҗлы ата каршына:
«Ханым,— диде,— әрнү салма башыма!

Бу нишләвең? Мәкер, яла кулына
Корал булып, кылыч орма улыңа!

Сиявушта тузан гөнаһ булмаса?!
Хактан саклан, Кояш, Күк — шаһит ласа!

Ираныннан сиңа аерылып килде,
Олылап үз итте гаиләң, илне,

Баш тартып үз милке, тәхете, таҗыннан,
Хезмәтеңдә бил бөкте чын җаныннан.

Ата булсаң, минем хәлне дә уйла:
Балаң бәхетен үз кулың белән суйма!

Бирелмә бу ялганчы коткысына,
Ачу үче, җәзасы кайтар сиңа:

Искә төшер Зәххак, Фәридун хәлен.
Оттылармы, үчләнеп, Тур йә Сәльм?

Мәнүчәһер чапты аларның башын...
Уйла Кәвыс, Рөстәмнәр кузгаласын...»

Хан ярсыды: «Бу тагын ни сафсата?!
Күр, йомырка этәчкә акыл сата.

Акыл сатуың бәласен белерсең:
Зинданга илт, башы шунда чересен...»

Сиявушка эндәшә шунда хатын:
«Тоткын. Ялгыз. Еракта илең, халкың,

Бездә юлыктың мәкерле еланга,
Шом хәбәрең генә кайта Иранга.

Синең канга каныккан дошманыңа
Дәһшәт тәкъдир итсен Алла җанына.

Сине бу хур хәлдә күрәсем белсәм...
Хәерлерәк булмас идеме үлсәм...

Атам сүндерде бәхетем кояшын,
Бардыр, күрәм, мәңге күз яшь коясым...»

Кызны саклар китте зинданга алып,
Карап калды Әфрасияб шомланып.

Нидер ымлый да Гәрсиваз Горуйга,
Аңлап ымны (хан баткан тирән уйга),

Аждаһадай ташланып Сиявушка,
Егып җиргә, бирми килергә һушка,

Сөйри аны Горуй чәченнән тартып,
Таш-туфракта тәнен, йөзләрен ертып.

«Әй Ходаем,— дип, Сиявуш сызланды.—
Шаһ, тормыштан китәм сөреп тузанны!

Риза. Тик бир шундый угыл син миңа:
Дошманнарым үкенсен кылмышына,

Шундый итеп ул минем үчне алсын,
Мәңге сабак, шом, дастан булып калсын!

Елап торган Пилсамга ул эндәшә:
«Тормыш бездән үтте! Дустым, син яшә.

Фаҗигамдә күрмим шәхси ялгышым,
Без чит кулда, без — курчагы язмышның.

Күндәм булдым чыкмый Пиран сүзеннән,
Ил генәме? Мин ваз кичтем үземнән.

Пиран әйтте: «Кыен хәлгә тарысаң,
Йөз мең гаскәр бирәм! Яклыйм! Карышам!»

Кая Пиран? Йөз меңнәре? — Еракта,
Мин — Гәрсиваз җәтмәсендә, тозакта.

Мин егылдым. Юк дус кулы. Яклаучым.
Янда — әҗәл, тешен ыржайткан аучым...»

Аны шулай байтак сөйрәп илттеләр.
Ярышларда җиңгән җиргә җиттеләр.

Сарык кебек бәйли дә кул-аякны,
Кара дәһшәткә салып тирә-якны,

Горуй кулга үткен хәнҗәр ала да,
Тартып чәчтән, башны артка аудара,

Сиявушның бугазын кисеп өзә,
Чәчрәтеп каннарын өскә, йөзгә.

Әһ, дияргә өлгерми Кәвыс улы,—
Калтырауны белмәде җәллад кулы.

Яшәү көче — каны тамган урында
Шытып чыкты кызыл чәчәк болында.

Ул «Сиявуш каны» дигән гөлчәчәк,
Шуннан мәңге юл буенда үсәчәк.

Арысландай бу батыр шулай ауды.
Кинәт шунда кара давыл кузгалды,

Караңгылык басты кояшны, күкне.
Куркынышкан халык Горуйны сүкте.

Тик ни чара? Мәңге йокыда батыр,
Ул йокыдан кем соң уянып кайтыр?!

Үтәр еллар. Күп гасырлар. Заманнар.
Әмма моны уята алмас алар.

Менә шулай аның гомере киселде,
Калды җирдә дастаны тик, исеме.

Үләт базы синең гөлбакчаң, дөнья!
Кара тап тик нурлы кояш та монда!

Уңга баксаң, сулга күз салсаң да — бер:
Явыз язмыш, нахак кан, дәһшәт, кабер.

Залим, явыз, намуссызга — юмарт син,
Изге затка күрсәтәсең тик арт син.

Явызларга җәннәт — бу дөнья үзе,
Намуслылар — әрнүдә, яшьле күзе.

Ә бит хаклык, казанышың — гаделдән,
Намуссызлар адәм ич фәкать телдән.

Синең өчен гамь кысмасын йөрәкне,
Күңелемнән кудым мин син өрәкне.

Ышаныч юк сиңа, язмышка — мәңге,
Ялган, мәкер таптый монда адәмне.

Үртә, хурла, гаҗәпләнмәм, шаккатмам,
Юк бит синдә бер гадел хозур тапкан.

Дөнья — милек, мал ул тик Гәрсивазга,
Аңа иркен, ул гарык бәхет, назга.

Сиявушка — хәнҗәр, ут, куылу, качу.—
Ничек тумасын җанда сиңа ачу?!

# ЭЧТӘЛЕК

КӘЙ-КӘВЫС . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

Мазандиран явы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4

Һамавиран сугышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61

Кәй-Кәвысның күккә очуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93

СИЯВУШ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105

Литературно-художественное издание

*Абулькасим Фирдоуси*

**ШАХНАМЕ**

(на татарском языке)

Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 8.04.2003.
Форматы 70×90 1/16. Офсет кәгазе.
«Академия» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 16,97+форз. 0,29.
Шартлы буяу-оттиск 18,73. Нәшер-хисап табагы 9,16+форз. 0,24. Тиражы 2000.
Заказ Я-196.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.